САНИЯ
ӘХМӘТҖАНОВА

# Гәрәбә

*Шигырьләр, поэма, тарихи цикллар*

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2012

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Ә87

**Әхмәтҗанова, С. Ю.**

Ә87 Гәрәбә : шигырьләр, поэма, тарихи цикллар / Сания Әхмәтҗанова ; [кереш сүз авт. М. Галиев]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2012. – 351 б.
ISBN 978-5-298-02214-9

Китапта шагыйрә Сания Әхмәтҗанованың соңгы елларда язылган лирик-фәлсәфи шигырьләре, төрле чорларда милләтебез тарихында якты эз калдырган күренекле хатын-кызларга багышланган «Татар кызлары» лиро-эпик циклы, татар халкына игелекле хезмәт иткән фидакяр табиб һәм галим Карл Фукс образын сурәтләгән «Сүнмәс балкыш» поэмасы һәм популяр җыр текстлары тупланган.

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-02214-9

© Татарстан китап нәшрияты, 2012
© Әхмәтҗанова С. Ю., 2012

# ГӘРӘБӘ — ДИҢГЕЗ БҮЛӘГЕ

Шигырьгә үзеннән-үзе тәгәрәп керә ул — гәрәбә... Үзәгенә кояш нурын йоткан кыргый таштанмы ул? Диңгез сагызыннанмы? Дәрья төпкелләрендә ут һәм су гарасатыннан микъдарлап-тамчылап укмаша да, тыгызланып чыныга-чыныга, гасырлар юшкынында тәмам өлгереп җиткәч, якты дөнья йөзенә ыргытыламы? Нидән хасил була, нинди тылсым барлыкка китерә аны? Асылташлы бизәнү әйберләре арасында тыйнак кына урынны биләгән бу зиннәткә матурлык нәфесен, сихәтлелек әфсенен кем өргән? Гәрәбә төймәнең, игътибар белән карасаң, эчке тирәнлегеннән серле бер «җене күз кысып», хатын-кызны әсәрендерә түгелме?

Көз учыннан төшкән гәрәбә мин,
Яшькелт күзле серле гәрәбә.
Тылсымыма әсир булмам димә,
Бер чагылып китсәм әгәр дә, —

дип яза шагыйрә «Гәрәбә» шигырендә. Назлы тавышка күчеп шигырь сөйләгән мәлендә тыңлап карагыз сез аны: һәр сүз-кәлимәсе гәрәбәгә бәрабәр.

...Менә син, тәүге таң нурлары белән уянып, диңгез ярына чыгасың. Сирәк елмайган Балтыйк диңгезенең тымызык дулкыннары, ярны ялап, кире чигенә. Син яланаяк, тыгыз-юеш комда яфрак-яфрак эзләр калдырып барасың да барасың.

Кинәт еракта, яр кашагасында кош йомыркасы кадәр генә карамчык пәйдә була. Йөгереп килеп, аны учыңа аласың. Гәрәбә таш! Син аны бу таңда беренче булып таптың. Шатлыктан кычкырасың килеп, борылып карыйсың. Артта гәрәбә эзләп килүче мосафирлар бихисап...

Син бәхетле. Учыңда — куныкланган, ябышкак тәнле таш. Әнкә мәгарәсеннән яралып, дөньяга әле генә туып чыккан сабый кебек. Таш дияргә дә уңайсыз. Учка кыссаң, йомшак, җылы, тын гына сулыш аладыр шикелле.

Син, бу хикмәтне кайсы дулкын бүләк иткәнен дә белмичә, диңгез ярыннан йөгерәсең.

Күңелең мәтәлчек ата.

Учыңда — кыргый таш. Хикмәтле табыш.

Шундый халәт: күңелеңнең чын шигырьгә сусаган мәле, имеш. Көйле тибрәнештән ваемсыз изрәп, шигырь юлларыннан йөгертеп кенә узган чакта, кинәт!.. ачылып китә дә шигырьнең югары кимәлгә җиткән мөкәммәл хасияте, син, сулышыңа кабып, рәхәт убылып китәсең. Бөтен вөҗүдеңне үткен бер хис чагып ала. Менә ул — сүз хикмәте, сүз шифасы, сүз егәре…

Көз учыннан төшкән гәрәбә мин,
Диңгез балы — сары гәрәбә…
Үз бәямне үзем белим әле,
Узмасын ла гомер әрәмгә!

*(«Гәрәбә»)*

…Бераздан, чынлыгына ышанырга теләгәндәй күздән кичереп, тагын шигырьнең хикмәтле таҗын — гәрәбәсен эзләп табасың. Табасың да сүзләр ләйсәнендә кабат-кабат коенып кинәнәсең. Нинди төгәллек, нинди тәңгәллек! Хисси нурланыш хасил иткән сүз гәрәбәләрен тагын учка алып кысасы, чөеп карыйсы килә; сүз табигатен тоя алган Шагыйрьгә генә насыйп бәхет бит бу!

Бер якта — су карынында яралган гәрәбә ташын табып алган Оста, зирәк кораллары белән әфсенләп: чарлап, кырып, шомартып, эчендәге нурын балкытып, бер-берсенә төсен, карашын туры китереп, муенса, йөзек, алка кебек зиннәтләр ясый. Икенче якта — күңел тирәнлегендәге сүзләр хәзинәсеннән иң тереләрен чумырып алып бер җепкә тезә алган сәләт-рухиясенә ия Шагыйрь. Бу ике бизмәндәге сәнгати әверелеш охшаш хасият түгелмени? Охшаш кына түгел, илаһи сулыш өртелгән бердәйлек үрнәге.

Көз учыннан төшкән гәрәбә мин,
Яралтучым ләкин көз түгел...
Йөзегемнән төшеп тәгәрәдем –
Тар кысалар миңа төс түгел.

*(«Гәрәбә»)*

Бу кырыс дөньяда Шагыйрәнең көмеш челтәрле читлектә, йөзек кашы булып, әсирлектә каласы килми. Аның җаны үткәненә кире кайтырга алгысына. Һәм бу – шагыйранә чытлыклану хисе генә түгел, ә узган дәверләргә китеп, халык язмышының бүгенге халәтенә тәңгәл җавап эзләү хыялына тиң тарихи ишарә.

Гәрәбәгә табынуы да юкка түгелдер аның. Безнең халыкта энҗе-мәрҗән һәм гәрәбә кебек бизәнү әйберләре кадерле хәзинә булып гасырлардан гасырларга күчә килгән, мирас булып буыннарга тапшырыла барган.

Гәрәбә – Хәтер. Талисман. Ядкяр. Ярларын унике диңгез юган кыйтгаларны биләгән бөек төрки дөньясында хатын-кызның абруе зур булган. Күңеленнән Ил-ана тәхетенә омтылган һәммә хатын-кыз гәрәбә кебек бизәнү әйберләренә аерым мөнәсәбәттә. Ил-йортның учагын сүндермичә, кабатланмас моңнарын буыннан-буынга саклаган хатын-кызлар дәүләтле, дәрьялы мәмләкәтләр тоткан шанлы дәверләрнең рухы-хәтере-догасы шушы гәрәбә төймәләренә сеңеп саклана икәнен тоя-сиземли, күрәсең. Һәм аны җаны-тәне белән тоя алган хатын-кызлар, бу хәтер моңын бишек җырына күчереп, халыкның гомер агачына яңа яфраклар өсти баралардыр.

Мин кемме? –
Хатын-кыз! Мин – Ана!
Саклаучы гаилә учагын.
Кирәксә, бар минем бәйгедә
Җиһангир ирләргә тиң чагым.

*(«Татар кызлары» – «Ниятләү»)*

Ә бит хатын-кыз кавеменнән Өйбикә генә түгел, Илбикә булып тәхет биләгәннәре, беләзекле кулына кылыч алып яуга чыккан каһарманнары да, дөньяви шәхесләрне ир итеп

күтәргән ханикә, җаникә, тәнәкәләре дә аз түгел. Болар бит ирләрне һәм илләрне балдаклы бармак тирәли бөтереп йөрткәннәр. Мисыр халкының табынган Алласын үзгәртергә кодрәте җиткән Нефертитины; үзенә гашыйк итеп, цезарь белән цезарьларны, ягъни илләрне чәкәләштергән Клеопатраны гына искә төшерик…

Үзебезнең төрки-татар кавеменнән дә дөнья хәтерендә калган хатын-кыз шәхесләр шактый: Аттила хатыны Керкә, Кубрат хан кызы Чәчкә, Чыңгыз хан кебек бөек саргаскәрне тудырган Айлын әкә, Татар бугазыннан алып Дунайга кадәрле киңлекләрдә дүрт ил тәхетендә утырган дүрт ханны тудырган Бөртә хатын (Чыңгыз хан җәмәгате), Чыңгыз ханның яшь хатыны – иң кыю, иң чибәр, иң зирәк киңәшчесе, соңгы сулышын алганда янәшәсендә булган татар кызы Ису, Алтын Урда ханбикәсе Тайдула һәм тагын кемнәр… Мәшһүр затбикәләрне олыларга алынган «зәһәр» каләм иясенә нинди мөмкинлек!

«Гәрәбә» китабында без шанлы исемгә лаек хатын-кыз плеядасының чор-дәвер аша үзебезгә якынракларын күрәбез: Нурсолтан, Сөембикә, Фатима Солтан…

Җилеп узам Хәтер далаларын,
Курганнарны кочып, җил елый.
Тояк эзләрендә җир төшләнә,
Ак бүреләр җанда ник улый?

*(«Татар кызлары» – «Чордан чорга»)*

Тарихи шәхесләр, фаҗигале язмышлар. Каһәрләнгән дә, бәяләнмәгән дә, асыл сыйфатлары ачылып та бетмәгән. Аларның серен ачу бүгенге каләм ияләренең фидакяр иҗади хезмәтеннән тора.

Шагыйрә якын дәвердә шанлы исемен калдырган хатын-кызларның кыйссаи язмышын үз даирәсенә туплап бара. Үзе дә мөгаллимә булганлыктан, аны бу изге һөнәр иясе, заманында атаклы Иж-Бубыйда хатын-кызлар мәктәбен оештырып җайга салган Мөхлисә Нигъмәтуллинаның катлаулы гомер юлы тетрәндерә, татарларга дөньяви белем

биру тарафдары Фатиха Аитованың эчкерсез иганәчелеге сокландыра. 1913 елда Сорбонна университетын тәмамлаган Сара Шәкулова, 1941 – 1945 елгы Ватан сугышында очучы буларак катнашып, Герой исеме алган кызлар – «төнге фәрештәләр» Ольга Санфирова, Мәгубә Сыртланова, атаклы балет биючесе Галия Измайлова, гимнастика шаһинәсе Галимә Шөгерова кебек мәшһүр кызларыбыз хакындагы шигъри бәяннар такыясы да китапта нигезле урын алган.

Дөрләтәм дә теләктәшлек ялкыннарын,
Сулыш өреп хәтер-учак кузларына,
Һәйкәл куям шигъри гөлләр бостанымда
Милләтемнең ир йөрәкле кызларына.

*(«Татар кызлары» – «Язмышлар такыясы»)*

* * *

Авылда туып үскән татар кызларының туры сукмагы бакча ызанынннан башлана. Менә ул, кызыл косынкалы кызый, китмәнен җилле уйнатып, бәрәңге төбен йомшарта. Кояшлы иртә. Бакча башындагы бирчәйгән өянкеләр тамырын сыйпап, инеш ага. Арырак – оя-оя казлы болыннар. Шул болында колынлы атлар кешнәп куя. Җитез яшьлек, буразнадан башын күтәреп, күктәге бөдрә болытларга карап хозурлык алырга да җай таба. Чыклы бәрәңге чәчәкләреннән дә шигырь чаткылары күрә белгән кызый, үз күләгәсе тирәсендә бөтерелеп, җир йомшарта.

Табигатьнең, кызлар күңеледәй,
Дәрт ташыган гүзәл мизгеле.

*(«Зәңгәр күлдә»)*

Кай арада еллар бөтереп алыр да, уен гына тоелган эшгамәлләре җитди вазифага, көндәлек шөгыльгә, котылгысыз бурычка әверелер. Бала карау мәшәкате, ир ихтыярына көйләнү, түгәрәк табынны муллыкта тоту, кырыс кагыйдәле йортта тәртип-низамга буйсынып яшәү – болар бар да

мөселман хатын-кызына бәләкәйдән үк сеңдерелә килгән күндәмлек-тугрылык кануннары. Ә инде иҗатка тулысынча бирелү өчен тормышның кайбер мәҗбүриятле тармакларыннан ваз кичү нәүмизлеге дә заруридыр.

Тел сандыгын вакыт-вакыт барлап, сүз хәзинәләрен актарып, сайлап, шомартып, илһам нурына манып торырга кирәк. Чишмә дә шулай бит: каршына тезләнеп, ләйсән су тамчыларын учыңда биетеп-иркәләп, догалар пышылдап, сулышын киңәйтеп тормасаң, үпкәләп, суы кача да, җир бәгыренә китеп йомыла.

Кайчан да булса бер могҗиза булыр да, дөнья мәшәкатьләреннән арынырмын, иркен сулап, каләмгә тотынырмын, үкенечтә калган еллар өчен дә икеләтә дәрт белән язармын да язармын дигән әкияти хыялдан кемнәрнең генә күңеле изрәп йомылмаган.

Иҗат ул – даими үсү, каләм белән кое казу.

Поэзия шаукымы тышаулы рухка – җәза, азат рухка – дәва.

Әмма бу болгавыр дөньялыктан үзеңә тигән вакытны каерып алып, аны иҗатка багышларга беркайчан да соң түгел! Үзеңдә ихтыяр көчен тойдыңмы, үзең генә белгән мәҗүси доган белән сүз дәрьясын уята алдыңмы – илһамлы сер, изүен ачып, Күк катларыннан күңелеңә сикерә.

Өр-яңа Мин булып, якты көнгә
Ачам менә бүген күземне.
Мин яңадан тудым бу дөньяга...
Эзли торгач, таптым үземне.

*(«Өр-яңа Мин»)*

Шигърият кишәрлекләре инде мең кат эшкәртелгән: казылган, чәчелгән, урылган. Менә бу түтәлдә – мәхәббәт кыяклары, бусында – туган җиргә мәдхия куаклары, менә тагын... Инде яңа сүз куәсенә, фикри табышка җирлек тә калмагандыр кебек. Әмма... Кабатланган, мең кат әйтелеп шомарган сүзләрне Шагыйрь, үзенчә янәшә китереп, тынын – тынга, тәмен – тәмгә, гамен гамьгә тезеп куюга, ни гаҗәп, моңарчы

әйтелмәгән яңа гыйбарәләр балкый да китә; яңгырашы белән колакны иркәли, үткенлеге белән аңны сызып сискәндерә, матур әйтелеше хисләрне кытыклап уята. Тел дәрьясының чиксезлеге, әүвәле һәм ахыры булалмаган шигъри сүзләр мириадасының илаһи төрлелеге үзе бер могҗиза түгелмени!

Иелмәстәй башларны да иеп,
Хәсрәтләргә сала бу дөнья!
Галәми уй иңрәткән җанга
Көч тә бирә ала бу дөнья!

*(«Дөнья бу!»)*

* * *

Кораб-тустаганда океан-диңгезләр кичеп, хәйран дөньялар гизеп, күз күрмәгән илләргә сәяхәт кылып, бай язмышлы гомер кичергән өлкән әдибебез Миргазиян Юныс, яшь каләм тибрәтүчеләргә карап: «Их, бу татар яшьләрен дөнья гиздереп, илләр күрсәтсәң, кем чыкмас иде болардан», — дип сызланып әйткәне бар. Шулайдыр, таулар артында — таулар, илләр артында илләр бар.

Шундый чорда яшәдек бит: Ялтада яисә Күктүбәдә иҗат йортында ял иткәндә, Кара диңгез ярыннан ерак офыкларга үрелеп, Төркияне күрү хыялы белән яна идек. Төрки галәмендә бердәнбер азат ил. Кызыктыра. Алгысыта иде. Цензура күзе төшмәслек итеп, шигырьләргә бик эчкәре яшерелгән фикерләрне, Төркиягә карата булган соклану хисләрен саркытып ала идек. Ә инде кыюлыкка тыюлык бетерелгәч, Истанбул капкалары ачылгач... Агылды шагыйрьләр, һава юлыннан да, су юлыннан да, җир юлыннан да... әмма ярсып каләм тибрәтмәделәр, әйтерсең лә ярларын дүрт диңгез юган төрек илендә гомер буе аунап үскәннәр: бар да табигый, бар да билгеле, янәсе.

Ә менә гәрәбә муенса таккан Шагыйрәбез соңлабрак кына, гомерендә беренче кат сәяхәт кылды. Бу борынгы илнең көчле рухы күз карашында, бәйсез атлап баруында; ирек тәме җиләндә, күгендә, кояшында икән бит! Йөзләгән

манаралардан яңгыраган азан моңына Шагыйрәнең йөрәк тибеше кушыла:

Дүрт диңгезнең дәрт-дәрманы кага
Йөрәк тибешеңдә, Төркия.
Кояш егәрлеген кыю җиккән,
Тау-ташлыкны җир оҗмахы иткән —
Яши белеп яши Төркия.

*(«Төрки дөнья таҗы — Төркия»)*

Шагыйрь Мөдәррис Әгъләм әйтмешли: «Еракка китеп кара син, еракка китеп кара!» Үз ватаныңның хәлен аңлау өчен, чагыштырып карау, ирек тәмен сүздә түгел, гамәлдә тою кирәк икән шул.

Һәйкәлләре дә мәһабәт —
Атлары аягүрә...
Каян килә бу горурлык? —
Тез чүкмәгәнгә күрә!
Әрнүле яшәү асылын
Аңладым шул чагында:
Күктән бирелми Азатлык,
Даулана яу кырында!
Атасы булган милләтнең
Ияре — үз кулында!

*(«Төрки дөнья таҗы — Төркия»)*

Әмма әдип өчен иң мәгънәле сәяхәт — халкының хәтеренә, бөтен дин тәгълиматларыннан да бакыйрак тарихына. Моны бик вакытлы тоеп, үз кыйбласын тапкан Шагыйрәбез юкка гына болай дип язмый:

Йолдызларга карап юлга чыгам,
Җилкән итеп ярсу йөрәгем.
Үз кайгымны бүген куеп торам, —
Милләтемә тоям кирәгем.

*(«Татар кызлары» — «Юлдан юлга»)*

Әгәр мин, әсәр көзгесенә карап, бу шигырьләрне бар иткән каләм иясенең кайсы халыкның бәгыреннән өзелгән

икәнен тоя алмыйм икән, тышта кайсы фасыл җиле искәнен, бу эчкерсез тәрәзәләрнең кайсы заманга ачылганын, бу таш диварларга кайсы гасыр каны чәчрәгәнен, бу моңнарның нинди йөрәктән саркыганын, бу былбылның кайсы телдә сайраганын, бу тау-ташларның тамыры нинди хәтерне саклаганын белә алмыйм икән, димәк, бу шигырь шәлкеме — канатын җуйган кош, хәтерсез калган аң, җилгә кол булган флюгер, сүзеннән мәхрүм калган үги моң, баласыз тирбәлгән җырсыз бишек, тамырыннан купкан тирәк, суы саташкан кое, убылып төшкән җансыз таш һәм тагын... Тагын... Тагын... Димәк, бу шигъърият — сүз күче сарган, ләкин сүрә булалмаган кысыр бушлык сүрүләре...

«Гәрәбә» китабындагы тере күзәнәкле, әтрафлы шигырьләр әнә шуларны тәнбиһ итә, әрнеп кисәтә. Кисәтә дә, сискәндерә дә; йокымсыраган зиһенеңне камчылап, кан тамчылары саркытып, халыкның хәтер катламнарына, тарихи тамырларына төшәргә өнди. Шуннан соң гына гомум язмышыбыз агачының ябалдашына менеп, киң офыкларны колачлап, яшәвеңне расларга, Тукай манарасына ышыкланырга була.

«Соңгы... соңгы... иң соңгы!» — дип тибә йөрәк,
Тукталмыйча, юлым дәвам итү кирәк!
Иң беренче булмасаң да, уй-тулпарым,
Соңгы булма, максатыңа оч син тизрәк!

*(«Татар кызлары» — «Фатима Солтан»)*

* * *

Татар милләтенең төш-үзәге — Арча төбәге. Халкыбызның күңел кәгъбәсенә асыл затларны биргән, гыйлем фәһемен, әдәби сүз кодрәтен бибәһа югарылыкка күтәргән як. Мәркәзи Казаныбызга борын-борынгыдан үз капкасыннан керә торган бу төбәктә динне, гореф-гадәтне олылау, бисмиллалы табын күрке, эчкерсез кунакчыллык, ана теле хасиятенә, иманга тугрылык, җир кадерен бәрәкәтли белү — һәр җәһәттән халыкны күркәм иткән бу изге сыйфатлар, күңелдә табигый соклану уятып, Арчаның игелекле хол-

кында, якты йөз суында чагыла. Һәм бу рухият казанышы, бернинди заман шаукымнарына бирешмичә, «Без яшәдек, без яшибез, без яшәячәкбез!» дигән шигарьдә, бөтен буена басып, тантана итеп килә.

Туган җирең менә шундый булсын да — горурланмау мөмкинме?!

Туган җирең менә шундый булсын да — шигырь язмый каласыңмы?!

Горурланам — мин бит Арча кызы!
Данлы хөкем — уйлап карасаң...

*(«Ант»)*

Әйе, горурлыгыңны яңгырату өчен лаек биеклек кирәк. Шул биеклектән торып, Шагыйрә бер мәлгә икеләнеп, юашланып, уңайсызланып та куя.

Күпме бөекләргә, гали җанга
Арча булган язмыш аланы.
Мин — арчалы, мин, дип, Апрель кызы,
Җиңел генә әйтеп буламы?!

*(«Ант»)*

Мин язучылар мохитендә күреп белгән арчалы классиклар исән булса... Мөхәммәт Мәһдиев, мут елмаеп: «Кыюрак бул, кызый, син бит үзебезнеке», — дияр иде. Казан арты, Кушлавыч, Кырлай якларын иң газиз сүзләр белән олылый белгән Сибгат ага Хәким исә, күзләрен солы бөртеге кебек кенә кысып, аталарча елмаер да: «Шигырьләрең шифалы яңгыр кебек», — дияр иде. Гомәр Бәширов исә, күзләрен нурландырып, мин синнән разый, дигән кебек, олпат елмаеп, сүзсез генә баш кагар иде. Иде... иделәр шул... Хәзер инде, Күк катларыннан иелеп кенә: «Мәрхәбә!» — дип, Шагыйрә ханымның иңнәренә йолдыз каурыйлары коялардыр кебек.

Ә ул язмыш ярыннан, яфрак-яфрак эзләр калдырып, үз гәрәбәсен эзләп килә.

***Марсель Галиев,***
Татарстанның Г. Тукай исемендәге
Дәүләт премиясе лауреаты

# Жан сулышым



*Ачыл син, Күкләр капусы,*
*Ашкынганда йөрәгем, —*
*Бу дөньяда кешеләргә*
*Бар бит әле кирәгем.*

*Ашыкма, йөрәк, тукталга,*
*Ишетсәң сур быргысын, —*
*Милләтемә бүлеп бирәм*
*Сулышымның соңгысын.*

## АНТ

Горурланам – мин бит Арча кызы!
Данлы хөкем – уйлап карасаң...
Сискәнепләр китә каләм җаны,
Тоеп бөекләрнең карашын.

Тотындыммы шигырь ялларына,
Тукай калка камчы уйнатып;
Язгы күкрәү булып дәшә гүя:
«Телнең җанын йөрмә канатып!»

Яз сулышын Кырлай кырларына
Апрель җиле тигез тараткан.
Җир, Су, Кояш туры Тукаемны
Халык бәгыреннән яралткан.

Күпме бөекләргә, гали җанга
Арча булган язмыш аланы.
Мин – арчалы, мин, дип, Апрель кызы,
Җиңел генә әйтеп буламы?!

Заман җилләренә җанны ачсам,
Тетрәп калка кузы, моң яна.
Тукай аһы тамган чал туфракта
Яралганмын мин дә дөньяга.

Яралганмын, ахры, күз яшеннән,
Тукай җанлы булып гомергә.
Ләйсәнле һәр тамчым — изге антым,
Оеганда җаным шигырьгә.

Явым көткән халкым күңеленә
Тамып, шытым бирсен тамчылар.
Кыямәт көне килсә моң багына,
Тукай үзе безне камчылар.

Олы ташлар куеныннан чыгып,
Яшьнәп яналмасаң, ант итмә!
Тере сулы чишмәң булалмасам,
Туган җирем, мине яд итмә!

## ӨЛГЕРӘСЕ ИДЕ

Фикер кылы буйлап алга барам,
Уй ташкыны күмә сизгерлекне.
Заман бушлыгына очмас өчен,
Югалтмаска иде тигезлекне.

Галәм хәтерендә эзсез сүнә
Үз-үземнән узалмаган көннәр.
Тарихларга ялган битләр өстәп,
Иртәгәмә тозак кора кемнәр?

Вакыт тәгәрмәче тешләренә
Суырылып кереп бара гомер...
Көннәр исәбеннән түгел яшәү,
Җан сулышым — яңа туган шигырь.

Хаклык даулап, ярсып алга барам,
Тын алырга туктап, юк һич чара.
Өлгерәсе иде... өлгерәсе —
Хакыйкатькә ничә шигырь ара?
Үз-үземә ничә сулыш ара?

## ТЕРЕ СҮЗ

Кынысыннан
хәнҗәр тартып чыгаргандай,
Куеныннан
китап алды
олпат шагыйрь.
Зиһенемнең
күзен ачты
үткен сүзе,
Тере судай,
җан сирпеде
имле шигырь.

## ТАШЛАМА...

Шигырем, дускаем, ничекләр син булдың?!
Сыйдырдың яхшысын, яманын;
Чарасыз калганда, күңелнең китеген
Иң кирәк сүз белән ямадың.

Каләмем, ташлама! Шигырем, туктама!
Үз туган телемдә сайрап тор,
Дустымның җанына шифа бул, сихәт бир,
Дошманга кылычың кайрап тор!

## ТАТАР ҖЫРЫ

Моңнардан яралган җыр бит син –
Уе да, гаме дә халыкның;
Вакытка буйсынмас көч булып,
Хәтерләр түреннән калыктың.

Татар җыры! Татар җыры!
Иманга чакырып дәшәсең...
Тылсымлы догадай, син мәңге
Яшәдең, яшисең, яшәрсең!

Күңелләр мөлдерәп тулганда
Елата курайлар сагышы;
Шатлыклы көйләрең чыңында
Ишетәм чулпылар тавышын.

Татар җыры! Татар җыры!
Өметле юатып дәшәсең...
Аһәңле наз булып, син мәңге
Яшәдең, яшисең, яшәрсең!

Син мәгърур бөркеттәй ирекле,
Күңелгә канатлар куясың.
Далалар киңлеге тар сиңа,
Ә үзең йөрәккә сыясың.

Татар җыры! Татар җыры!
Горурлык уятып дәшәсең...
Кодрәтле рух булып, син мәңге
Яшәдең, яшисең, яшәрсең!

# СӘХТИЯН ЛӘ ЧИТЕК, КӨМЕШ ДАГА...

Күк иңенә шоңкар чөйгән чакта,
Ефәк җиләнеңне җил ача.
Алмаз хәнҗәреңә кын икән бит
Тар сәхтиян читек кунычы.
    Сәхтиян лә читек, көмеш дага
    Болгарлардан алган мал микән?
    Аргамак ат менгән азамат ир
    Кай ханәшкә хәләл яр икән?

Ирәннәргә торыр ир шаһбазы
Аудан кайта дала буйлатып;
Каршыларга килә, ай, яшь бикәч,
Акбүз атын иркә уйнатып.
    Ияреннән сикереп төшкән чакта
    Чыңлап куя йөгән аелы.
    Сәхтиян лә читек... кемнәр чиккән –
    Дебет бизәкләре каюлы.

Сахраларга чыгып кош очырдым –
Җан серемне ачтым дөньяга.
Бәгырь кылым өзеп очты аһым,
Бәрелде, һай, килеп кыяга.
    Сәхтиян лә читек табанында
    Сыкрап куя нәфис туз микән?
    Лачын дигәннәрең байгыш булгач,
    Җаның иңрәсә дә, түз икән...

Зилзиләләп кайный дала каны,
Кубарыла гасыр тузаны.
Бу бит бары таңгы мираж гына –
Араларда чорлар ызаны.
　　Сугарыйм ла дисәм, акбүз атым
　　Айдалага таба юл ала.
　　Сәхтиян лә читек кигән җайдак
　　Рәшәләргә кереп югала.

　　Сәхтиян лә читек, көмеш дага
　　Болгарлардан алган мал микән?
　　Аргамак ат менгән азамат ир
　　Мәңге насыйп булмас яр икән.

## ИКЕТЕЛЛЕ ТЕЛСЕЗЛЕК

Бер казанга сыймый, диләр, ике башны,
Ни күрсә дә, сабыр итә татар башы.
Безнең казан, ташыса да, кайный бирә,
Пешә ашы, берүзенә – ике башы.

Ике тел дә сыя безнең бер авызга,
Һәр икесен тигез, дибез, бердәй хаклы.
Кайсын гына тешләсәң дә, бик авырта –
Икесе дә дәүләт теле, халык яклы.

Бер казанда кайнасак та, бер үк утта,
Кемдер әйтер: хокуклар, дип, безнең башка;
Телләрнең, дип, берсе – олы, берсе – кече,
Тик берсенең языла, дип, сүзе ташка.

Туган телең оныт, диеп, кем боера,
Авызыңа кем соң көчләп хәмер коя?
Намазлыгың йолкып алып тез астыңнан,
Саф әхлаклы булма, диеп, кемнәр тыя?

Хөсетлектән ашый күрмә күршең башын,
Үткенлим дип, кыя күрмә үз телеңне;
Мин татарга урын тар, дип, бу казанда,
Килмешәккә хәер итмә үз түреңне.

Кайда синең татарлыгың-хәтәрлегең?
Дөньяларны дер селкеткән даның кайда?
Милләт өчен җанын фида кылганнарның
Исеменә сыенудан нинди файда?

...Бүген «ханнар» толерантлык ягын карый,
Баш сау булсын, калганын, дип, вакыт җайлый.
Тарих шаһит: бүкәннәргә салган чакта,
Кем дә түгел, татар башын татар сайлый.

Казан кайный...

## МИЛЛЕНИУМ

Рәсәй Илбикәсе сәфәр чыккан
Яраннары белән озын юлга,
Шәһре Казаныбыз хозурына
Алып килгән аны Идел-елга.

Шанлы кунакларга чиркәү чаңы,
Туплар гөрелтесе сәлам биргән.
Комач бәрхет җәйгән сукмак буйлап
Казаныма яңарышлар кергән.

Әби патша биргән фәрман белән
Елга аръягына чыккан Казан.
Казансуның бәгыреннән ташып,
Чал дулкыннар комга ниләр язган?

Гасырларны гасыр алмаштыра,
Чорны чорга күпер тоташтыра.
Миллениум! Неон балкыш булып,
Йолдызларның күзен камаштыра.

Кавышалар юллар-тамырларың,
Ашкынгандай йөрәгеңә, Казан!
...Купкан туфан, әрнүле эз салып,
Ил язмышы синең аша узган.

Еллар арты еллар алышына,
Әверелеп канат кагышыңа.
Миллениум! Иске Казан бага
Хәйран калып дөнья агышына.

Дуга сыман борылып китә күпер,
Меңьеллыкны кичә җилгер Хәтер.
Галиҗәнап тарих безнең хакта
Килер буыннарга ниләр әйтер?

Үтә айлар-көннәр кай арада,
Сәгать суга әнә манарада...
Миллениум! Меңьеллыклар чиге
Әйләнде дә куйды манзарага.

Әби патша йөргән фаэтон да
Тарихи бер ядкяр булып калды:
Өске Казан белән Яңа Казан
Җир астыннан чуен юллар салды.

Мизгел чабуыннан тотып кара –
Иртәгегә кул сузымы ара...
Миллениум! Заман тизлегендә
Казан яңа меңьеллыкка бара.

## МӘҢГЕЛЕК УТ

Хәтер булып, Казан йөрәгендә
Һәйкәл тора татар улына.
Богауларын өзеп ташлар да ул,
Ашар кебек кошлар юлына.

Тоткын шагыйрь, яудашлары белән,
Тугры калып биргән антына,
Чит туфракка газиз башын салган,
Татар исемен аклау хакына.

Кем ул анда, гайрәт чәчкән булып,
Кара яга милләт йөзенә?
Дары иснәмәгән мәхлук җаннар
Ватан сакчысына кизәнә.

Хәтер көне... Тын кал бер минутка...
Тамырларда — вакыт агышы.
Йөрәк тибешенең кайтавазы —
Манарада сәгать тавышы.

Халык улларына баш иергә
Килдек бүген һәйкәл янына;
Учыбызда — мәңгелек ут таҗы —
Кызыл канәферләр кабына.

## УЯН, ДИДЕМ...

Гыйнвар төне. Җанда – эңгер-меңгер.
Йокымсырый мидә уй күче...
Сикереп торып дәштем үз-үземә:
«Мәрткә китәсең бит, әй Кеше!»

Калҗаң майлы, ятар урының җайлы,
Тәрәзәң дә тавыш үткәрми;
Ишегеңдә җиде катлы йозак –
Күршең түгел, хәтта бур керми.

Дөнья шавы бераз айнытмасмы –
Нигә күңел күзең ачмыйсың?
Җан йозагың охшый күгәргәнгә,
Ерак аттың микән ачкычын?

Бу син түгел. Син башкарак идең,
Таш битлек бит гамьсез йөзеңдә;
Элеккечә моң дәрьясы түгел,
Кипкән кизләү нурсыз күзеңдә.

Дула, буран! Ыжгырыгыз, җилләр!
Миңа уянырга кирәк, кыш!
Тоткынлыкта, күкрәк читлегендә
Бәргәләнеп сула шигырь-кош.

Китерегез кәгазь-каләмемне,
Сырхау күңелемә шул дәва...
Ярты юлда калган җырым булып,
Бәгыремә, саркып, моң сава.

Гыйнвар төне... Күздән йокы качты...

## КАНАТСЫЗЛАР

Очам диеп күтәрелгән кошның,
Тотып, канатларын кистеләр...
Кемнәр диген — Күкне кочалмаган
Зәгыйфь уйлы, түбән хисләләр.

Көнләшерлек иде аның җыры —
Шушы булды иң зур «ялгышы».
Әверелде моңлы бер кыйссага
Әйталмаган рәнҗү, сагышы.

Әле яңа гына борынлаган
Бер кошчыкны күккә чөйделәр;
Җырчы кошның канатларын биреп,
Оч биеккә, сайра, диделәр.

Үземнеке диеп сузды җырның
Чит берәүдән отып алганын.
Кемдер сизде, кемдер «аңламады»
Яшь кошчыкның матур ялганын.

Басыла төшкәч гарьле әрнүләре,
Үзен-үзе кошым юатты;
Бәгырь кылларына кагылды да
Ихлас җанлыларны елатты.

Сайрар урыны күктә булмаса да,
Рухы мәңге түбән булалмас!
Канатларын кисеп атсалар да,
Җырын беркем тартып алалмас!

## ОЧ ИРЕККӘ, ҖЫРЫМ!

Җырым минем – иреннәрнең назы,
Сөйгәнемнең йөрәк тибеше,
Яшь кызларның Казан урамыннан
Дәртле басып атлап килеше.

Моңлыларның кагыл җаннарына,
Нәүмиз күңелләрне назлап коч.
Тоткын булып берүк яши күрмә,
Оч иреккә, җырым, әйдә, оч!

Сабый тугач дәшә бар дөньяга,
Изге моң ул – аның тавышы.
Җырларымда – яшь ананың бәхете,
Ялгыз калганнарның сагышы.

Җан тибешем туа җырлар булып,
Моңсыз калсам, белмим, нишләрмен.
Әйтеп бирер сүзләр табалмагач,
Җырга салам ашкын хисләрем.

## ЧАКЫРУ

Мин сезне кунакка чакырам –
Очрашып торабыз бик сирәк;
Хисләрем дөрләгән чагында
Кушылып янарга сез кирәк.

Мин сезне кунакка чакырам –
Ваемсыз яшәүләр онытылсын;
Кузгатып оеган гамьнәрне,
Тамырга сихерле моң тулсын.

Мин сезне кунакка чакырам –
Килмичә калмагыз, мин көтәм.
Наз кушып, сөюем дисбесен
Бер тезәм җыр итеп, бер сүтәм.

Мин сезне кунакка чакырам –
Ут өстик сүрелгән йөрәккә:
Миңа да, сезгә дә җитәрлек –
Җырларым өләшәм бүләккә.

## ҖАВАП

– Сыктанасың, бәхет булмады, дип,
Нәрсә соң ул бәхет, әйт әле?
Син бит күктән йолдыз чүпләмәкче,
Безнең янга – җиргә кайт әле.

Иң биеген тауның яуласак та,
Буй җиталмас барыбер Кояшка.
Үз дигәнчә яшик, тыныч кына,
Артык хәсрәт алмыйк бу башка.

Кемдер һомай кошы тоткан, диеп,
Хак булса да, зинһар, сөйләмә.
Аңлыйсыңмы шуны: әйләнә Җир,
Бәхет тирәсендә әйләнә.

Без дигәнчә барса дөньялары,
Бик шәп булыр иде, әлбәттә.
Биргәненә шөкер итеп торыйк:
Бар да тигез, диләр, җәннәттә.

– Сүзең хактыр... Тик тергезим әле
Шәфәгымның соңгы күмерен...
Сүнәр-сүнмәс җанны саклаганчы,
Дөрләп янсын булган гомерем.

# ИНАНУ

Бар булганга шөкрана итми,
Нәфсем төшкән чакта юк-барга,
Сак кисәтү сала шомлы уйга –
Ышанам, Илаһым, Син барга.

Беркем күрми, диеп, гөнаһ кылсам,
Сәбәп тапсам гаебем юарга,
Вөждан газаплары җанны телә –
Ышанам, Илаһым, Син барга.

Кайчак өмет өзеп юл табудан,
Әзер булсам барып туктарга,
Җиде ятлар ярдәм кулы суза –
Ышанам, Илаһым, Син барга.

## НИЯТ

Каләмемнең кипте карасы,
Сулык-сулык йөрәк ярасы…
Сынык күңел, үчле хәтер белән
Ничек кенә яшәп карасы?

Каләмемнең алдым яңасын,
Догам япты йөрәк ярасын.
Аллаһыма сыенып үтмәк булдым
Фани белән бакый арасын.

## ХАЛӘТ

Калдырыгыз әле берүземне,
Һич югында, бары бер көнгә;
Ишетәсем килми берәүне дә,
Сүз кушасым килми беркемгә.

Телефонны бүген өзеп торам —
Шылтыратып җанга тимәгез.
Күренеп кит, диеп чакырмагыз,
Сагынылган, диеп килмәгез.

Хаталардан авырайган җанны
Күз яшенә иде манасы,
Вөҗдан каршысында сәҗдә китеп,
Күкләр хөкемендә каласы...

Калдырыгыз бүген ялгызымны,
Бу халәтем минем вакытлы, —
Гамәл дәфтәремне барлар өчен,
Мин туктатып торам вакытны.

Калдырмагыз бүген ялгызымны...

## ГАДЕЛ ХАКИМ

Ышанмасаң әгәр бүгенгемә,
Шик тудыра икән узганым, —
Синнән түгел, оят үз-үземнән:
Гадел хаким — бары вөҗданым.

Чынлап түгел, фәкать уйларымда
Булса вәгъдәбезне бозганым, —
Синнән түгел, оят үз-үземнән:
Гадел хаким — бары вөҗданым.

Кеше бәхетенә нәфес сузсам,
Бәхил кылмый тәкъдир язганын, —
Синнән түгел, оят үз-үземнән:
Гадел хаким — бары вөҗданым.

## БЕРӘҮГӘ

Ике күзең – кып-кызыл кан,
Кыргый җанвар – килешләрең;
Өнне ала әрле-бирле
Киләп сарып йөрешләрең.

Йодрык болгап кизәнүең
«Яшел елан» шаукымыдыр...
Аллаһыдан куркыр идең –
Син Фиргавен токымыдыр.

## САБЫРЛЫК БИРДЕ

Үзем сайлаган язмышым,
Ник соң әле аһ орам?
Җиде юлның чатларында
Уйларга чумып торам.

Таянып йөрәккәемә,
Ирекле булыйм микән?
Зиннәтле ялган бәхетнең
Бер колы булыйм микән?

Канатларымны каерып
Атканданиләр диим?
Бәгыре боздай салкынны
Үз итеп, ни хәл сөйим?

Кайтып туган нигеземә,
Сихәтләр алыйм микән?
Кара уй сарган башымны
Суларга салыйм микән?

Җиде уйның чатларында
Көч-хәлләр түзеп торам…
Соңгы юлны сайламадым –
Сабырлык бирде Ходам.

## НИ БУЛСА, ШУЛ!

Тәрәзәмә бер кош килеп кунды.
Ник яралы аның канаты?
Тәрәз аша үзәк өзгеч тавышы
Бәгыремне тырнап канатты.

Тән ярасы җан ярасы түгел,
Бер төзәлер әле ничек тә...
Син – ирекле, кошым! Минем җаным
Ачылмаслык тимер читлектә.

Анысы алай озак торалмаслар,
Үз-үземнән мине аерып...
Ни булса, шул: ачам йозакларын,
Теш-тырнагым белән каерып.

## КҮҢЕЛ ТӨШКӘНДӘ

Телдә – йозак. Уйга – тозак,
Сүзгә ятьмә коралар;
Хокук даулап баш калкытсам,
Колагымны боралар.

Талантсызлар шаһи хәзер,
Әхлаксызлар – илаһи.
Меңнән берәү – чын даһи,
Башкалары – чи даһи.
Татар булып туганыңа
Гарьләнерсең, билләһи!

## БЕЛМӘҮ КИРӘК

Күзгә карап алдалыйсың, ант итәсең, –
Ялганыңны сизеп торам, аңлап торам.
Бер мизгелгә ышанып та куя язам:
Хак сөйли, дип, үз-үземне алдап торам.

Чын дөресен әйтә алу батырлык шул,
Синдә, дускай, ни кызганыч, куян йөрәк...
Һәм шуңарга куаныплар бетә алмыйм –
Бүген миңа дөреслекне белмәү кирәк.

## ҮЧ

Бәллүр касәләргә салып бирдең
Ачуыңның утлы шәрабын.
Үч ялкынын йоткач кына белдем
Сусау басылмауның сәбәбен.

Азлап-азлап татыйм зәһәреңне,
Арта гына бара ачысы;
Йөзне чытып, тешләремне кысып
Эчәсе дә әле эчәсе.

## ТӘҮБӘ

Корбан бәйрәмнәре якынлаша,
Кайтып киләм балачагыма.
Сабый күңелем мич куйнында пешкән
Гает коймакларын сагына.

Мамык кебек яңа йон оекбаш
Булды безгә бәйрәм бүләге.
Ни хакында иде әниемнең
«Ярлыкагыл!» дигән теләге.

Ул чаклардан аңга сеңеп калган
Дога-аятьләрем санаулы...
Яулык ябып кына гыйлем артмый,
Хәтере дә кырык ямаулы.

Менә бүген, менә иртәгә, дип,
Үз-үземә яшим алдашып.
Ярым-йорты тоткан уразамдай,
Йөрмәс микән бу җан адашып?!

«Бер аягы җирдә, берсе — гүрдә», —
Әллә соң бу шушы хактамы:
Денсез дип тә әйтү дөрес түгел,
Мөэмин дип тә булмый мактанып.

Минем өчен серле ул дөньяның
Могҗизасы күпме белмәгән;
Балачактан канга сеңмәгән шул,
Ана сөте белән кермәгән...

Тарихларны сылтау-сәбәп итеп,
Күңел манарасы аумасмы?
Хак дин өчен шәһит киткәннәрнең
Рәнҗешләре безгә яумасмы?

Хаҗ кылганга, корбан чалдырганга
Мин кызыгып карыйм, сокланып.
Җанга баккан Ярымайны күрми
Яшәү гөнаһ инде, акланып.

Ул бәхеткә соңламасам иде,
Үз манарам көтеп, үз аем.
Изге Гает көннәрендә сорыйм:
«Хак юлыңа күндер, Ходаем!»

## ДӨНЬЯ БУ!

Таш кыя да сыкрап куя кайчак –
Ирләр була белик, димәгез.
Ирләр елый, елый алар сирәк,
Түгелсеннәр бераз, тимәгез.

Гарасаты куба, зилзиләсе, –
Балкып кояш чыга аннары.
Күз яшьләрен юллый, ахры, Күкләр,
Пакьләр өчен безнең җаннарны.

Бөркетләр дә, канатлары талгач,
Кунып тора таулар кашына.
Таянырлык җылы иңнәр кирәк,
Зарлы уйлар төшсә башыңа.

Иелмәстәй башларны да иеп,
Хәсрәтләргә сала бу дөнья!
Галәми уй иңрәткән җанга
Көч тә бирә ала бу дөнья!
Дөнья бу!

## КЫЙБЛАҢ ҮЗГӘРТ

Корым сарса бу җаныңа, юшкын ятса,
Мөлдерәмә күңелеңне хәсрәт басса,
Күз яшьләрен хәерлегә埠 юра, —
Елый-елый, иманыңа куәт сора.

Яны белән борылып басса дус-ишләрең,
Гел кирегә китеп торса бар эшләрең,
Булыр-булмас бәндәләргә башың орма, —
Сәҗдә китеп, иманыңа куәт сора.

Ашыкмый тор. Җиде ятка бәйләнгәнче,
Якын кешең чит кешегә әйләнгәнче,
Өр-яңадан тормышыңны башлап кара, —
Кыйблаң үзгәрт... Иманыңа куәт сора.

## НИЯТ ҺӘМ ГАМӘЛ

— Гел кирегә китеп тора эшләр,
Алдан күрәм юкса әмәлен.
— Ниятләрең изге идеме соң?
Ниятеңә күрә — гамәлең.

## ҮЗЕМ БЕЛӘН КҮЗГӘ-КҮЗ

— Әле ярый яшь гомерне, — дисең, —
Үкенмәслек итеп уздырдым.
— Син шуны әйт: дәртең-дәрманыңны
Нинди гамәлләргә туздырдың?

— Ташпулатлар корып куймасам да,
Яшәмәдем калып мескенгә.
— Кайдан килде малың, кая китте,
Кеше хакы юкмы өстеңдә?

— «Надан» дигән мөһер сугалмаслар,
Гыйлем эстәү — сөйгән шөгылем.
— Ә халкыңа файда китердеңме,
Сарыф итеп акыл-фигылең?

Үз-үземнән хисап алам шулай,
Аулак уйга качып, көн үткәч...
«Милләтенә ни мирасы калды?» —
Дип сорарлар әүвәл, мин киткәч.

## ҖИМЕШ

Уйлап баксаң, күпме эшне
Башладым да ташладым:
Гәрәбәдәй орлык чәчеп,
Кысыр җирне ашладым.

Инде гомер көзем җитеп,
Артта калгач җәйләрем,
Көшелемдә алтынымның
Аз булуын шәйләдем.

Соң булса да, җиң сызганып,
Кабат эшкә керештем:
Бер орлыктан биш үренте
Үстерергә тырыштым.

Ике атлыйсын бер атлап,
Бар көчемә йөгерәм.
Бәлки инде, җимешләрем
Татырга да өлгермәм...

Шулчак нәни оныкчыгым
«Каршы чыкты» сүземә:
«Мин дә шигыль язам», — диеп
Кунаклады тиземә.

# ЯШЬ ӘБИ

Автобуста бер кыз урын бирде,
Күреп алгач басып барганым.
Ялгыштымы берәр танышы дип,
Йөзгә чыккан микән арыганым?

Бер апага ымлыйм, ул утырсын, —
Мин яшьрәк әле, түзәрмен...
«Утыр, утыр, — ди ул, — син үзең дә...»
«Ишетмәдем» соңгы сүзләрен.

Яшел утны сабыр гына көтә —
Салмакланган күңел чаптарым...
Кая китте керт-керт кенә басып,
Итәк җилпеп үткән чакларым?

Туфлиләрнең биек үкчәлесен
Бер киям дә салам яңадан.
Яңгыратып көлүләр дә хәзер
Сирәгәйде — артмый чамадан.

Көзгеләрнең башын әйләндермим,
Чыгып китәм онытып карарга.
(Үтеп барган саен күз кысмыйлар:
Тыйнаклана отыры алар да.)

Шулай итеп олыгайдым микән,
Үз күңелем күреп яшәми?!
...Оныгым ала муеныммнан кочып:
«Син иң матур, иң-иң яшь әби!»

# КЕШЕЛЕГЕМ

Кеше икәнеңне кешелекле
алымнар белән исбатлау кыен.

*Халык сүзе*

Сукыр төннең күзенә багып, нәрсә көтәм?
Көпә-көндез шәм яндырып, кемне күзлим?
Кешелегем чыгып качты мине ташлап,
Арлы-бирле йөгерә-чаба шуны эзлим.

Белдерүләр язып элеп карыйм микән,
Табылдыклар бүлегенә барыйм микән?
Кеше хәзер акча өчен җанын сата –
Кешелекне әллә сатып алыйм микән?

Әгәр берәү ишетә калса сүзләремне,
Тилергәндер бу мескен, дип уйлап алыр.
Җавабым шул: бүген мине Кеше итеп
Саклап калса, кешелегем саклап калыр.

# ТӨЕН

Йөрдем нәфеснең азуын
Сылтап заманасына.
Бәйләргә вакыт күңелне
Иман манарасына.

Үрелгән бавым җидедән –
Һәр җебе нәфес яклы,
Чишелеп китүдән күңелне
Бары вөҗданым саклый.

Бер җебе бауның – мин-минлек –
Дөньяга баш булмакчы;
Икенчесе – хөсетлегем –
Җанны талкып тормакчы.

Өченче җеп – саранлыгым,
Байлыкка табынуым,
Дүртенчесе – гөнаһларга
Сөртенеп абынуым.

Бавымның бишенче җебе –
Ялкаулык шаукымчысы,
Комарланып ризык җыю –
Җебемнең алтынчысы.

Җиденче җеп – кинә саклау
Дустыма-дошманыма,
Үчләнеп каршы чыгуым
Намусым кушканына...

Нәфесемне мин бүгеннән
Бәйләп куям төенгә.
Җиңдем тагын берәүне, дип,
Шайтан мәлгунь, сөенмә!

## ГАЕП КЕМДӘ?

– Дустыма чиштем серемне –
Фаш ителми калырмы?
– Син саклый алмаган серне
Дустың саклый алырмы?

## БҮРЕ ӨНЕНДӘ

Айның тулган төнендә,
Төштә, әллә өнемдә?
Кайдан килде егетлек? –
Булдым Бүре өнендә.

Миндә бүре каны мы,
Кыргый җанвар аңымы? –
Эх тә итми тапшырдым
Аңа газиз җанымны.

Нигә якын җибәрде? –
Аңламадым үзем дә...
Яшь яшәгән Бүренең
Сагыш күрдем күзендә.

Бүрем мине кумады,
Белмим, әллә сынады?
Сизеп өнсез калуым,
Күккә карап улады.

Ялгышуым аңладым,
Качу ягын карадым.
Юл куюын Бүренең
Картлыгына юрадым.

...Бүре булып бүре дә
Көндәш эзли тиңендә.
Куркаклыгым тамгасы –
Теш эзләре иңемдә.

## КЕШЕ БУЛЫЙК

Эт елына алмаш булып
Кабан елы ашыга.
Юраган юш килә, диләр,
Юрыйк әйдә яхшыга.

Без яшәп күнеккән инде
Терек-терек элдереп.
Дуңгыз син, дип сүккән саен,
Танау белән җир сөреп.

Башны аска иеп йөрмик,
Мыркылдамыйк юк-барга...
Мөмкин ишәю ягыннан
Шул мәхлукка охшарга.

Елы шундый, дип акланмыйк,
Кылган саен явызлык.
Кеше булып кала белик,
Котыртса да дуңгызлык.

Килсен әйдә Кабан елы
Төкле аягы белән!
Чыдам сырты, күндәм холкы,
Муллык-байлыгы белән.

## ХЫЯЛЫМ

Үз-үземне алдап яшәгәнче,
Яшәгәнче йөрәк яндырып,
Чынга ашмас кыргый хыялларны
Иске елда китәм калдырып.

Шаять, күңел бераз тынычланыр,
Тау төшкәндәй булыр иңемнән...
Күңел канатына ял да кирәк –
Җиргә төшәм хыял күгеннән.

Яңа елга кереп барам менә,
Ваз кичмичә әйткән сүземнән...
Хыялларым белән саубуллашмыйм,
Ераклашам гүя үземнән.

Ник соң әле дөньям төссезләнде,
Җуйды күңел җете буявын?
Моңа кадәр мине яктылыкка
Әйдәп барган икән хыялым.

Яңа елга кереп барам менә,
Ераклашып барам үземнән...

## ӨР-ЯҢА МИН

Мин яңадан тудым. Бу дөньяга
Ташны тишеп чыккан үлән мин.
Тоткынлыкның ни икәнен аңлыйм,
Яшәү кадерен шуңа беләм мин.

Сусынымны басар өчен аз шул
Тик көттереп яуган ләйсәннәр.
Мин Кояшка үреләм җылы эзләп,
Әрсез диеп әйдә әйтсеннәр.

Булыр башка басып китүчеләр,
Иючеләр булыр башын да –
Нәфис кенә үзе, ләкин көрче,
Тишкән, диеп, кыя ташын да...

Өр-яңа мин булып, якты көнгә
Ачтым әле бүген күземне.
Мин яңадан тудым бу дөньяга...
Эзли торгач, таптым үземне.

Сикереп мендем Пегас ияренә,
Үз кулыма алдым тезгенне.
Ялгышмагыз мираж гына диеп
Юлсыз юлга салган эземне!

## ИСӘНМЕ, ЯҢА КӨН!

Тормыш бигрәк катлаулы, дип
Зарланырга вакыт тар:
Тәвәккәлләп, җиң сызганып,
Зур эшләр башлыйсым бар.

Әле кичәге көнемнән
Гыйбрәтләр аласым бар;
Ялгышларымны төзәтеп,
Сафланып каласым бар.

Кайтарасы бурычым күп
Иртәгесе көнемә:
Кичектереп килгән эшләр
Басып тора иңемә.

Гафу үтенгәнем көтә
Үпкәләп китүчеләр,
Бәхиллегем өмет итә
Саксыз рәнҗетүчеләр.

Җан яралган нигеземә
Түләнмәгән түлисем,
Газиз халкым, милләтемә
Бирелмәгән бирәсем.
Алынмаган аласылар,
Күрелмәгән күрәсем…

Исәнме, яңа туган көн!
Син хәерхаһлы, беләм.
Каршылыйм сине шатланып,
Изге ниятләр белән.

# СӘФӘР

Һәркем эзли җирдә үз кыйбласын,
Иртәге көн тәкъдир кулында.
Язмыш кичеп йөргән юлаучы без,
Мосафир без гомер юлында.

Борылышлар күтә, тукталышлар…
Хушлашырга әле бик иртә.
Биштәреңне ерак куймыйча тор:
Сәфәр көтә безне, юл көтә.

Якты өметләрне кабызыйк та
Җылытыйк бер арган җаннарны.
Бәхет яши торган тарафларга
Кузгалырбыз иртүк аннары.

Әле генә таң сызылган иде,
Инде кояш байый офыкта.
Таулар менеп, таулар төшәсе бар
Гомер дигән кыска вакытта.

## АЛДАША КӘККҮК, ЯЛГЫША

Һәр көн иртән кояш чыга,
Җиһан нурга коена, –
Шушы бәхетле мизгелләр
Мәңгелек күк тоела.
Алдаша кәккүк, ялгыша,
Санап кемнең гомерен?
Кояшлы һәрбер иртәнең
Белеп яшик кадерен.

Күрешүләр көтә-көтә,
Хушлашыр вакыт җитә.
Бу дөньядан күпме җаннар
Бәхиллек алмый китә...
Алдаша кәккүк, ялгыша,
Санап кемнең гомерен?
Шатлыклы һәр очрашуның
Белеп яшик кадерен.

Төн куйнына башын салып,
Күз йома тагын бер көн;
Яхшымы ул, яманмы ул, –
Кайтара алмый беркем.
Алдаша кәккүк, ялгыша,
Санап кемнең гомерен?
Һәрбер йөрәк тибешенең
Белеп яшик кадерен.

## ГОМЕР УЧАГЫ

Яңа язлар килә, яңа назлар,
Тик гомернең булмый яңасы.
Күз ачып, күз йомган кебек кенә
Язлар белән көзләр арасы.

Алгысыдык, Нух көймәсен биләп,
Ышыграк урын алырга.
Чабатаны тизрәк түргә элдек,
Өметләнеп түрә булырга.

Ник бәхетнең бәхет булганлыгын
Аңламадык үтеп китмичә?!
Төсен җуйды хисләр такыясы,
Иясенә барып җитмичә.

Уллар туды, бакча күкрәп үсте,
Өлгердек без йортлар салырга.
Соңармадык микән әнкәйләрнең
Фатихасын алып калырга?

Дөрли-дөрли сыза гомер-учак,
Ашыккандай янып бетәргә.
Ата – улны, ана кызны белми,
Ашкынабыз дөнья көтәргә.

Ялгыз гына төбәлербез беркөн
Гомер шәфәгының күзенә…
Соңгы кузы керфек йомган мәлдә
Кемнең яше тамар йөзенә?..

## ЮЛАУЧЫ

Тәгәри тормыш арбасы,
Ай үтәсен көн үтә;
Язны кичеп, җәйне гизеп,
Гомер көзенә җитә.

Җитсен әйдә, узган юллар
Минеке барысы да.
Ярсу аткаем сер бирмәс,
Сөрлекмәс арыса да.

Олавыма шатлыклар да,
Борчулар да төялгән,
Табышлар һәм югалтулар
Катлап-катлап өелгән.

Тормыш йөге арта бара,
Чакрымнар узган саен.
Текә үргә менүләрнең
Табам бит әле җаен!

Тәгәри тормыш арбасы
Язмышның юлларыннан.
Урап тотам дилбегәне,
Төшермим кулларымнан.

## МИН ҮЗЕМ!

Яхшы атлы булып, адым саен
Акыл бирүчегә шул сүзем:
Сорап алган киңәш кенә кыйммәт –
Борчылмагыз, зинһар... мин үзем.

Горурлыгым аяк чалды бүген,
Тезләнмәскә, Раббым, бир түзем!
Егылганда ярдәм кирәк түгел –
Булышмагыз, рәхмәт... мин үзем.

Шатлык арты шатлык килде беркөн –
Дус дигәннәр ачмый ник йөзен?
Бәхетемне гафу италмыйсыз? –
Гафу итәм сезне... мин үзем!

## ХУШ ХӘЗЕРГӘ…

Үткенләнгән, диеп сокланмагыз –
Күз тиюләр каләмемне егар;
Сүз-кошыма уклар төбәмәгез –
Куркып, шигыремнән очып чыгар.

«Язганнарың үзең турындамы?» –
Урынсызга ошбу соравыгыз.
Тәүбә-тәүбә, юш килмәсен тагын
«Ялгыздыр ул» дигән юравыгыз.

«Җырың моңлы!»
Моңсыз җыр туамы?
Моңлырагын әле язасым бар…
Хуш хәзергә, барыр юлым ерак –
Үз җырымны эзләп табасым бар.

# Гомерлек бурыч

*Туган нигез җылысына төреп,*
*Кардәшлекне саклыйк йөрәктә.*
*Үз-үзенә кайта һәрберебез*
*Туган якта, туган төбәктә.*

# БӘБКӘ

Каз бәбкәсе саклый әни
Чирәмдә, су буенда,
Төпчек кызы үсеп җиткән,
Бүләк кирәк туена.

Борынгыдан килгән йола –
Туй табыны мул булыр;
Каклаган каз, мамык мендәр –
Иң зур бүләк шул булыр.

Буйга җиткән сылу кызлар
Читләргә китә «очып»,
Килен булып төшәр бәбкәң,
Болыт-мендәргә басып.

Яшь кәләшнең наз бишеге –
Каз мамыгы – күбектән,
Тиздән аңа яучы килер
Лачын кебек егеттән.

...Татлы уйларына талып,
Калгып киткән чирәмдә...
Бирмә, әни, син бәбкәңне –
Тилгән оча тирәндә.

## ДӘВАМЧЫ

Бар җиһанга аваз салды сабый,
Кеше туды Җиргә – ир бала.
Биләүләнеп ап-ак өметләргә,
Җан түрендә бәхет тирбәлә.

Күкләр гүя хәер-дога укый:
Ишетелә азан тавышы, –
Кендек каны тамган шул мизгелдән
Башланамы Кеше язмышы?

Бишек җыры итеп, көйгә салып,
Изге теләк теләр әнкәсе;
Җисеменә туры килсен диеп,
Матур исем эзләр әткәсе.

Яшь ананың күңел бишегендә
Якты уйлар гына тирбәлә.
Киләчәкне сайлап тавыш бирде
Нәсел дәвамчысы – ир бала.

## УЛЫМА

Минем нәни фәрештәм син —
Күзләр генә тимәсен;
Канатларың җилпи-җилпи,
Тәпи атлап киләсең.

Үчти-үчти үчтеки шул,
Булмый һич тә туктатып;
Туп шикелле түп-түгәрәк, —
Сикерәсең тып та тып.

Җәннәт гөле — хуш исләрең,
Җанга дәва булырлык;
Килешләрең бигрәк матур —
Карап кына торырлык.

Шаян песи баласыдай
Иркәләнә беләсең,
Учка кунган кошчык сыман
Чырык-чырык көләсең.

Киреләнгән чакларыңда
«Кәҗәләнеп» аласың.
Кызык: кем дип сөя икән
Кош-кортлар үз баласын?

# ФАТИХА

Алдыңда — өр-яңа дөнья
Көтә ачып кочагын;
Синең дә, газиз кошчыгым,
Очышка әзер чагың.

Әй минем кыю бөркетем,
Ашкынма шулкадәрле, —
Биеклекнең азлап-азлап
Яуланганы кадерле.

Туры килер зур сәфәрдә
Сынау тавын кичәргә,
Олы Тормыш диңгезенең
Тозлы суын эчәргә.

Яшь шул, балам, канатларың,
Ныгыр әле очканда.
Онытма туган ояңны,
Киң күкләрне кочканда.

## БАЛАМ, БЕЛ...

Илен, телен, динен алмаштыра —
Ниләр көтә адәм баласын?
Аңла, балам, сине Үзең итеп
Туган телең саклап каласын.

Куштым сиңа сайлап матур исем —
Җисемеңә туры килсен ул;
Милләтеңнең бер мирасы итеп
Әткәң-әнкәң биргән исем ул.

Вакыт белән бергә үзгәрә бел:
Телләр өйрән, балам, дөнья күр.
Йөз чөермә ләкин үз телеңнән,
Бу — Ватанны сату белән бер.

Син тугач та, әнкәң сөте белән
Иренеңә тамган туган тел.
Туган телең җуйсаң, әниеңне
Онытуың булыр, балам, бел!

## МОҢЛАНУ

Бер яшь егет бигрәк, әй, моңлана,
Гитарасын алып кулына;
Йөрәк серен аңа ача кебек,
Сак-сак кына чиртеп кылына.

Моңы — садә, көе шундый дәртле,
Яшь күңеленә берәү кергәнме?
Дөньяларын шулай оныттырып,
Әллә тәүге сөю килгәнме?

Ишетми дә мине, күрми дә ул,
Уйларына чумган уралып.
Бүлдерүдән куркып сөю җырын,
Мин тыңладым аны тын калып.

Ярты юлда җырың өзелмәсен,
Хыял канатларың сынмасын,
Саф күңлеңдә туган тәүге хиснең
Гомерләре кыска булмасын.

Бер яшь егет бигрәк, әй, моңлана,
Гитарасын алып кулына.
Гитарада түгел, уйный гүя
Күңелләрнең чиртеп кылына.

## МӘҢГЕЛЕК БӘХӘС

Акыллы һәм чибәр идек,
Әдәп саклап кына йөрдек
Без сезнең яшьтә, дисез;
Күпме генә орышсак та,
Үзгәртергә тырышсак та,
Сез хәзер башка, дисез.

Әй, әтиләр-әниләр,
Борчылмагыз сез юкка!
Сүз әйтмәгез без яшьләргә,
Бу мәңгелек бәхәсләргә
Куярга иде нокта.

Сездән туган уллар икән,
Сездән туган кызлар икән,
Без начар булалмабыз;
Сезнең алмагачта үскән,
Үсү белән сикереп төшкән,
Без — алтын багалмагыз.

Хыялларга ирек кирәк,
Күкрәктәге ярсу йөрәк
Азатлык даулап тибә.
Туу белән зиһен керсә,
Акыл бездән алда йөрсә,
Яшьлек-юләрлек нигә?

# АНА ҺӘМ БАЛА

— Хәзер болай сөйләшмиләр,
Хәзер болай эшләмиләр,
Хәзер болай яшәмиләр, —
Дөньядан артта калгансың син, әни!

— Сөйләгән сүзең ятышлы,
Эшләгән эшең уңышлы,
Һәрбер адымың отышлы, —
Кайлардан мондый булгансың син, балам?!

## ӘНИ СҮЗЕ

Бераз гыйбрәт алсын, диеп,
Балам кеше булсын, диеп,
Әткәң-әнкәң, укып дога,
Озаттылар сине юлга.

Көне үтсә, төне озын –
Шәһәр сыный авыл кызын.
Урамның бар кырык күзе –
Кызармаслык булсын йөзең.
Аңладыңмы, балам, сүзем?

## ДУСКАЕМ-СЕРДӘШЕМ

Безнең әле, яшәү кадерен белеп,
Канатланып йөрер чагыбыз;
Яшьлек килә, юл бирегез, диеп,
Утка-суга керер чагыбыз.

Бигрәк чая кызлар икән болар,
Яшен уты кебек, дисеннәр,
Дускаем-сердәшем!

Югалтулар килер, зур табышлар –
Әзер булып торыйк барсына.
Беребез – апа, беребез сеңел булыйк,
Баскан чакта сынау каршына.

Бигрәк тату кызлар икән болар,
Бертуганнар кебек, дисеннәр,
Дускаем-сердәшем!

Беребез – ал, беребез гөл булыйк,
Пар чәчкәсе язгы болынның;
Дәртле көе, серле моңы булыйк
Кабатланмас яшьлек җырының.

Бигрәк матур кызлар икән болар,
Язгы гөлләр кебек, дисеннәр,
Дускаем-сердәшем!

## УЙЛАРМЫ?

И кыз бала, кыз бала,
Моңаймале, түз, бала!
Юксынып туган йортын,
Гомер итә кыз бала.

Әти ясаган кабада
Җеп эрлим җырлый-җырлый.
Кулымда әни орчыгы
Әйләнә зырлый-зырлый.

Төн йокылары күрмәгән
Әнием яшь чагында,
Кул җылыларын тоям күк
Шул җитез орчыгында.

Әтинең тальян тавышы
Ишетелгәндәй була;
Вакытсыз өзелгән моңы,
Сулкылдап, җанга тула.

Чорналган җептәй гомерләр,
Чуалды заманалар...
Уйлармы туган нигез, дип
Без үстергән балалар?

## ТОРМЫШ КИНОСЫ

Йөгерергә чыктым — үзгәрергә:
Күренәсе килә яшь булып,
Сау-сәламәт күренәсе килә,
Йөрәк чаба алдан, ашкынып.

Даруымны бүген эчми тордым —
Саф һавадан алыйм сихәтлек;
Бәлзәм булып җанга ятсын әле
Бу иртәнге салкын рәхәтлек.

Балыкчылар ярга сибелгәннәр,
Пеләшләрдән күзләр чагыла.
Әзмәвердәй бер ир, эт җитәкләп,
Кайтып килә шәһәр ягына.

Колагына плейер тыккан малай
«Девятка»сын юа тырышып.
Нинди җыру алыштырды икән
Таллыктагы кошлар тавышын?!

Яр буенда ике кызмача кыз
(Туташ, дисәм, телем әйләнми.)
Көйрәтергә шырпы сорап тора,
Бөкре балыкчыга бәйләнеп.

Кичтән кайтмый калган маллар кебек
Адашканмы, калып «көтүдән»?
Кичә-бүген бергә буталганмы
«Кәефләнеп» бәйрәм итүдән?

Ак яулыклы әби шешә җыя,
Берне тапты, куйды сөенеп:
Бүген кабар сыныгын эзли булыр,
Куак төбе саен иелеп.

Йөрәк алды чәнчеп: үз урынында –
Мине ташлап кая киталсын.
Хәлем китте, күреп ун минутлык
Хакыйкати тормыш киносын.

## ТИЕШ!

Керфекләремнән сибәли
Кояшлы яңгыр бүген.
Әнине искә алам да,
Татлы сагышка талам да,
Гөлдери күңел күгем.

Хатирәләр чүпләм-чүпләм:
Алтындыр да көмештер...
Үткәнне җанда яшьнәтү,
Киләчәк өчен яшәтү –
Бүген миңа тиештер!

* * *

Үпкәләдең, ахры, әни, миңа,
Моңсу бага дымлы күзләрең.
Элеккечә җан түреннән түгел,
Саркып кына чыга сүзләрең.

Чишмәләрнең юлы ерак китә,
Кайтыр өчен кабат әйләнеп;
Мин бит синең бәхет таҗларыңа
Сәйлән булып тамар ләйсәнең.

## КИЧЕР, ӘБКӘЙ

Туры сүзле, гадел Ак әби син,
Күңел нурың күчкән йөзеңә;
Оныкларың дәү әнием диеп,
Якын итеп дәшә үзеңә.

Төп нигезнең якты кояшыдай
Каршылыйсың, озатып каласың.
Дәү әнием, син көннән-көн безгә
Кадерлерәк була барасың.

Балаларың, үрмә гөлләреңдәй,
Назларыңда үскән коенып;
Инде хәзер оныкларың яши
Изге теләгеңә сыенып.

Күрше кызы аша хат җибәрдең:
«Әйтер сүзләрем бар, балам, кайт!»
Тагын кайтмый калдым. Кичер, әбкәй,
Соңламасам иде... соңгы кат...

## УТЛЫ КҮМЕР

Әниемнең күзләрендә
Шатлык микән, зар микән?
Мин баласын уйламаган
Берәр көне бар микән?

Ә мин менә онытылам,
Йөрәк тигез типкәндә;
Әни, дип инәләм бары
Соңгы чиккә җиткәндә.

Үтәлмәгән вәгъдәләрем –
Җандагы утлы күмер...
Әнине бәхилләтергә
Җитәр микән бер гомер?!

*

Балалар хакы яшәтә
Яндырып та көйдереп.
Торсалар ярый «Йәсин»дә,
Иренгә су тидереп...

## КАЙТУ

Ялантәпи баскан эзләремнең
Җылысына карлар яугандыр,
Авыл башындагы нәни инеш
Кар көртенә күмелеп калгандыр.

Әй, язмышым, аерып туган йорттан,
Еракларга алып киттең син;
Карашыма – сагыш, ә йөземә
Сагыну төсе салып үттең син.

Бер ягымлы тавыш дәшә сыман
Бик ерактан, хәтер түреннән.
Ромашкалы җәе яшьлегемнең
Ап-ак бәскә инде төренгән.

Ак бүреген кырын салды микән
Басуларда эскерт өсләре?
Таралгандыр таңгы урамнарга
Яңа пешкән икмәк исләре.

Әткәемнән откан «Авыл көе»н
Сагынып җырлармын дип кем белгән...
«Туган нигезеңә баш июнең
Ояты юк» дигән уй белән
Кайтып киләм әле, кыяр-кыймас,
Күптән чыгып киткән юл белән.

# ӘНИ БӘЛЕШЕ

Башына яулыгын бәйләп,
Алъяпкычын яба да,
Кулы кулга йокмый: әни
Бәлеш ясый табада.

Бармакларын биеткәләп,
Чит-читен бөреп куя;
Шулпа салырга уртага
Каплаулы тишек уя.

Бәлеш пешү хөрмәтенә
Табагач та кузгала:
Кызу мичтән эләктереп
Кайнар бәлешне ала.

Хуш исләрен бөрки-бөрки,
Мичтән чыгып килеше:
Бигрәк уңган, йөзе килгән —
Бәлеше дә бәлеше!

Кетер-кетер килеп тора —
Мондый бәлеш кайда бар?
Түгәрәк капкач астыннан
Күтәрелә кайнар пар.

Бәрәңгесе вак-вак шакмак,
Исең китеп карарлык,
Ите дә мулдан күренә —
Өреп кенә кабарлык.

«Кыстатмагыз, җитешегез! —
Әни табынга дәшә, —
Кайнар килеш ашыйк», — диеп,
Агач кашык өләшә.

Ярмаланган бәрәңгесе
Телгә салуга эри,
Шулпасында бөрчек-бөрчек
Майлары йөзеп йөри.

Ите сусыл, бигрәк йомшак,
Мине кап диеп тора.
Сөйләшергә вакыт та юк —
Кашыклар биеп тора.

Әни пешергән бәлешне
Ашагачтын бергәләп,
Инде безнең дә «йөз килде»,
Күңелебез түгәрәк.
Килгән-килгән китеп торма,
Үт син, бәхет, түргәрәк.

# ӘНКӘЕМ-СЕРДӘШЕМӘ

Сабый чактагыдай, иркәләнеп,
Алларыңа башым салыймчы?
Үзем күптән әни булсам да мин,
Нәни кызың булып калыймчы?

Чәчләремнән сыйпа әле, әни,
Тойыйм кулларыңның җылысын.
Изге йөрәгеңә сыйдыргансың
Мәхәббәтнең иң-иң олысын.

Өзми-куймый бәхетем сайраганда,
Син һәрвакыт әзер тыңларга;
Җанымдагы телсез сагышларны
Ярый син бар сүзсез аңларга.

Дустым да син, әни, киңәшчем дә,
Бер серләшик таңга кадәрле...
Упкыннарга күңел убылганын
Тояр кешең булу кадерле!

Сүз әйтергә әле өлгермәдем:
«Аңлашылды, — дисең, — барысы да.
Авыр йөгең кире төяп китмә,
Ташлап калдыр, — дисең, — басуда.

Шатлыкларың бүлеп ал үзеңә,
Беләм, алар сиңа кадерле.
Үз сыеннан үзе сыйланганнар
Була, — дисең, — озын гомерле».

Бер бушаныйм диеп кайткан идем,
Күңел иләсләнгән чагында,
Ничек әле чишелмәдем, әни...
Сине кайгырткапга кайгырудан
Артыр иде кайгым тагын да.

## УКЛАУ

Җырлый-җырлый токмач җәям,
Бигрәк җитез уклавым!
Тәгәрәп йөри кунада —
Бер дә белми туктавын.

Җәемем дә бигрәк тигез —
Юкара җәйгән саен,
Чит-читләрен кат-кат үтә —
Уклавым белә җаен.

Каян шулай остарганмы? —
Ул инде шактый яшьтә.
Әбиемнең кулларында
Өйрәнгән башта эшкә;

Әбиемнән — әниемә,
Миңа күчте аңардан.
Кулдан-кулга йөри-йөри,
Уклау шактый шомарган.

Хуҗабикә алыштырыр
Көннәре килде менә:
Уклавымны иртәгәдән
Тапшырам киленемә!

## ӘЙТТЕМЕ ӘНИ, УЙЛАДЫ ГЫНАМЫ?

Күзләреңә туры карый алмыйм –
Карашларың җанга ут сала.
Газиз башкаеңда нинди уй бар,
Никләр болай моңлы син, бала?!

Җырлавыңны тыңлап, йөрәк туктый,
Күкрәгемдә каба сулышым...
Еламыйча түзәр хәлләрем юк –
Никләр болай моңлы тавышың?

Кушылыймчы мин дә җырлавыңа,
Булмасам да җырчы сандугач;
Бардыр әле уртак көйләребез,
Моң-зар кылларыбыз пар булгач...

Күкрәгемә куй син башкаеңны –
Ярты сагышыңны мин алам.
Бергә-бергә барыбер җиңелрәк,
Моңаймале ялгыз, и балам!

Сузып-сузып уйна гармуныңны,
Күңелеңдә төер калмасын.
Җырлый-җырлый, елый-елый юыйк
Әрнеп типкән үкенү ярасын.

## ТАНСЫКЛАУ

Табыннар тулы булса да,
Сый-нигъмәт бөтен түгел:
Чикмәнле мич бәрәңгесен
Тансыклап куя күңел.

Йомры бәрәңге егәре —
Куәтле буыннарда,
Җанга йөгерә җылысы
Иң зәһәр салкыннарда.

Күмерләнеп пешә бит ул
Юлаучы учагында.
Кем сыйланмас бәрәңгедән,
Биетеп учларында!

Икмәк белән янәшә ул
Кадерле урын алган:
Михнәтле елда халкымны
Ачлыктан йолып калган.

Җыяр ризык, эчәр сулар
Читтә йөртә бәндәне.
Туган нигез төшкә керә,
Сагындырса бәрәңге.

# ШӘЛБИЗӘК

Әни шәл бәйли кышкы кичләрдә,
Җитез уйнатып көмеш энәсен.
Ул улларыңа, әни кадерлем,
Күзләр тимәсен, күзләр тимәсен.

Әни шәл бәйли кышкы кичләрдә,
Изге уйларын җыр итеп көйләп;
Дисбе тарткандай, күзәнәк саен
Ак теләк теләп, ак теләк теләп.

Әни шәл бәйли кышкы кичләрдә,
Йөгерек уйлары еракка китә:
Балаларыннан – газизләреннән
Бер хәбәр көтә. Гел хәбәр көтә.

...Мин шигырь язам кышкы кичләрдә,
Сагышка манып көмеш каләмем.
Җырлы шәлбизәк булып ирешсен,
Әнием, сиңа таңгы сәламем,
Таңгы сәламем, сагыну сәламем.

# ӘНИЕМ ХАТЛАРЫ

Була минем бик бәхетле көннәр,
Була моңсуланган чакларым.
Шатлыкта да, авыр вакытта да
Укыйм әниемнең хатларын.

Теләп миңа күркәм сабырлыклар,
Кушсаң да син, әни, түзәргә,
Күз яшьләрең тамган эзләр калган
«Бик сагынам» дигән сүзләрдә.

«Быел язгы ташу иртә төште,
Юлга чыкма, балам», — дигәнсең,
Хат соңында үзең: «Тиз көннәрдә
Күрешү көтеп калам», — дигәнсең.

«Бәрәңгеләр әйбәт булды, диләр,
Чыгып күрә алмыйм мин генә.
Сабый бала карагандай карый,
Мең рәхмәтләр яусын киленгә...»

Әниемнән хатлар килми инде,
Кайт, балам, дип хәзер дәшми ул...
Бәхил булып, хәер-дога кылып,
Җан тибешем булып яши ул.

## ТУГАН ЯКЛАР — ҖАНГА ДӘВА

Кайларга китеп барасың,
Утыртчы, зәңгәр поезд?
Хәсрәтләремнең куйнында
Калдырма мине ялгыз.

Булмасмы ерак җирләрдә
Хәлемә керүчеләр,
Өзгәләнгән минутымда
Бер киңәш бирүчеләр?

Сагышлы йөзем күрмәсен
Якыннар да, ятлар да.
Сөенмәсен дус түгелләр,
Мин көенгән чакларда.

Нигә ашыгасың, поезд?
Ерагая тавышың.
Кемнәргә сөйләп бушатыйм
Күкрәк тулы сагышым?

Сыенам туган нигезгә, —
Бүтән чарам калмады.
Үзең күтәр кайгыңны, дип,
Поезд мине алмады.

Туган яклар — җанга дәва,
Диюләре чындыр ул;
Илләреңнән аерылсаң,
Бер хәсрәтең ун булыр.

## ОЗАКЛАМЫЙМ

Төшләремә күптән керми туган йорт,
Кайтмый, диеп, инде өмет өзгәндер.
Күрешүне көтеп, сабыр май ае
Юл буена сары чәчәк тезгәндер.

Элеккечә мине әни җанашым
Капка төбендә үк каршы алмас шул...
Озак тордың, хәбәр бирми тилмерттең,
Һай балам, дип өзелүче булмас шул.

Язлар җитсә, күңелдә боз кузгала,
Дәрьялары тула күзгә яшь булып;
Сагынулар-саргаюлар газаплый,
Бәгырькәйдә яткан ачы таш булып.

Озакламыйм, кайтып киләм авылга,
Тынгы эзләп җанымдагы давылга.

# МИРАС

Күңелемдә, әни, өең нурлы,
Тәмле ашың пешкән кайчан да.
Яран гөлләр арасыннан карыйм,
Сагыну пәрдәләрен ачам да.

Уйларымда дөрли хатирәләр,
Чәчрәп куя якты очкыны;
Ишетелгән күк кырыс-йомшак итеп
Әтиемнең капка ачканы.

Иңнәремә ап-ак олы мичнең
Җылылары калган ягылып.
Мөлдерәшеп карый тамчы гөлләр,
Күз карашым китсә кагылып.

Әти ясап биргән агач чанам
Бала чакта калган онытылып.
Көянтәмнең алма-бизәкләре
Яшьлек төсен җуйган, сыкылы...

Энем мунча яга. Нәкъ әтичә,
Миллекләрен үзе бәйләгән.
Бөтнек исләренә рәхәт оеп,
Яшьлек болыннарын әйләнәм.

Кунак сые мулдан, урын түрдән —
Элеккечә монда барысы.
Туган нигез — ярлы хәләл байлык,
Әти-әниемнең мирасы.

## АВЫЛ КЫЗЫ

Шәһәр тормышына ияләштем,
Миннән бәхетлерәк юк сыман, –
Тик барыбер ялантәпи йөргән
Авылым урамнарын юксынам.

Телефоннан була хәл белешеп,
Хат язалам, әгәр теләсәм...
Җаннарыма тынгы тапмыйм барыбер,
Бер авылга кайтып килмәсәм.

Телләр беләм, илләр-җирләр гизәм –
Заманадан тормыйм калышып,
Тик гомергә керде күңелемә
Урман шавы, чишмә тавышы.

«Шәһәр кызы түгелмени син?» – дип,
Ник шулкадәр хәйран каласың?
Асылына алып кайта язлар
Җирсеп яшәр адәм баласын.

## МИН — ТУГАН ЯК БАЛАСЫ

Туган йортта мин — әнкәмнең
Газиз йөрәк парәсе;
Чит туфракка аяк баскач —
Татарстан баласы.

Үземнеке була Мөслим,
Баулысы, Тәтеше дә.
Чит җирләрдә туганың күк
Үз ягың кешесе дә.

Сагынам Мишә талларын,
Ямьле Ык буйларын да,
Чупырдап үскән булсам да
Кесмәсем суларында.

Туган җир — газиз Ватанның
Һәр авылы, каласы.
Мин — халкымның бер бөртеге —
Татарстан баласы.

## БӨЕКЛӘР

Язлар белән кайтты үз йортына
Бөркет кебек мәгъруР биш улы.
Ватан йөрәгендә урын алды
Һәйкәл-сыннар булып бу юлы.

Шушы туфрактан бит милләтемнең
Гали улларының күпмесе!
Даһиларның, галим-остазларның
Бу бөркетләр бары бишесе.

Тукай, Камал, Гомәр, Гарифына,
Мөхәммәткә баглап хөрмәтен,
Арчалылар шулай бөекләде
Туган халкын, газиз милләтен.

## ОЧРАШУ ҖЫРЫ

Сагынып кайттыгызмы, сабакташлар,
Онытылмас мәктәп елларын?
Бер узыйк дип Хәтер урамыннан
Үсмер чакның йөгерек юлларын.

Хатирәләр – күңел түрләрендә,
Серләшербез таңга кадәрле.
Бүген бездә Яшьлек үзе кунак,
Бу очрашу шуңа кадерле.

Сау гынамы, газиз укытучым,
Таныйсыңмы мине, юк микән?
Җан сыкравы булып, кемдер дәште:
«Кайберәүләр инде юк күптән...»

Бәхилләшмик, бары саубуллашыйк,
Аерылышып киткән чагында...
Бу изге йорт, туган нигез кебек,
Очраштырсын безне тагын да.

Нигезен җуйган – кайтыр юлын җуйган!
Хәтер торсын юллар сагында.

## БЕЛЕМ АЛИҺӘСЕ — ӘЛИФБА

Балачагым чыкса кулын изәп,
«Кил монда-а!» — дип, барыр юлыма,
Вакыт чиген кичәр тылсым итеп,
Әлифбамны алам кулыма.

«Качыш-качыш» уйныйм... Өлкән уйлар
Бүген мине эзләп тапмасын.
Ак бантиклы нәни кызчык булып
Ачам балачакның капкасын.

...Әлифбамнан карый таныш йөзләр,
Сагынгандыр мине алар да.
Тик дәшмиләр, үз-үзеңне онытып
Йөрдең дигән кебек кайларда.

Әнә Муса тауда чана шуа,
Каз ашата үскән кыз Наза.
Дамир душта, Бәшир балык тота,
Хаҗи апасына хат яза.

Чү! Әминә нигә елый тагын
Куе таллы елга буенда?
...Читтән генә кызыгып карап торам
Сабый күңелем дәшкән уенга:
— Куян, син кайда?
— Яшел тугайда.
— Куян, син кайда?
— Калын урманда.
— Куян, син кайда?
— Карлы буранда...

Хәтер сурәтләре җанлана да,
Өзәм чикләвеген, миләшен.
Авыз итәм Бану биргән балны,
Әни салган балан бәлешен.

...Белем дигән изге мәгарәнең
Син, Әлифбам, алтын ачкычы;
Һәр хәрефең, һәр иҗегең гүя
Тормыш үрләренең баскычы.

Галимгә дә, гади эшчегә дә
«А»дан «Я»га сабак биргәнсең.
Сабыйлыктан безне зур дөньяга
Син җитәкләп алып кергәнсең.

Рәхмәт сиңа, гыйлем алиһәсе –
Туган телнең тугры сакчысы.
Әлифба ул – туган телдәй берәү!
Булмый начары йә яхшысы.

...Белсәм дә мин тәүге сентябрьгә
Кабат кайту мөмкин түгелен,
Изге китап – Әлифбамны ачам,
Сафландырыр өчен күңелем.

## ГАЛӘМИ СӘЛАМ

Арча сөйли! Шәфәкъ алсуланып,
Таң туганда газиз җиремдә,
Башлап сүзен изге теләкләрдән,
Аваз сала Тукай телендә.

Тәүге сәлам авыл кешесенә,
Таңнан торучыга һәр көнне;
Терлекчегә, иген игүчегә —
Сыйлы итүчегә һәркемне.

Хәерле көн хезмәт юлларыннан
Бергә атлаучыга ил белән;
Алны-ялны белми чабучыга,
Ашын табучыга тир белән.

Иман бирсен намазлыкка баскан
Уңай нияттәге җаннарга,
Тәмле төшләр күрсен нарасыйлар,
Изрәп йоклаганда таңнарда.

Гыйлем эстәүчегә — тел ачкычы,
Мөгаллимгә — зиһен, сабырлык;
Адашканның ачсын күңел күзен,
Туры юлны эзләп табарлык.

Әткәй-әнкәйләргә килеп торсын
Балаларның изге хәбәре,
Җитәкчеләр илгә игелек кылсын
Кулларыннан килгән кадәрле...

Арча сөйли! Сөйләп кенә калмый,
Сүзе күчә изге гамәлгә;
Киләчәкне сайлап, эфир аша
Тавыш бирә бөтен галәмгә.

## ЯШӘҮ ГИМНЫ

Ачыгыз тәрәзәләрне,
Язгы моң тулсын өйгә;
Кушылсын күңел оркестры
Дөнья җырлаган көйгә.

Яшьниләр ләйсән тамчылар –
Яңгырның сеңелләре;
Керфеген ача бөреләр,
Тулышып күңелләре.

Өйрәнчек җил көй чыгара,
Чиртеп кояш нурына;
Чыпчыклар алкыш яудыра
Сыерчыклар хорына.

Сабый бала аваз сала
Бүген тәүге язына...
Каурый болыт белән күккә
Яшәү гимны языла.

## КАРДӘШЛЕКНЕ САКЛЫЙК ЙӨРӘКТӘ

Бер анадан туган булмасак та,
Бер туфракта туып үстек без;
Туган авыл күкрәгеннән типкән
Чишмәләрнең суын эчтек без.

Очрашабыз хәзер сирәк кенә,
Эчәр сулар читтә булганга.
Авылым хәбәрләре җанга дәва,
Сагынулардан күңел тулганда.

Бер сукмактан тәпи атлап киттек,
Бер мәктәптә гыйлем алдык без;
Нинди генә үрләр яуласак та,
Авылдашлар булып калдык без.

Очрашабыз хәзер сирәк кенә,
Җыяр ризык читтә булганга.
Авылым һавалары җанга дәва,
Сагынулардан күңел тулганда.

Туган нигез җылысына төреп,
Кардәшлекне саклыйк йөрәктә.
Үз-үзенә кайта һәрберебез
Туган якта, туган төбәктә.

Очрашабыз хәзер сирәк кенә,
Тәкъдиребез читтә булганга.
Авылым кешеләре — җанга дәва,
Сагынулардан күңел тулганда.

# КОШЛАР КАЙТА

Әллә үтте кыр казлары,
Кыйгак-кыйгак сәлам биреп,
Әллә күктә ефәк тасма
Җилфердәвен калдым күреп.

Киек казлар, парын табып,
Оя кора туган якта.
Нәсел җебен ялгар өчен,
Туган якка кошлар кайта.

Санарга да өлгермәдем –
Күмелделәр офыкларга,
Киек коштай бәйсез җанны
Җилкендереп очышларга.

Әйтерсең лә кыр казлары
Җырлап үтте турыбыздан:
«Өзелмәсен тамырыгыз
Туган-үскән ягыбыздан!
Туган-үскән ягыбыздан!»

## НӘҮРУЗ КИЛӘ

Көн белән Төн бил алышыр вакыт җитте,
Елый-елый, кышкы юллар агып китте.
Нәүруз килә! Ил-йортыма Нәүруз килә!
Көлтә-көлтә шатлык чәчеп, Кояш көлә.

Җир-анабыз шифа-дымга туенсын, дип,
Бар тереклек бәрәкәттә коенсын, дип,
Изге теләк әйтә-әйтә, бала-чага
Өйдән өйгә кереп йөри йөгерә-чаба.

Яр буенда күмәкләшеп казан асыйк,
Уңдырышлы еллар теләп, бәйрәм ясыйк.
Арыш, бодай, арпа, тары – бар да уңсын,
Куанычлар сумәләктәй* үргеп** торсын.

Тулган Аймы мул табынга әллә төшкән? –
Түм-түгәрәк тәбикмәкләр уңып пешкән.
Кар өстендә бии-бии учак яна,
Узган елгы кайгыларны салыйк аңа.

---

**Сумәләк* – Нәүруздә төрки халыкларда шыттырылган бодай үрентесен ваклап, аңа он, май салып, тәүлек буе пешереп әзерләнгән хәлвә.

***Үргү* – үрчү, күбәю, ишәю.

Нәүруз килә, күк күкрәтеп, яшьнәп килә,
Зәңгәркүзкәй* – Яз сылуы балкып көлә.
Көн буена уен-көлке тынып тормый,
Яшь-җилкенчәк учак аша сикереп уйный.

Көн белән Төн кул бирешер сәгать җитә,
Бар кешеләр, өмет баглап, язны көтә.
Нәүруз килә! Ил-йортыма Нәүруз килә!
Көр күңелле Яңа елны алып килә.

---

*Зәңгәркүз исеме белән борынгы заманнарда Нәүруздә иң оста җырлаучы кызны атаганнар. Аңа, биек урынга менеп, махсус йола җыры башкарып, Язны чакыру хокукы бирелгән.

## ЯФРАК ГОМЕРЕ

Кыенсынма, кил, яшь яфрак,
Учыма куй учыңны;
Лепердәми генә тыңла
Язмышың юраучыны.

Гомер фалыңны ачармын,
Уч төпләреңә карап;
Әйтеп бирермен теләсәң,
Киләчәгеңне, юрап.

Сандугачлар сайраганда,
Моң тибрәтеп талларда,
Чык тамчысы булып тамар
Күз яшьләрең таңнарда.

Җәйге челлә ышыкланыр
Күләгәң салкынына,
Яңгырлар елар сыенып
Ямь-яшел ялкыныңа.

Шаярту гына булса да,
Хаклык бар минем сүздә:
Гафу ит... гомер сызыгың
Туктала шушы көздә...

Каяндыр чыгып, көчле җил
Ярсып-давыллап алды.
...Ямь-яшь яфрак үзелде дә
Иңемә башын салды.

## АЧУЛАНМА, ШӘҺӘР...

Асфальт сулап үскән таш каланы
Зәһәр кояш тормый кызганып.
Мөмкин булса, йортлар безнең арттан
Китәр иде әллә кузгалып.

Бәлзәмләнгән һава тынга каба –
Июнь җилләренең исе ул.
Шигырь дәфтәремә чәчәк салам –
Бу бәхетле көннең төсе ул.

Бала-чага ялантәпи чаба,
Яшь-җилкенчәк туймый шаярып.
Җәйгә чыккач, хәтта карт-корылар
Таягына тормый таянып.

Хисләрнең бер бәйдән чыгар көнен,
Беләсең бит инде, бик көттек.
Калдырабыз җәйге ятимлектә,
Ачуланма, шәһәр, без киттек.

## САФЛАНУ

Тормыш шау-шуыннан җан талкынып,
Эшем төшкән чакта кулымнан,
Җитәкләшеп ялгызлыгым белән,
Кереп киттем урман юлыннан.

Изге мәгарәгә иңгән кебек,
Убылды уй серле упкынга.
Бер мизгелдә дөнья мәүласыннан*
Әверелдем гүя тоткынга.

Сихерләнгән кебек түбән төштем
Кемдер баскыч уйган сукмактан.
Урман ияләре — агач сыннар —
Кулын суза миңа як-яктан.

Кыңгыраулар каршы йөгереп чыга,
Күбәләкләр уйнап очына;
Каен җиләкләре, тәгәрәшеп,
Үзе өзелеп төшә учыма.

Томырылып ята тау иркендә
Куптарылган тамыр-гөрзиләр.
Тынычлыкны безнең бозмасмы дип,
Шыпырт кына мине күзлиләр.

Аулак дөнья. Монда вәхшиләрчә
Кул салмаган әле кыргыйлык.
Бу сәйранга җирнең куеныннан
Чишмә чыккан әнә ургылып.

---

**Мәүла* — ия, хуҗа.

Тау чишмәсе... саф уйларын уйлап,
Кая ага болай атлыгып?
Сәждә китеп, тәкатьсезлек белән
Тере суын эчтем йотлыгып.

Әй Табигать, кыйпылчыгың итеп
Тойдым шунда кабат үземне;
Җиләс җилгә куйдым йөзләремне,
Рәхәтлектән йомып күземне.

Туган йортка кайткан кебек булдым,
Чын бәхеткә бүген тиендем.
Үз Җиремнең — үз өемнең — мине
Чит итмәвен аңлап сөендем.

Кайтып киләм кире чынбарлыкка,
Яңа туган кебек сафланып.
Чытлыкланып, сабый хыялларым
Янәшәмнән йөгерә шатланып.

## ЗӘҢГӘР КҮЛДӘ

Табигатьнең, кызлар күңеледәй,
Дәрт ташыган гүзәл мизгеле.
Җәй сеңгән дә көзләр кочагына,
Аерылам дими тиз генә.

Күл өстендә әллә яфрак йөзә,
Әллә минем хисләр тирбәлә...
Күңелемдә җем-җем рәшә уйный,
Төсләр алып якын-тирәдән.

Исем китеп, сине тыңлап барам:
«Шагыйрьнеке», ахры, йөрәгең.
«Бу көзге көн, якын дустым, — дисең, —
Истәлеккә сиңа бүләгем...»

Зәңгәр күлдән чыккан чишмәләрнең
Учыбызга алып салкынын,
Сүндермәкче булдык инде әллә
Йөзебезгә капкан ялкынны.

Сабыйларча беркатлы мин бүген,
Үз-үземнән хәтта оялам:
Әйтерсең лә чишмә суы түгел,
Шәраб эчкән сыман тоелам.

Дөнья малларына алыштырмас
Бәхет бүләк иттең, мең рәхмәт.
Сулап туймас көзге бәлзәм-һава
Янган йөрәкләргә, һай, рәхәт!

Үзе шатлык, үзе сагыш җанда!
Җәйләр сула, көзләр – чәчәктә.
Тәүге тапкыр көзгә гашыйк булдым,
Хәйран гомер җирдә яшәп тә.

«Яшәү – бәх-е-ет!» – диеп, бар дөньяга
Килгән иде сөрән саласым,
Баеп барган кояш куркыр диеп,
Әйттем бары тәһлил-догасын.

Югарыда кошлар аваз салды,
Ерак юлга дәшеп бер-берсен...
Саубуллашу җырында да хәтта
Шатлык ишетелә әйтерсең!

Әйтерсең лә яшьлек үзе кайткан
Кунак булып көзләр иленә...
Озатып калды безне Зәңгәр күлдә,
Чиккән шәлен салып иңенә.

## ТУГАН-ҮСКӘН ҖИРЛӘРДӘ

Җылы яңгыр юып үткән
Җәяүле басу юлын.
Кочак җәеп каршы ала
Безне хәтфәдәй болын.

Өзмик әйдә чәчәкләрне,
Үссеннәр матур булып;
Уйнасыннар күбәләкләр,
Гөл-чәчәкләргә кунып.

Тирбәләләр талгын җилдә,
Ямь биреп Туган җиргә.
Бүләк итеп ал гөлләрне
Болыны белән бергә.

Дөнья ямьле кояш белән,
Болын яме — гөлләрдә.
Күкләр аяз, күңелдә яз
Туган-үскән җирләрдә.

## СОКЛАНУ

Урманга күз-рәссам килгән:
Һәр яфракның үз төсе.
Пәрәвез ятьмәләрендә
Тирбәлә гөмбә исе.

Өрәңгедә күпме йолдыз, –
Санадым хәйран калып.
Күлдә йөзә тал яфрагы,
Әйтерсең алтын балык.

Мин аяк атлаган саен
Кыштырдый чуар келәм.
Кыштырдамый – сөйләшә ул
Яфраклар теле белән.

## КӨЗ ҺӘМ БЕЗ

Кыраугa биреште көз яме,
Кышларга тапшырды язмышын.
Җирләрнең куйнына баш салып,
Көз ала ахыргы сулышын.

Көзләрнең гомере бер түгел,
Китәр дә кайтыр ул әйләнеп.
Безләрнең язмышы торган күк
Пәрәвез җебенә бәйләнеп.

# ТӘҮГЕ КАР

Дөнья ап-ак, күңел хуш,
Сагындырган икән кыш.
Тәрәзәгә күзең сал,
Тәүге карны күреп кал.

Карлар төшә серләшеп,
Безгә шатлык өләшеп.
Үтә гомер, шул карларның
Пакьлегеннән көнләшеп.

Юләрем син, дип көлмә,
Бу бит ялган кар, димә, —
Көзнең көне санаулы,
Кышка да күп калмады.

Күмеп кара төсләрне,
Назлап якты хисләрне,
Күкләрдән иңә аклык,
Безләргә теләп сафлык.

## ИСТИРАХӘТ

Ал чаңгыңны, чык син әйдә
Казансу буйларына,
Котлап яңа яуган карны,
Бас чаңгы юлларына.

Үз-үземә фәрман бирдем
Җиңәргә ялкаулыкны,
Гомерлек юлдаш итәргә
Ыспай буйлы саулыкны.

Җиле дә исми каршыга,
Суыгы да чамалы.
Монда бар да үз ишләрем:
Чаңгылы да чаналы.

Җиллерәкләр җилсен диеп,
Туктап юл сапма, чаңгым!
Синең, кыргый җилне җигеп,
Эз ярып барыр чагың.

Уйнак җанны биләп ала
Йөгәнсез иркенлекләр;
Суласаң, сулышка каба
Саф һавалы киңлекләр.

Тездән көрткә чумып кала
Сузан буйлы камышлар.
Баш кагып уза елмаеп
Узган елгы танышлар.

Тау битендә, шау-гөр килеп,
Бала-чага кайнаша;
Көртнең мамыгын туздырып,
Ике маэмай уйнаша.

Сипкелле йөзенә кояш
Болыт-пәрәнҗә япкан.
Ни арада кайтыр юлга
Зәңгәр кич кырын яткан?

Пар эзләр кала сызгырып
Чаңгылар табаныннан.
Яшьлектән килеп, бураннар
Шул эздән табар сыман.

# Алмагач бураны

*Болыт артларында кояш бар,*
*Ярсып алгач, сулар бер тына.*
*Соңгы сүзне әйтмик ашыгып,*
*Сабыр итик сөю хакына.*

## МИН БӘХЕТЛЕ БУЛЫР ӨЧЕН ТУДЫМ!

Бу дөньяга күпме кеше килгән,
Бардыр тагын күпме туасы.
Мин – әнкәмнең Ходай сөеп биргән
Газизләрдән газиз баласы.

Гомеремнең серле китабында
Булыр димим битләр ак кына.
Сындырыплар сыный бит ул язмыш,
Ә башлардан сыйпый чак кына.

Җил-яңгырлар тими үстем шул мин,
Давылларга ни хәл чыдармын?
Ялгышып та берүк рәнҗетмәгез,
Иркә гөлдәй юкса сулырмын.

Сөю-назга сусап туйганым юк,
Нәкъ нарасый сабый инде мин.
Бу дөньяга елар өчен түгел,
Көлеп яшәр өчен килдем мин.

Гомер китабымның соңгы битен
Ашыкмаска иде ябарга...
Мин бәхетле булыр өчен тудым
Һәм Берәүнең бәхете булырга.

## МӘҢГЕЛЕК ҖЫРЫМ БУЛ!

Бер матур җыр булып килдең син,
Килдең дә шатлыкка урадың.
Бар дөньям сагышлы күз иде –
Син мине күзләрдән урладың.

Тылсымлы җыр булып килдең син,
Үз җырым артыннан юл алам.
Ялгызлык тапмасын эзләп тә –
Мәхәббәт куенында югалам.

Бер серле җыр булып килдең син,
Килдең син көтмәгән яклардан.
Җырымны йөртермен йөрәктә,
Җырлармын яшерми ятлардан.

Сагышлы җыр булып килдең син,
Моңнарың сирпелде моңыма.
Озат син мәңгелек җыр булып
Бәхетле гомерем соңына.

## ПАРЛЫ ГОМЕР

Зәңгәр күктә уйный пар күгәрчен,
Пар аккошлар йөзә күлләрдә.
Бер-берсенә сыенып үссә генә
Шаулап чәчәк ата гөлләр дә.

Сыерчыклар бала очырганда,
Ни куаныч, күзләр тимәсен!
Кошларга да әти-әни булу
Күтеп алган шатлык, күрәсең.

Табигатьтә язын — туйлар чоры,
Һәр бәхетле җанның пары бар...
Алтын көзгә керә җитәкләшеп
Тигез гомер иткән парлылар...

Парлыларның сабырлыгын язмыш
Сыный икән әйдә сынасын.
Так җан итеп кенә яратмасын
Бу дөньяга адәм баласын.
Парсыз булу бәхетсезлек түгел,
Парлы ялгыз булу язмасын.

## СИҢА ТАБА

Рәхәт миңа синең янда,
Бәхет кошы сайрый җанда.
Бәйдә торткан тойгыларым
Кайнарланып уйный канда.

Буйсынмаска тели хисләр,
Ирек куйсам, йөрәк нишләр?
Йөгәненнән чыкса бу дәрт,
Туктатырга җитмәс көчләр.

Без бит түгел унсигездә,
Керәбез шул инде көзгә...
Син әйтәсең: «Минем сөю
Җитәрлек, — дип, — икебезгә».

Ни булса да булыр алда,
Сиңа таба чыгам юлга...
Теләсәң — ас, теләсәң — кис:
Тапшырылам синең кулга!

# ГӨЛБИШЕК

Сайлап алып матур төсләр
Хыялым түрләреннән,
Үрим әле гүзәл бишек
Сөюем гөлләреннән.

Бәйләм-бәйләм гөлләр китер,
Үрелсен хисләребез.
Аллы-гөлле хыялларга
Күмелсен кичләребез.

Тирбәлербез икәү бергә
Мәхәббәт бишегендә.
Мине сөю, бары сөю
Яшәтә яшьлегемдә.

Берәүгә дә бирмим сине –
Тапмадым югалтырга.
Ирек куймам икәү үргән
Хисләрне чуалтырга!

## ГОМЕР ЮЛЫН УЗЫЙК БЕРГӘЛӘП

Сөю аятьләрен көйлим әле,
Күзләреңнән алмый күзләрем.
Күпме күзләр, йөзләр арасыннан
Мин бит сине озак эзләдем.

Бу самими җаным мең сәдәпле,
Берәүгә дә күңелем чишмәдем.
Наз таҗымны кидерермен диеп,
Мин тик сине көтеп яшәдем.

Учларыңны куй син учларыма,
Йөрәгемә күчсен җылысы.
Күпме була яшь аралаш көлеп,
Бәхетемнән килә елыйсы.

Чакматаштай, җанга ут тергезгәч,
Сүнмә өмет күген телгәләп.
Минутларны, сәгатьләрне түгел,
Гомерләрне кичик бергәләп.

## КУШЫЛЫЙК КУШ КАЕННАРДАЙ

Мин бит сине, үзем теләп,
Ходайдан сорап алдым.
Табуын таптым да, никтер
Сөюдән куркып калдым.
Алып кит мине, урлап кит,
Бернигә дә карама.
Үрмә гөлдәй җанга сарган
Сагышлардан арала.

Дөньям нурларга күмелде,
Син үпкәч күзләремнән.
Күкләрдән көткән бәхетне
Таптым җир йөзләреннән.
Карашларың – төпсез упкын,
Ә хисләрең – өермә.
Кушылыйк куш каеннардай,
Аерылмаска гомергә.

Йөрәгеңдә урын тапсаң,
Синеке генә булам.
Теләсәң, беркем белмәгән
Яшерен сер булып калам.
Тик синең өчен сакладым
Саф хисләремне, иркәм.
Әйдә, дисәң, синең белән
Җир читенә дә китәм.

## СИН — ЙӨРӘГЕ МИНЕМ СӨЮЕМНЕҢ

Нинди тылсым бәйләп тора икән
Күңел белән күңел арасын?
Ераккарак синнән киткән саен
Якыная гына барасың.

Төннәремнең сихри балкышы син,
Көннәремне ямьләр кояшым.
Син югалсаң, кояш тотылгандай,
Сагыш каплар Сөю дөньясын.

Гомер буе бәләм кебек сине,
Югалтырга берүк язмасын.
Уйнап кына сүз башлаган идем,
Сөю белән алдым «җәзасын».

Син — йөрәге минем сөюемнең,
Син — тибеше минем йөрәкнең.
Яшәү дигән бөек могҗизаны
Кадерләргә мине өйрәттең.

## САГЫНУ

Эшең сәбәп итеп
Югаласың китеп,
Сагышланып сулсын дисеңме?
Бүлмәмдәге гөлләр
Башын түбән иде,
Күтәралмый сагыну хисемне.

Бергә чакның кадерен
Аңлар өчен, бәгърем,
Янып-көю кирәк дисеңме?
Котыптагы бозлар
Эреп бетәр иде,
Илтеп салсам сагыну хисемне.

Беләм, күпкә түгел,
Тик тарыга күңел –
Сабыр итү җиңел дисеңме?
Яратам дип әйтмә,
Көч-хәл җиңеп торам
Иләсләнгән сагыну хисемне.

## ЧИТТӘН ТОРЫП

Бүген тагын китеп бардың менә...
Ерак юлга сине озаттым.
Аерылганда, күзләремнән үбеп,
Еламаска кушып юаттың.

Китүләрең булса бөтенләйгә,
Кайтаралмам сине елап та.
Күрешү көнен якынайтыр өчен,
Йөрәгеңдә булыйм еракта.

Өйнең – яме, ризыкның юк тәме,
Сагыну белән үтә көннәрем.
Тәрәзәдән күзем алмый көтәм
Йөгерә-йөгерә кайтып кергәнең.

Синең белән өйгә Бәхет кайта,
Куанычлар, күңел бәйрәме...
Күп тә үтми – ник соң Сөюебез
Бер ятимгә кала әйләнеп?

Өйнең – яме, ризыкның юк тәме,
Көч-хәл аттырабыз таңнарны...
Без соң әллә читтән торып кына
Сөешергә туган җаннармы?

## ЯЛГЫЗЛАРГА

Бар ул, беләм, ялгыз моңланганнар,
Сагышларда ялгыз янганнар;
Үз насыйбын — җаны теләгәнне
Көтеп-көтеп, ялгыз калганнар.

Юктыр димим парлар кавышканда
Сиздермичә яшен сөрткәннәр;
Так яраткан өчен, язмышына
Җан түрендә рәнҗү йөрткәннәр.

Азмы әллә үзе парлы булып,
Ялгызлыкта гомер иткәннәр!
Сез алардан күпкә бәхетлерәк,
Гомер буе тиңен көткәннәр.

Кызганмагыз, дисез, ник кызганыйм,
Бәхетле без, дисез, ышанам.
Сабырлыкка сезнең мин таң калам,
Горурлыкка сезнең сокланам.

## АЕРЫЛУ

Янәшәдән өчәү атлап килә,
Ап-ак карда кала өч пар эз.
Тукталдылар эзләр аерылырга –
Өзгәләнмә, йөрәк, зинһар, түз.

Нәни кызчык карый әтисенә,
Мөлдерәтеп яшьле күзләрен.
Телсез калган ата, өнсез калган, –
Әйтә алмый соңгы сүзләрен.

Кысып алып кызын күкрәгенә,
Үпте бары тозлы күзеннән.
Үзенең дә ачы күз яшьләре
Тәгәрәде ап-ак йөзеннән.

Мәхәббәт һәм нәфрәт ник янәшә?
Никах вәгъдәләре, сез кайда? –
Җавабыгыз күптән әзер дә бит,
Тик сабыйга моннан ни файда?

Вакыт оныттырыр кайгыгызны,
Сез беразга гына түзегез...
Чит кешегә: «Әти, әтием», – дип
Дәшә алыр микән кызыгыз?

Кызчык үсәр, үсәр үги булып
(Булмый үги ир дә, хатын да!).
Бәхетлерәк бәхет сайлап йөреп,
Оныткансыз бала хакында.

Бар галәмгә ярсып кычкырсаң да
Үзгәрми шул берни. Йөрәк, түз...
Башка юлдан китте аерылып
Ике пар эз — ана белән кыз.

## АҢЛАШЫЙК

Син дә парлы, мин дә парлы,
Матур гына гөрли тормыш.
Ник соң моңлы минем җырлар,
Синең йөздә нигә сагыш?

Аңлашмыйча аерылыштык,
Араларда — дистә еллар.
Үпкә саклап яшәү авыр:
Бер очрашсын иде юллар.

Бәгырьләрдән өзелеп төшкән
Багалмалар бигрәк татлы.
Исемеңне йөртә улым,
Синең кызың минем атлы.

Аккан сулар кире кайтмас,
Ерак калды инде яшьлек.
Мин үземне гафу иттем,
Соң димәсәң, бәхилләшик.

## ЧЫНЛАП ШАЯРУ

Җитәр инде, күп еладым,
Үпкәләткән чагында.
Бүген берни булмагандай
Басып торам яныңда.

Елмаям шул, нигә әле
Гаҗәпләнеп карыйсың?
Син бит минем бер тамчы да
Күз яшемә тормыйсың!

Беләсеңме, гафу итәм
Барысы-барысы өчен дә.
Син әлегә чит түгелсең,
Түгел якын кешем дә.

Кызганырга калды бары
Сыкрап үткән гомерләр...
Сукмагыбыз гел янәшә,
Аерылды күңелләр...

## ҮКЕНЕЧ

*(Бер егет зары)*

Уйларның агышлары –
Кайларга барышлары?
Хәтер кайта үткәннәргә нидер юксынып.
Балачак инде ерак,
Күз яшьсез генә елап,
Әти, диеп бер әйтергә калды ымсынып.

Уйларның агышлары –
Юктыр тукталышлары…
Убылса да үксез җанга текә дөньясы.
Әнкәйләр – әнкәйләрчә,
Киләә, ир-егетләрчә,
Әткәйнең нык маңгаена маңгай куясы.

Уйларның агышлары –
Мең төсле балкышлары…
Киләчәкне кайтам урап хыял буйлатып.
Әти булу бәхетен,
Бала сөю ләззәтен
Күңелемдә үчти-үчти барам уйнатып.

## КИТЕК БӘХЕТ

Бер-беребезне тагын үпкәләттек,
Соңгы чиккә барып җиттек бүген.
Түм-түгәрәк иде дөньялары –
Дөньяларның чите китек бүген.

Син – бер якка, мин икенче якка
Саубуллашмый гына киттек бүген.
Төне кара, йолдызлары сүнгән,
Аебызның чите китек бүген.

Нәүмизләнеп күзгә карап торган
Мәхәббәтне ятим иттек бүген.
Синең белән минем юләрлектән
Бәхетебезнең чите китек бүген.

## ТАМАША

Пәрдә ачыла, утлар сүнәләр,
Җансыз курчаклар терелә шулчак.
Уйлап карасаң, тормыш – зур сәхнә,
Синең кулыңда мин – җанлы курчак.

Пәрдә ябыла, утлар кабына.
Монда мәхәббәт җиңә һаман да.
Сәхнәдә гомер алдан язылган,
Ә минем язмыш – синең кулыңда.

Тормыш-тамаша гел шулай барса,
Аны, үзгәртеп, үзем язармын.
Синең урынга, әй төп уйнаучым,
Башка берәүне эзләп табармын.

## КИТҮ

Китәм инде. Телисеңме-юкмы...
Күз яшьләре, зинһар, кирәкми.
Буш биштәрем асып чыгып китәм,
Учларыма кысып йөрәкне.

Озатырга чыкма, монысы артык –
Әйтер сүзләр бар да әйтелгән;
Яхшысы да узган, яманы да,
Сабыр йомгаклары сүтелгән.

Шөбһәләнмә, ачу төяп китмим,
Андый авыр йөкне алалмыйм.
Исемем дәшсәң, бәлки, борылырмын,
Тик яныңда бүтән калалмыйм.

Гафу итәм, бәхет теләп китәм...
Җылы эзләремә кар ятар,
Минем сөю булып кояш баер,
Алсуланып көн дә таң атар.

Биштәрем буш... Дүрт ягым да – кыйбла.

## ХӘТӘР ТӨШ

Пардан ап-ак күлмәк кигәнбез,
Ак атларда икәү киләбез.
Бөтен дөнья никтер ак икән,
Үзе ташу аккан чак икән.

Елгада боз чатнап ярыла,
Син – ташуның аргы ягында.
Бата-чума боздан атладым,
Чыгалмады ярга атларым.

Дәшеп карыйм – чыкмый тавышым,
Барыр юлларымны ялгыштым.
Янәшәдә үзең, янымда,
Тик минеке түгел һаман да.

Ак томанга кереп югалдың,
Юлларыңа ятып еладым...
Ярый әле тышта кыш икән,
Югалтулар бары төш икән.

## БЕРГӘ БУЛУЛАРГА НИ ҖИТӘ?

Очраштырды безне тәкъдирме,
Кисештерде барыр юлларны?
Бәйләде ул чәчкә чәчләрне,
Кичегез, дип, ут һәм суларны.

Тормыш сукмаклары борма-борма,
Язмыш чатларында ни көтә?
Авыр сынауларга бирешмичә,
Бергә булуларга ни җитә?

Ятлар куенында – гөлбакча,
Барып керсәң – куе карурман.
Карурманга кереп адашкач,
Чыгар юлны кем соң табалган?

Болыт артларында кояш бар,
Ярсып алгач, сулар бер тына.
Соңгы сүзне әйтмик ашыгып,
Сабыр итик сөю хакына.

## БЕЗНЕҢ СӨЮ

Кайчакларда бер дә юкка гына
Куйсаң хаксыз сүзләр әйткәләп,
Мин түгел ул, шулай, сулык-сулык,
Безнең сөю елый үпкәләп.

Көлүеңдә, атлап йөрүеңдә
Разыйлыгың китсә чагылып,
Мин түгел ул, йөри яннарында
Безнең сөю, канат кагынып.

## ЙОКЛЫЙ АЛМЫЙЛАР

«Яшең отыры олыгая бара,
Гашыйк булма, адәм көлдереп.
Харап, әгәр чыкса яманатың,
Кеше телләренә керерлек!»

Монысын Акыл әйтте. Катгый итеп.
Хис пышылдый башка төрлерәк:
«Синең әле чәчәк кебек чагың,
Дәртең тора ташып-мөлдерәп...»

Шигырь укый ханым. Миндәрендә —
Шагыйрь бүләк иткән китабы.
Янәшәдән, мышнап, ире дәште:
«Сүндер утны, йоклап киталмыйм».

## БЕРГӘ ЧАКНЫҢ КАДЕРЕН БЕЛИК

Бер-бер артлы, җепкә тезелгәндәй,
Көннәр түгел, безнең гомер үтә.
Туар таңның серле иртәсендә,
Белмим, кайгы,
Белмим, шатлык,
Белмим, тагын ниләр көтә?

Мин бит — сине, ә син мине таптың,
Кадерләрен белик бергә чакның.
Бергә чакның кадерләрен белик, —
Бергә елыйк әйдә, бергә көлик.

Ялгызымны бүген калдырма син,
Кара сөю тулы күзләремә.
Иртәгә дә көн бар әле димә!
Бүген шаярт,
Бүген ярат,
Бүген күм син назлы сүзләреңә.

Ике йөрәк бергә тибәр өчен,
Дөнья ваклыклары түгел киртә.
Тәрәзәгә шаян җилләр булып,
Әллә яшьлек,
Әллә бәхет,
Әллә узган гомер чиртә.

## ЫШАНАМ

Тәрәзәгә карап уйга талам:
Урамнарда салкын кыш һаман.
Апрель керми, карлар эреми, дисез,
Озакламас язлар, ышанам.

Бу табигать үзе бер могҗиза:
Быел көзләр җәйгә охшаган.
Җәй дә уза, гомерләр дә, дисез,
Минем йөрәк әле яшь һаман.

Пар сыерчык бала чыгарсын дип
Элгән ояларым бушаган...
Вакыт әрәм итмә, көтмә, дисез,
Килер сөю, килер, ышанам.

## КҮҢЕЛЕМНӘН — КҮҢЕЛЕҢӘ

Күңелемнән – күңеләңә
Җырларымнан салам сукмак,
Гөл-чәчәкле аның як-ягы.
Тукталыйк та Сөю дигән
Могҗизалы аланнарга,
Өзик чәчәкләрнең акларын.

Синең белән миннән башка
Бу сукмакны беркем белмәс,
Булсын әле уртак серебез.
Онытып бар дөньяларны,
Санамыйча минутларны,
Бер яшьлеккә кайтып килербез.

Күмелеп гөл-чәчәкләргә,
Бәхет үзе яши монда,
Безне көтеп серле аланда.
Күңелеңнән күңелемә
Табарсың дип сукмакларны,
Өметемне өзмим һаман да.

# МӘХӘББӘТ ҖИМЕШЕ

Бу ни хәл бу? Көз җитсә дә,
Шау чәчәктә, карачы,
Хыялымның бакчасында
Бер мәхәббәт агачы.

Берәү генә, янып тора,
Һай, җимеше югары.
Көз җитсә дә, кыш кермәгән,
Өмет өзмим, юк әле.

Җан сусавын басалмагач,
Оныт шуны димә син.
Бәлки, беркөн учларыма
Үзе төшәр, белмәссең.

Күңелемнең бар җылысын
Аңа саклап йөретәм.
Ул бит Сөю агачында
Өзелмәгән Өметем.

# КЫРГЫЙ АЛМА

Алма аттың миңа — тоталмадым,
Яннарымнан барды тәгәрәп.
Ник ымсындым, юкса дөньяларым
Алмалардай иде түгәрәк?

Тукталды да калды серле алма,
Адымнарым шулчак ялгышты…
Иелеп алдым гүя учларыма
Мин татырга тиеш язмышны.

Кыргый алма… Соң өлгергән алма…
Кирәк иде микән өзәргә?
Ачы алма сутын сорый күңел,
Кереп барган мәлдә көзләргә.

Очрадыңмы көзге бакчаларда
Мине үкенечкә салырга.
Язмышыма язган, ахры, миңа
Кыргый алмаң булып калырга.

Алма аттың миңа… тоталмадым…

## ЧАЛМА ЧӘЧӘК

Бәхет бүләк иттең миңа, гөлләргә төреп,
Чалма чәчәк арасына адаштым кереп.
Гүя җаннар кавыштылар чәчәк туенда,
Мин гөл булып бөреләндем синең куйнында.

Керфекләре түбән төшә алсу гөлләрнең,
Карашыңда чагылып китсә моңсу күзләрең...
Кер бакчама, миндә дөрли җәйләр чилләсе —
Безгә әле мең кат үлеп, мең тереләсе.

Өзмә миңа чалма чәчәк, сулмасын иртә,
Гөл гомере бер вакытлык — үтә дә китә...
Сөюемә сөю белән белсәм түләрең,
Назым белән сугарырмын күңел гөлләрең.

Таҗ кидерден миңа шашкын хисләреңнән,
Исердем мин чалма чәчәк исләреннән.
Чалма чәчәк бөреләре алма-алма,
Сөю таҗы ачылганны күрми калма.

# ЯНАРТАУ

Яңа тапкан утравым син –
Үзең ерак, үзең якын.
Утрау түгел, Янартау син –
Тышың салкын, эчең ялкын.

Хәтта хыял үталмаслык
Нык киртәләр минем алда,
Очкын төшсә, гөлт итәрлек
Утлы күмер минем җанда.

Әй, Янартау! Юллар табып,
Сиңа килдем, күрәсеңме?
Туңган йөрәк җылы сорый –
Бер уч җылы бирәсеңме?

Уй җитсә дә, буй җиталмый –
Үзең ерак, үзең якын.
Атылмаган Янартау син –
Тышың салкын, эчең ялкын.

## ЙӨРӘКСЕНУ

Сез кая илтәсез, юлларым?
Сез кая чабасыз, уйларым?
Мин беләм: ул көтә, бик көтә –
Менә шул йөрәкне җилкетә.

Китимме борылып кирегә,
Яшимме сабышып тилегә?
Сарылып ярымның муенына,
Керимме бәхетнең куенына?

Кайларга илтсә дә юлларым,
Гел аңа тоташа уйларым…
Акылым әйткәнне тыңладым,
Тик йөрәк кушканны сайладым.

Өзелә күрмәгез, юлларым!
Туктала күрмәгез, уйларым!
Мин беләм: ул көтә, бик көтә –
Шул мине бәхетле яшәтә!

## ХЫЯЛЫЙ

Яр ташласа, җанда яра кала,
Дус ташласа, үзәк өзелә.
Җанда микән, йөрәктәме урын
Синең «сагынам» дигән сүзеңә?

Фараз кылмыйк, вакыт — гадел хаким:
Бер әйтер ул безгә турысын.
Мин, хыялый, җанның иң түрендә
Йөртәм хәзер шул сүз җылысын.

## СӨЮ ТӘМЕ

Бөтнек салып чәең ясыйсың да,
Эч, бала, дип каршы аласың.
Бөтнек түгел, сөю касәсенә
Син бит өмет таҗы саласың.

Иреннәрдә изри татлы ләззәт,
Хисләр чиртә бәхет сазымны...
Бөтнек тәме кушып, карашыңнан
Урлап эчәм яшерен назыңны.

## МИН СИНЕҢ ӨЧЕН ЯРАТЫЛГАНМЫН

Кул җылыларың йөрәкне эретә,
Җанны иркәли назлы көлүең.
Син минем өчен яратылгансың –
Миңа бик кирәк моны белүең.

Сине җанымнан, тәнемнән өзеп,
Беркемгә килми, килми бирәсем.
Без сөю өчен яратылганбыз –
Монысын инде үзең беләсең.

Күрешүне гел кичектерсәң дә,
Әле килерсең, барыбер килерсең.
Мин синең өчең яратылганмын –
Әле аңларсың, әле белерсең.

## СИН УЛ — АРТИСТ!

Сабый бала кебек иркәләнсәм,
Китсәм кайчак артык үзсенеп,
Кыланчыгым минем, дисең дә син,
Ник куясың инде көрсенеп?

«Синнән яхшы артист чыгар иде,
Бигрәк килештереп уйныйсың!»
Ышанасың, барыбер ышанасың, –
Мине сизми диеп уйлыйсың.

Сагынам дип әйтер идеңмени?
Димәк, ихласлыгым аңлыйсың.
Син ул – артист! Син ул – кыланчыгым!
Яратмаган булып алдыйсың!

## СОҢГЫ БҮЛӘК

Өметемне өзеп сулган чакта,
Сынды дигәч сабыр канатым, –
Изге нурдай иңдең күңелемә:
Бер күрүгә сине ярattым.

Гөнаһларым өчен җәзамы син,
Соңгы бүләгеме язмышның?
Күрми йөреп, син ялгыштың микән,
Кыймый йөреп, минме ялгыштым?

Гомерем буе сине эзләдем, дип,
Күзләремә сөеп багасың.
Кулларымны кушып үбәсең дә
Татлы газапларга саласың.

Зәгъфрандай әйдә саргаешмыйк,
Сабырлыклар сорыйк иң элек.
Дөньялыкта безгә кавышу юк,
Кавыштырыр, бәлки, мәңгелек...

# КЫЙССА

Теләп алдым бу ләззәтле газапны,
«Яратма», дип ничек әйтим йөрәккә.
Канат итеп каурый-каурый хыялны,
Очыйк әйдә, кошлар булып, еракка.

Сахралардан искән чакта таң җиле,
Исемеңне дәшми ничек түзәрмен?
Адашырмын, табылырмын, тик кабат
Татлы сөю газапларын эзләрмен.

Без икебез – ике сагыш, ике моң,
Безне язмыш аерым-аерым яраткан.
Тик йөрәгең дәшә минем йөрәккә:
Яратам, ди, сине генә яратам…
Сулышлар кушыла: яратам, яратам, яратам!

Җанда яшен, аҗаганнар уйнаклый, –
Бәхеткәйнең санаулыдыр көннәре.
Шушыдыр ла безнең Кадер кичләре,
Ак абага чәчәк аткан төннәре.

Икәү генә белгән яшерен серләрне,
Гәрәбә дип, диңгезләргә сибәрбез.
Язылмаган безнең сөю кыйссасын
Әкият итеп оныкларга сөйләрбез.

## ҺАВА ТОРЫШЫ

Сагындырып килә быел кышлар,
Быел кышлар килә ялындырып.
Ник, ичмасам, яумый инде карлар,
Тарыгудан җанны арындырып?

Ничәнче көн инде кояш та юк,
Кояш та юк... һәм син дә юк янда.
Телефонда бары боек тавыш:
«Һава торышлары ничек анда?»

Һава хәле бездә шундый менә,
Шундый менә: сулык-сулык йөрәк.
Ишеп-ишеп яуган бәхет булып,
Бәхет булып кайт син миңа тизрәк.

Ничәнче көн инде кояш та юк,
Кояш та юк, сагыш ойый җанда...
Телефонда синең боек тавыш:
«Һава торышлары ничек анда?»

## АЛТЫНЧЫ КӨН...

Бишенче көн инде хәбәрең юк,
Бишенче көн янам газапта.
Сине сөю – чынга ашкан хыял,
Сине сөю олы язык та.

Бишенче көн инде хәбәрең юк –
Китү белән мине оныттың.
Өмет кенә җылытырлык түгел –
Бозлы тының исә е547ктан.

Бишенче көн инде хәбәрең юк,
Юк, сагынмам сине, еламам...
Мин саташкан адәм баласына
Сабырлыклар бирче, бер Аллам?!

Алтынчы көн...

## ТИК СИН ДИЕП КЕНӘ ЯШИМ

Бәхет күзләренә карыйм
Мин синең күзләр белән,
Уйларым туа дөньяга
Нәкъ синең сүзләр белән.

Синнән алган бер очкынны
Кайтарам меңе белән.
Йөрәк тыныңнан кабынам,
Керфек җилеңнән сүнәм.

Гомеремне тамчы итәм
Син аккан дәрьяларда.
Тик син диеп кенә яшим
Бу якты дөньяларда.

Йолдыз булып атылырмын,
Аямыйча үземне,
Бер мизгелгә яктырталсам
Синең хыял күгеңне.

# ГӘРӘБӘ

Күз учыннан төшкән гәрәбә син —
Яралгансың диңгез балыннан...

*Марсель Галиев*

Күз учыннан төшкән гәрәбә мин,
Яралтучым ләкин күз түгел...
Йөзегемнән төшеп тәгәрәдем —
Тар кысалар миңа төс түгел.

Күз учыннан төшкән гәрәбә мин,
Яшькелт күзле серле гәрәбә.
Тылсымыма әсир булмам димә,
Бер чагылып китсәм әгәр дә.

Күз учыннан төшкән гәрәбә мин,
Диңгез балы — сары гәрәбә...
Үз бәямне үзем белим әле,
Узмасын ла гомер әрәмгә!

Тик соңладым... балкый алмадым шул
Сөю таҗындагы каш булып.
Кайтам кире диңгез күңеленә
Мин иясез асылташ булып.

Күз учыннан төшкән гәрәбә мин...

## АЛМАГАЧ БУРАНЫ

Коела ак тәңкә таҗ гына,
Җил куйса тирбәлеп аз гына.
Мин кердем бакчаңа адашып,
Гаепле барысына яз гына.

Мең рәхмәт булганың өчен дә
Янымда шушы май кичендә.
Туена соңлаган кәләштәй
Калдым мин шау хисләр эчендә...

Моң булып сарыла җаныма
Ак таҗлар, бер-берсен узышып.
Ничекләр түзәр бу йөрәгем,
Алмалар пешкәндә тулышып?

Ник сайрый елатып сандугач,
Чәчкәсен койганда алмагач?
Ник купты мәхәббәт бураны,
Сөяргә хакларым булмагач?

## КЫЗЫЛ ТӨЛКЕ

Әй Төлкем, Төлкекәем, дип
Яратып иркәлисең.
Ак Бүрем минем, дигәнгә
Үзең дә үртәлмисең.

Ялгыз Бүре булып йөрү
Төс түгелдер сиңа да.
Төлкелегем күрсәтергә
Иш булмаган миңа да.

Минем Кызыл Төлке булу
Ошый бугай үзеңә, –
Төлкебикәм, дигән чакта,
Мутлык чыга йөзеңә.

Үз дигәнемә ирешсәм,
Кайчак алдап-юмалап,
Ах, Төлке, дип шелтәлисең,
Хәйләләвем чамалап.

Төлкеләнмә, дип куясың,
Мин көлтәйгән* чагында.
Көлтәләндереп итәгем,
Сырпалансам янында.

Кылтын булып кылансам да,
Ышан син бу Төлкегә:
Сине, беркатлы Бүремне
Калдырмамын көлкегә.

---

* *Көлтәю* – кылтаю.

# СӨЮДӘН ВАЗ КИЧМӘ

Синнән башка яши алмыйм, дисең,
Ә син миннән башка яшәмә.
Өннәремдә көтеп-көтеп арыгач,
Ул мин кергән идем төшеңә.

Китәрсең, дип, беркөн башкаларга,
Аерылу безгә юрама...
Сөюеңнән башым җуярлык ит,
«Яратасыңмы» дип сорама.

Китү белән сагына башлыйм, дисең,
Китмәскә дип кил син яныма.
Бүгенгесе булмаганнар гына
Үткәннәргә елап табына.

Саклар идем, яклар идем, дисең,
Нахак сүзләр сиңа тиюдән...
Синең хакка түзәм мин барысына, –
Тик ваз кичмә генә сөюдән.

## МИҢА СУСАП БАККАН КАРАШЫҢДА...

Миңа сусап баккан карашыңда
Яшеренгән булса явызлык,
Куенымда сине назлаганнан
Хәерлерәк миңа ялгызлык.

Тугры калырсыңмы иртәгә дә
Антлар эчеп әйткән вәгъдәңә?
Саф ниятләр белән орындыңмы
Сиңа мәхбүс булган гәүдәмә?

Тел очыңда былбыл сайратуың
Барыр микән, белмим, озакка?
Мине шашып үпкән иреннәрең
Бикли алырсыңмы йозакка?

Китмәссеңме минем бәгыремне
Сәмум җиле кебек көйдереп?
Юләрдер син, димә, юләр түгел,
Сөям бары шашып-тилереп.

## БЕР ВАКЫТЛЫК...

Күпме сүз сөйләнде, вәгъдәләр эчелде...
Сәгатьнең телләре йөгерде ашыгып.
Сулышың җиленнән, сискәнеп, шәм сүнде,
Яраттың син мине, шашынып-шашынып.

Күпме сүз әйтелде. Әйтелде – онытылды...
Нигә соң бу вакыт борылмый кирегә?
Үткәнгә – салават. Үпкәм юк бөртек тә,
Тик өмет өзәргә ашыкмыйм әлегә.

Ни бәхет! Мин сөям. Мин татлы газапта...
Өр-яңа сагышлы җыр туды күңелдә.
Сәгатьнең герләре учыма баш салды.
Туктаттым вакытны...
Бәхетле көнемдә.

## ҖИҢЕЛҮ

Акыл белән Хиснең йөзгә-йөз
Бәрелешкән мәле. Йөрәк, түз!
Кайсы җиңәр, кайсы җиңелер? –
Җиңүчегә булыр соңгы сүз.

Буйсындырып кына булмый һич –
Үзенекен итә юләр Хис.
Урынына бәйсез Акылны
Утыртырга җитми минем көч.

Катнашмый тор, Йөрәк, ярсыма,
Күкрәк читлегемне тарсынма;
Сыендырма Хисне, яклама –
Ул гаепле монда барысына.

Ник керәсең ике арага,
Акыл белән Хисне аралап?
Үзенекен итәр тагын Хис, –
Син Йөрәкне китәр яралап...

Йөрәк колак салды сүземә,
Акыл карап тора күземә.
Хисем тынды... ләкин бу килеш
Мин кирәкмим хәтта үземә!

## ҮЗЕМ БУЛЫП КАЛЫЙМЧЫ?!

Китмә миннән сабырлыклар,
Яшьлек китмә, яме?!
Холкыңа күнә алмыйм, дип,
Гаҗизләр итмә, яме?!

Сиңа карамасын дисәң,
Күзләрем капла әйдә;
Сине назламасын дисәң,
Мә, кулларымны бәйлә.

Матур сүзләр әйткән чакта
Тыңлама, сүзем бүлдер,
Йә булмаса, барысына да
Миннән алдарак өлгер:

Күрешүгә, кочаклап ал —
Күндәм генә торырмын;
Суырып үп иренемнән —
Телсез-сүзсез калырмын.

Хәбәр сал үзең беренче,
Зарыктырып бетермә;
Яратам, дип, үзәккә үт —
Көнләшерлек иттермә.

Булды, җитәр, күп сөйләндем,
Кил, иркәләп алыймчы...
Яратыйм, назлыйм, кадерлим, —
Үзем булып калыймчы!

## КИЛ ГЕНӘ

Җаннарыңа дәва кирәк чакта,
Ялгыз көннәреңә керт мине.
Нигә килдең диеп сорау бирмә,
Кайнар сулышыңнан эрет мине.

Үкенмәссең, миндә син белмәгән,
Син көтмәгән сихри тылсым бар.
«Сөелдем» һәм «сөйдем» диюләрең
Көлеп сөйләр өчен калсыннар.

Хәмер эчмичә дә баш әйләнер
Мизгелләрне бүләк итеп ал.
Башкайларың ташка орма әле –
Кайнар күкрәгемә минем сал.

Күктән төшкән изге фәрештәдәй,
Гөнаһларың гафу итәрмен.
Күз яшьләрең, борчу-хәсрәтләрең
Үзем белән алып китәрмен.

Җаның куяр урын тапмаганда,
Сәбәпләрен эзләп тилмермә.
Бер сүз әйтмәсәң дә аңлармын мин –
Хәбәр биреп торма, кил генә.

# АГЫЛА ГОМЕР, АГЫЛА

Хәбәрең көтә-көтә, сабырлар итә-итә,
Мизгелгә мизгел ялгана... вакытлар акрын үтә.

Агыла гомер, агыла,
Савылып аккан ком кебек.
Сагынганда-саргайганда,
Сәгате дә көн кебек.

Сабырлар итә-итә, көткән минутлар җитә,
Мизгелгә мизгел ялгана... вакыт үтә дә китә.

Гомеркәйнең узулары
Дөрләп янган утка тиң.
Ике гашыйк кавышканда,
Сәгате минутка тиң.

## ГАЗАПЛАМА

Сөюем хак, тик гомерлек түгел:
Ул нәкъ безгә кирәк кадәрле.
Китәм дисәң әгәр, хәерле юл,
Тоткарламам сине, кадерлем.

Хисем кайнар, тик чамалы гына:
Сиңа, миңа гына җитәрлек.
Сөю юлларымның чакрымнары
Икәү җитәкләшеп үтәрлек.

Ят тоелсам, сиздер шул мизгелдә –
Сабырлыкның миндә юк чиге…
Сөяр булсаң, бүтән газаплама –
Күңелемнең сиңа юк биге.

## ЙӨРӘК БЕЛӘН

Йөрәк белән тыңла йөрәгемне,
Оныт «сагыш» дигән сүзнең барын.
Кушылсыннар уйлар, тәннәр, җаннар –
Оныттырыйм әле дөньяларың.

Йөрәк белән җылыт йөрәгемне,
Сусаганбыз назга син дә, мин дә.
Башкаларга җанда урын нигә?
Бәхетле дә бүген икәү, тиң дә.

Йөрәк белән аңла йөрәгемне,
Озак тормас бәхет, үтәр-китәр...
Соңгы кат күк татыйк сөю тәмен,
Үкенергә... калган гомер җитәр.

# ДОГА

Әбелхәят чишмәсенең бер тамчысы
Әйтерсең кан тамырларын кузгатты ла:
«Син – бәхетем, син – язмышым», диюләрең
Яшәвемнең бар мәгънәсен үзгәртте лә.

Бисмиллалы догаларым кабул булсын,
Озын гомер насыйп булсын бу гыйшкыма.
Сабыйларча ихлас җаным мең-мең разый, –
Яшим әле, яшим әле, дип ашкына.

## КИЧӘ ҺӘМ БҮГЕН

*(А. Кашинадан тәрҗемә)*

Бүген мин яз кебек гүзәлмен,
Бүген мин бер көяз күбәләк,
Ә кичә башбирмәс зат идем,
Бер горур җан идем, ни гаҗәп!

Бүген бит барысы да үзгәрде,
Әйтерсең мин инде мин түгел!
Мин сиңа гашыйкмын – шул гына,
Һәм бүген кичәге көн түгел.

Самими күңелем – шау чәчәк,
Мин назлы, мин балкыйм, очынам!
Туасы көнемдә өмет бар –
Мин шуңа ихластан ышанам.

## ТОРМЫШ — СӘХНӘ

*(А. Кашинадан тәрҗемә)*

Йә шатлыктан яңгыратып көләм,
Йә дөньяга сагыш таратам,
Йә яшәүдән кинәт җаным бизә,
Йә тормышны үлеп яратам.

Кирәк икән — мин беркатлы туташ,
Кирәк икән, булам горур кыз.
Шаярам һәм чаяланам кайчак,
Йә топ-модель булам, йә — йолдыз.

Патшабикә иртән — илаһи зат,
Кичен хәлем Алла кулында.
Менә кош кук очам канатланып,
Йә елан мин дошман юлында.

Йөздә — битлек, ләкин йөзем җуймыйм,
Төш күргәндәй яшим өнемдә.
Бер хыялый иләс актриса мин,
Һәм урыным — сәхнә түрендә.

# ОЧРАР ӘЛЕ

*(А. Кашинадан тәрҗемә)*

Барысы да сыйган күңелемдә,
Артты җимерек дөньям хәрабәсе.
Миңа таныш түгел сукмаклардан
Дәшә һаман серле ут шәүләсе.

Басылды күк бәгырь әрнүләре,
Җан ярасы түгел инде киртә.
Үзем яккан ялгыз учак уты
Бу мосафир җанны кая илтә?

Кыйтгам эзлим шулай, абына-егыла,
Фани өметемә ябышып торам.
Юклык кичеп йөргән илгизәр мин,
Билгесезлек минем туктар урын.

Гел эзләнәм археолог сыман,
Җимерек хыялларым артта кала.
Очрар әле юлда тугры бер дус,
Төзешергә яңа уртак кала.

## ЯРЫЙ СИН БАР

Иелдем гөл сабагыдай,
Хәлләр шәптән түгел әле.
Мин дигәнчә бармый тормыш,
Күңелемнең төшкән мәле.

Берьялгызым нишләр идем,
Ничек әле килә белдең?
Юатырлык сүзләр таптың:
«Кайгы түгел кайгың», — дидең.

Күкнең җиде катларында
Хыяллардан сарай кордым.
Куанычтан шашуымны
Бераз дәшми карап тордың.

Берьялгызым нишләр идем,
Ничек әле килә белдең?
«Мондый гына шатлыклардан
Башкаеңны җуйма», — дидең.

Кайгыны да, шатлыкны да
Ярый син бар бүлешергә.
Бер көн сине күрми торсам,
Сәбәп эзлим күрешергә.

Берьялгызым нишләр идем,
Ничек әле үзең килдең?
Җанның син дип сулкылдавын
Каян белдең, каян белдең?

## ОНЫТЫЙК ЯРАТУ ТУРЫНДА

Онытыйк ярату турында,
Куыйк без сөюне йөрәктән.
Очрашу-кавышу көннәрен
Әйләнеп узыйк без еpoints.

Абына-сөртенә йөгермик
Телефон зыңлаган тавышка.
Төн буе шигырьләр укышмыйк,
Уздырмыйк вакытны без бушка...

Сүндерик йөрәкнең ялкынын,
Күмергә каласын уйлыйк та...
Иманга оесын иреннәр
«Сөям!» дип әйтәчәк минутта.

Көтмик без язмыштан могҗиза,
Сак булыйк мәкерле хәтәрдән...
...Сөюдән гакылымны җуярмын,
Тик сине җуялмам хәтердән!

## УТ ҺӘМ СУ

Казансу буйлары ком гына,
Дулкын кага ярга тын гына.
Югалтудан куркам эзләрең –
Мин бит сине озак эзләдем.

Йөрәгеңә дәва иттеңме
Казансуның салкын суларын?
Колач салып ялгыз йөзгәндә,
Талмадымы, бәгърем, кулларың?

Мин дә керим әле яныңа,
Иш булмаммы моңлы җаныңа?
Аңлагандай минем уйларым,
Каршы алдың сузып кулларың.

Сыендым мин синең кочакка,
Утлар капты җанга ул чакта.
Дөнья тоташ ут һәм су гына:
Яратам мин сине – шул гына.

## РОЗАЛАР

Алып килдең миңа ак розалар,
Күзләремә сөеп карадың.
«Ак чәчәкләр — сафлык билгесе» дип,
Ак бәхетләр миңа юрадың.

Бүләк иттең уттай гөлчәчәкләр,
Ялкынлысын ихлас сөюнең.
Кочак тулы кызыл розаларың —
«Мин синеке генә» диюең.

Сары розаң сагыш алып килде,
Яшерен хиснең соңгы көннәрен.
Бәхет дигәннәрем тик төш булды —
Алдамады сары гөлләрең.

Ал розалар — өмет билгеләре —
Серле балкып, мине ал, диләр.
Аңларсыңмы өзелеп көтүемне,
Бүләк итсәм әгәр ал гөлләр?!

## ГӨЛБАДРАН

Юл буенда үскән гөлбадраннар
Ямьле җәйнең җыйган җылысын...
Мин дә синнән җылы караш көтәм,
Мәхәббәтнең көтәм олысын.

Тәлгәш-тәлгәш сары гөлбадранга
Тып-тып тама кайнар яшьләрем.
Тәлгәш-тәлгәш сары сагыш йотып,
Үз-үземне алдап яшәдем.

Юл буенда үскән гөлбадранның
Башкайлары калды иелеп.
Гомер итеп була башны иеп,
Яшәп була сөеп-сөелеп.

Юл буенда үскән гөлбадранның
Төймәләрен җыйдым дәвага,
Әчеләре шифа булмасмы дип
Җанымдагы тынмас ярага.

## МИН, ЧЫННАН ДА, СӨЯ ИДЕМ

Ни булды, дип уйлап йөрмә,
Миңа берүк рәнҗи күрмә,
Ни булса да булган инде –
Онытырга тырыш мине.

Мин, чыннан да, сөя идем,
Бу – гомерлек, дия идем.
Бар да бетте, үтте-китте,
Хушлашырга вакыт җитте.

Тормыш матур, тормыш гаҗәп,
Сукты бары безнең сәгать.
Борчылма син, иртәгә көн
Бүгенгедән булыр әйбәт.

Соң мәртәбә йолдыз саныйк,
Дуслар гына булып калыйк.
Без сайлаган йолдыз сүнде –
Язмыш белән килешик инде.

## «МИН»ЛЕ ШИГЫРЬ

Хисләреңнең көче миндә, диеп,
Бәяң күтәрергә ашыкма.
Җырларымның кинәт туктавының
Син сәбәбен башта ачыкла.

Моңнарыңның төсе минеке, дип,
Үзеңнеке итмә барын да.
Синнән башка мин  ул – мин түгел, дип,
Калырымны көтмә янында.

Бер мизгелгә айнып мин-минлектән,
Янәшәңә күз сал тукталып:
Минсез уяначак иртәгәңә
Кереп бара төнге сукмагың.

## ХУШЛАШУ

Саумы, Яшьлек!
Саф-самими җаным
Синдә яши, яши Сөю көтеп.
Танымаган булып йөз чөермә,
Карамале миңа чит-ят итеп.

Минем әле синнән киткәнем юк,
Үз-үземне эзләп йөрим һаман.
Гомер кичәм: тәүге сөю җырым
Еллар тозагында өзелеп калган.

Танымассың да шул: йөзем инде
Сагышлардан шактый сулып бара.
Карашларым шул ук, шул ук ласа —
Яле, күзләремә минем кара!

Аларда бит шул ук ихласлыгым,
Күңелемнең якты балкышлары,
Яшьлек язларымның яшькелтлеге,
Садә хисләремнең ак кышлары...

Назга сусау да бар, сагаю да
Нәүмизләнеп калган карашымда.
Тыңламыйсың, борылып карамыйча,
Мине ташлап китеп барасың ла?!

«Хуш, Яшьлегем!» — генә дия алдым,
Сузган куллар калды күтәрелеп.
Йә Илаһым, бирче аек акыл,
Калган гомерләрне үткәрерлек!

Шулчак кемдер кайнар учын салды
Күккә ашкан канат-кулларыма.
Мең рәхмәтле Аллам мине ишетеп,
Әллә Сөю чыккан юлларыма?

## КИЛӘ ҮЗЕМ БУЛЫП КАЛАСЫМ

Үзгәртергә мине соң шул инде –
Үземнән дә яхшы булалмыйм.
Авыр, нишлим, дөресен әйтүләре,
Яратмагач, сөям диялмыйм.

Тыңламыйсың, диеп үпкәлисең,
Тыңлыйм үзе, бары ишетмим.
Башка берәү тулган йөрәгемә
Сыйдыралыйм сине ничек мин?

Сиңа карыйм, ләкин аны күрәм,
Син янымда, ләкин үз түгел.
«Сөям» дию күңел күрү өчен,
Әйтеп оныта торган сүз түгел.

Килми сине утка саласым –
Килә үзем булып каласым.

## АКЛЫК

Белмим, әллә кыш сәбәпче:
Күңелдә никтер аклык.
Салкын карны эретерлек
Хисләрдән учак яктык.

Кар-йолдызлар учлап алып,
Зәңгәр күкләргә сибәм.
Кояш нурларын тотмакчы –
Ашкына күңел нидән?

Оныттык бар үпкәләрне,
Шатланыр сәбәп таптык.
Кыш микән лә сәбәпчесе –
Күңелдә бары аклык...

## КҮК КҮБӘЛӘК

Сөюемне ятлар карашыннан
Яшереп сиңа алып килгән идем...
Пар күбәләк булып тирбәлербез
Бәхет таҗларында, дигән идем.

Рәнҗетелгән сөю сүзсез елый, –
Югалтудан авыр тагын ни бар?
Учларыңа кунган күбәләкне
Кире җибәр син, ирекккә җибәр.

Күк күбәләк керде араларга,
Гөлдән гөлгә очып йөргән чакта;
Йөрәгеңә кунып җилпенде дә
Онытты ул юлны синең якка.

Янган утка үзең барып кердең,
Без бит хәзер пар күбәләк түгел.
Канатлары көйде мәхәббәтнең,
Сиңа ышанычны җуйгач күңел.

## НИК ДӘШӘСЕҢ?

Нәни песи кебек иркәләнеп,
Куеныңа килә керәсем,
Назларыңда килә коенасым,
Уйларыңны килә беләсем.

«Йөрәгемдә сиңа урын түрдән,
Бирдәнберем – син ул», – диясең,
Ләкин үзең, алларыңа алып,
Башка йомшаккайны сөясең.

Нәни песи кебек сырпаланам,
Яратыла беләм белүен;
Уйларыңда ләкин башка берәү,
Шул берәүне сөйми күңелем...

Кил, песием, диеп ник дәшәсең,
Куеныңда урын булмагач?..
Күк күкрәүдән, әйтче, нинди файда,
Коеп-коеп яңгыр яумагач?!

## ТӘҮГЕ ЯРЫМ

Садә яшьлегемдә өзелеп сөйгән
Онытылмас тәүге ярым син,
Хәтер кылларымны сызландырган
Үзем генә белгән җырым син.

Юлларыбыз безнең аерым-аерым
Менгән чакта гомер үренә,
Тик шулай да күрешәсе иде,
Сөйләшәсе иде бер генә.

Яшерен сагынудан өзлеккәндә,
Үкенүдән дәва тапмыйм мин:
Әрнүләрне имләр дәва итеп
Йөрәгемдә сине саклыйм мин.

Беренче яр гомерлек яр икән,
Сөю – иң ләззәтле хатирә.
Гүзәл яшьлегемнең үзе булып
Калдың, тәүге ярым, хәтердә.

## ЙӨРӘГЕМӘ ЯЗДЫМ ИСЕМЕҢНЕ

Гөлләр белән яздым исемеңне –
Шаулап чәчәк атты гөлләрем.
Күзләр җиткәч сулды чәчәкләрем –
Минем сөюемне белмәдең.

Моңлы көйгә салган матур исемең
Кыңгыраулар булып чыңлады.
Тик син түгел, аны адашларың
Үзенеке итеп тыңлады.

Яфрак белән кулга тезгән исемең
Шаян дулкын китте таратып…
Исемеңне, күзләреңә карап,
Мин үзеңә дәштем яратып.

Таш кадәрле ташны вакыт уа,
Агач, янса, кала күмергә.
Йөрәгемә яздым исемеңне,
Җуелмаслык итеп гомергә.

## ЛИЛИЯЛӘР

Күңелемнең язны сагынганын
Әллә инде Сез дә сиздегез?
Чиксез соклануым билгесе, дип,
Лилияләр алып килдегез.

Лилияләр! Уттай лилияләр!
Онытылды гыйнвар салкыны.
Кочагыма сеңгән чәчкәләрнең
Йөрәгемә капты ялкыны.

Кышкы бакчамдагы гөлләр, дисез,
Җанны назлый салкын көннәрдә.
Тик, сеңелкәй, сезнең гүзәллектән
Көнләшерлек, дисез, гөлләр дә...

Җәйләрдә дә, кышкы чиллдә дә
Гөл-чәчәкләр тансык түгел дә...
Тик нигәдер, Сезне хәтерләтеп,
Лилияләр калды күңелдә.

## ЙӨРӘГЕҢНӘН — ЙӨРӘГЕМӘ

Җем-җем карның аклыгыннан
Бигрәк якты кышкы кичләр.
Өермәдәй уйный-уйный
Урап ала татлы хисләр.
Мизгелгә дә аерылмый
Аңлашалар безнең күзләр.
Ак келәмдә бизәк булып
Кавышалар безнең эзләр.

Араларны суыталмас зәмһәрир салкын,
Йөрәгеңнән йөрәгемә үрләде ялкын.

Сабыйлардай шаярышып,
Кар атыштык икәүләшеп.
Буранга да, давылга да
Керик бергә, җитәкләшеп.
Эзебезнең җылысына
Салкын карлар яуса явар,
Ул эзләрдә, язлар җиткәч,
Алсу гөлләр шытып чыгар.

Безнең барыр юлыбызга
Әйтерсең лә энҗе сипкән.
Күңелдә дә аклык-сафлык,
Сәбәпчесе кышлар микән?
Кар-йолдызлар учлап алып,
Көлә-көлә күккә чөям.
Мин бит сине сөям, дисең,
Ә мин сине ныграк сөям.

Араларны суыталмас зәмһәрир салкын,
Йөрәгеңнән йөрәгемә үрләде ялкын.

# ХАКЫЙКАТЬ

Гомер итеп булмый икән,
Җанны икегә ярып.
Мин барыбер үткәннәргә
Җитә алмадым барып.

Берексә дә куш игездәй
Ялганы-чыны бергә,
Куш йөрәк белән тумаган
Бирәү дә әле җиргә.

Мин кайда — бәхет тә шунда:
Яши-яши аңладым.
Төшкән җиремдә таш булыйм —
Бүгенгемне сайладым.

## МИНЕ СӨЮ БАРА ОЗАТЫП

Дөньясы бит гел карадан түгел,
Күрә белсәң, шатлык табыла.
Миңа карап елмаюың җитә –
Җанда яшәү дәрте кабына.

Кайсыбыздан язмыш көлмәгән дә
Кемнең башын сагыш имәгән?
Вакытлыча килгән сынауларга
Сер бирергә әле димәгән.

Шатланмыйча бер көн тора алмыйм,
Елмаймыйча ничек түзә алыйм?
Бар дөньяны яшим яратып,
Мине Сөю бара озатып.

# Татар кызлары

Язмышлар такыясы



*Күкрәк кага, гайрәт чәчә көчле затлар,*
*Бу дөньяның егәре, дип, бездә генә.*
*Алар батыр, алар галим, алар шагыйрь...*
*Һәйкәл куя ир-егетләр үзләренә.*

*Алыпларның тамырына җан тибеше*
*Хатын-кыздан — әнкәсеннән иңгәндер бит?!*
*Идегәйләр, Искәндәрләр, Чыңгыз ханнар*
*Яшәү сутын — Ана сөтен имгәндер бит?!*

*Ирләр белән янәшәдә, бер үк тында*
*Кем яу чапкан, ут тергезгән, иген иккән?!*
*Керфегенең һәр бөртеге ымсындырып,*
*Ханнарны да кем үзенә әсир иткән?!*

*Дөрләтәм дә теләктәшлек ялкыннарын,*
*Сулыш өреп хәтер-учак кузларына,*
*Һәйкәл куям шигъри гөлләр бостанымда*
*Милләтемнең ир йөрәкле кызларына.*

## НИЯТЛӘҮ

Иярләр иясез калганнар,
Яугирләр яу чапмый күптәннән.
Далалар ягыннан искән Җил
Өн-хәбәр китерде үткәннән:
«Ерак дәвер төпкеленнән
Бага сиңа Хәтер күзе.
Кайтаваздай кабатланып,
Җанга кага әйтер сүзе:
— Синең кылган гамәлләрдән
Оялмасын Күкләр йөзе.
Асылыңа кайт, соңлама,
Татар кызы!
Та-тар кы-зы-ыы!
Онытма:
Кем син?
Милләтең кем? —
Хәтерлә!»

Мин кемме? —
Хатын-кыз! Мин — Ана!
Саклаучы гаилә учагын.
Кирәксә, бар минем бәйгедә
Җиһангир ирләргә тиң чагым.

Мин Гайшә — Пәйгамбәр янында,
Саф өммәт, мәгърифәт сагында;
Халкыма кирәксә, Ил дәшсә,
Заманның хәвефле ягында…

Мин кемме? –
Хөкемдар – Ханбикә!
Чор гамен күтәрдем иңемә.
Сөрелсәм сөрелдем Ватаннан,
Әмма мин сөрлегеп
хыянәт итмәдем
Милләткә, денемә, динемә.

Бирегез аргамак! Юл чыгам
Хәтерем әйдәгән җирләргә!
Күңелне җилбәгәй җибәрәм
Тумыштан ирекле җилләргә.

Гасырлар, тайпылып, юл бирә,
Офыкта шам кылыч – шом яшьни...
Әһе-һей!
Мин – төрки кавемнән!
Мин – татар!
Ишетәмсез?!
Кайтаваз ник дәшми?

Кыюлык көбәсе – иңемдә,
Садакта – елдырым укларым.
Өн-хәбәр чакырган тарафка
Илт мине, ярсулы тулпарым!

## ХАННАР КИТӘ – ХАЛЫК КАЛА

Син уйлама, дөньяда мин мәңгегә калырмын дип, –
Күп янар вакытта утлар очырган дөнья бу.
Угылны атадан аерып, кызны да анадан шулай ук,
Елатып, бер-бер ишектә зар иттергән дөнья бу.

*Кол Шәриф*

## НУРСОЛТАН

Хәтернең кылларын зеңләтеп,
Уй аттым айдала* ягына.
Оч, угым, миңа юл күрсәт син
Нурсолтан ханбикә янына.

Казан – Кырым арасы
Күпне күргән юл булыр.
Казан, Кырым ханлыгына
Ханнар биргән кем булыр? –
Ак мангытлар ыруыннан
Тимер бәкнең бүзедер,
Бүз баласы – кызыдыр:
Казан, Кырым ханбикәсе
Нурсолтан сылу үзедер.

* *Айдала* – ачык, такыр дала.

Солтанлыгын калдырып,
Утауда* ут алдырып,
Күз яшьләрен тамдырып,
Ниләр уйлый ханбикә?
Кыйбла якка баш орып,
Ни ялвара ханбикә?

Казан – Мәскәү арасы
Күпне күргән юл булыр,
Кырым – Мәскәү арасы
Сер яшергән юл булыр.
Мәскәү белән языша,
Зур бүләкләр алыша...
Җөяң** нидә, хаҗия?
Үзең җилгән атыңны,
Мәккә җиткән атыңны
Мәскәүләргә бирергә
Җөрьәт иттең, хаҗия...
(Ни ният бар уенда,
Таш йөртмиме куйнында?)

Хан янында Нурсолтан –
Зирәкләрнең зирәге.
Ханбикәнең күкрәгендә
Тибә Ана йөрәге.
Ханзадәләр хакында
Кан-яшь йота Нурсолтан,
Мәскәү белән, бик уйлап,
Сак эш йөртә Нурсолтан.

---

* *Утау* – тирмә.
** *Җөя* – мантыйк (логика).

Ике углы, күз нуры —
Ибраһим хан дәвамы,
Тибә нәсел тамырында
Олы Мөхәммәд каны.
Яшь ханнарга көч бирә
Нурсолтанның үрнәге —
Үз дәүләтен бәйсез итеп
Саклап калу теләге.
Нык бул, Ана йөрәге!
Ханнар — илнең терәге,
Кыл өстендә тирбәлә
Дәүләтеңнең иреге.

...Сатлыкҗаннар, шымчылар,
Кенәзләргә ялчылар
Итәк аслап ут йөртә.
Шымчының бер шымыннан,
Патшаның бер ымыннан
Ханнар да сөрген китә.
Заман кемнең кулында,
Шулар хакимлек итә...
Дәвер кемнең кулында,
Шулар юкны бар итә,
Шулар барны юк итә.
Заман кала — баш китә...
Габделлатыйф, Мөхәммәдәмин,
Әнкәләрен калдырып,
Якты дөньядан үтә.
Шулай Олы Мөхәммәднең
Нәсел дәвамы бетә.

Казан — Кырым арасы
Күпне күргән юл булыр,

Казан, Кырым ханлыгына
Ханнар биргән кем булыр? –
Ак мангытлар ыруыннан
Тимер бәкнең бүзедер,
Бүз баласы – кызыдыр,
Казан, Кырым ханбикәсе
Нурсолтан ханча үзедер.

Ханына ханәш* булып,
Тиңенә тиңдәш булып,
Киңәшкә киңәш булып
Гомер кичә Нурсолтан,
Кырык еллап гомерен
Фида кыла халкына,
Мәскәү белән килешеп,
Тыныч яшәү хакына,
Үз ханлыгын дәүләт итеп
Саклап калу хакына.

Өч мәртәбә тол калып;
Хак намусы кушканча,
Ике тапкыр хаҗ кылып,
Җитмеш ике яшенә
Килеп җитә ханбикә,
Җитмеш өче булганда,
Кадер-хөрмәт күркендә,
Иректә һәм иркендә
Күзен йома ханбикә.
Казан, Кырым ханлыгын
Ятим итә ханбикә.

---

* *Ханәш* – хан хатыны, ханча.

Ханнар китә – дан кала,
Даны барга сан кала,
Буынга буын ялганып,
Дәвер кичәр кан кала...

Аңлы хәтерем уятканга,
Мең-мең рәхмәт, уй-дала!

## СӨЕМБИКӘ

Күкрәүләр белән күкләнгән
Тарихның һәрбер җеге.
Узып күңел күге аша,
Халкыма барып тоташа
Уй-яшен тегәрҗебе.

Нинди моң бу? Кем сыкрана? Кемнәр рәнҗеткән аны?
Өзелгән гөслә кылында өзгәләнә кем җаны:

«И күңел, бил баглама, күпне кичүргән дөньядыр,
Бу үлүм ширбәтин халыкга ичүргән дөньядыр...»*

Әй Шагыйрь, аңлыйм күңлең: әрнеп сызланган
күңел ул,
Үз иле хәсрәтеннән соңгача янган гомер ул!

Бер мөселман шәһәре зур каза күргән заман ул,
Халкым дип, ханбикәсе җанын да биргән заман ул.

---

* Кол Шәриф газәленнән.

Елама, Сөембикә, син сөен, — ярый күрмисең:
Җиргә елыша манараң, авышканын белмисең.

Тез чүкми — иңә генә: ханбикәседәй горур ул,
Ватаны өчен шәһит киткәннәр кебек мәгърур ул.

Син — халкым, халкым диеп, моң-зар эчкән
ханбикәбез,
Тик, зинһар, булма безләрдән ваз кичкән шанбикәбез.

Кем кая кушса, шундук башны шул таба борабыз,
Җил кайсы якка иссә, шунда аварга торабыз.

Үз теләгебез белән кяфер куйнына әзер без...
Чит кавем үрчетүче «халык кызлары» хәзер без.

Җариядәй, күндәмлек пәрәнҗәсе ябынабыз,
Һуш китеп, телдән язып, «ушкуйник»ка табынабыз.

Юл читләрендә саф-саф ирекме даулап торабыз?
Хөррият әллә шулмы? «Без әле кая барабыз?!»

Кем идек? Каян килдек? Кайсы туфрактан тамырлар?
Килер буыннар безне кем диеп искә алырлар?

Бил бөгелгән, «тыйнаклык»тан гел иелгән башмы ул,
Илбаш өстенә илбаш, әйткән сүзенә башмы ул?!

Елама да һәм кичермә... бу аек заман түгел...
Тик бер Раббыма бага манарасы авыш күңел.

Ул авыш, ләкин аумаган һәм аумаска охшаган:
Синең кан гүли җанымда — мин шуңарга ышанам.

Сөембикәле кавем без, синең шанда коенабыз,
Рух чүксә, өмет ауса, сиңа килеп сыенабыз.

Ханбикәбез рухы дәшә кыйбланың һәр ягыннан,
Шәйләнә төз манаралар офыклар аръягыннан.

...Башбирмәс, горур булган! — хак сүзләр синең
хакында...
Ышанам! Сөембикәләр туачак әле халкымда!

## ФАТИМА СОЛТАН

Фатима Солтан Акмөхәммәд Шаһкол сәет кызы (? — 1681) — Арыслангали ханның хатыны, Касыйм ханлыгының иң соңгы идарәчесе (1679 — 1681). Аның да, аңа кадәрге ханнарның да идарә итүдә хокуклары бик чикле була. Фатима Солтан улын чукындыруга, рус патшасы нәселеннән килен алуга һәм ханлыкта ислам динен кысрыклауга ризасызлык белдереп яши. Фатима Солтанның үлеменнән соң, Пётр I нең «тырышлыгы» нәтиҗәсендә ханлык таркатыла, руслаштыру хәрәкәте көчәйгәннән-көчәя бара. Мөселманнар һәм үз аллаларына табынып яшәгән башка җирле халык, көчләп, христиан диненә күчерелә.

*Тарихи чыганаклардан*

«Лә илаһә иллаллаһ!» — дип әйтеп куям,
Күз салам да болытларның агышына.
Азан моңын басып китә чиркәү чаңы,
Әверелеп чорның йөрәк кагышына.

Тетри җаным! Убыла аң! Җитми һава!
Күз алдымда манаралар сыкрап ава.

Тамырымда ярсып типкән әрнүләрдән
Бәгыремә сулык-сулык кан-яшь сава.

Ул – Касыймның соңгы солтан-ханбикәсе...
Булалганмы үз халкының җанбикәсе?
Ханкирмәнгә*, мөлкәтенә читләр хуҗа,
Залиманә бу дөньядан ни көтәсең?

Ясак салып, кол хәлендә калдырылгач,
Тынны буып, хак динеңнән яздырылгач,
Башны ташка орсаң да син, юк һич чара,
Һәр адымың сак астына алдырылгач.

Ул Фатима – шәехләрдән, сәет кызы,
Күк шаһыннан ярдәм сорап бага күзе.
Хыянәтнең иң яманы – яраннарның
«Хак диненнән язган» дигән нахак сүзе.

«Мин соңгысы... Күк каршында ни гөнаһым?
Соңгы карар, соңгы сулыш, соңгы аһым...
Ханлык белән ава күңел манарам да,
Үзең кичер, ярлыкагыл, бер Аллаһым?!» –

Шул хактамы ханбикәнең тәүбә сүзе?
Бикләнә дә дога кыла ул берүзе.
Йома күзен. Җан убыла. Ава дөнья...
Хакыйкатьне иелеп ала Күкләр үзе.

---

* *Ханкирмән* – Касыйм шәһәренең татар чыганакларындагы икенче атамасы.

Ялгышымы? Әллә Ходай каргышымы?
Соңгыларның соңы булу — язмышымы?
...Хәтәр төштән айныгандай, борам юлым
Кол Шәрифтән килгән азан тавышына.

«Соңгы... соңгы... иң соңгы!» — дип тибә йөрәк,
Тукталмыйча, юлым дәвам итү кирәк!
Иң беренче булмасаң да, уй-тулпарым,
Соңгы булма, максатыңа оч син тизрәк!

## ЧОРДАН ЧОРГА

Җилеп узам Хәтер далаларын,
Курганнарны кочып, җил елый.
Тояк эзләрендә җир төшләнә,
Ак бүреләр җанда ник улый?

Якыная уйлар үз чорыма,
Ярылырга җитеп йөрәге.
Юлларыма чыга, теш ыржайтып,
Замананың кансыз өрәге.

Минем чорым, минем дәверем бу!
Үзем менә, белмим, кайдагы?
Кая барам?.. Дүрт ягым да кыйбла —
Мин — заманның башсыз җайдагы.

Күңел күзем үткенләнә төшә
Тоеп йолдызларның яктысын.
Алар минем сүнмәс өметемә
Утлы куәт биреп балкысын.

## ГЫЙЛЕМ ТАҖЫ

Изелгән, асылган, киселгән,
Тапталган, иленнән сөрелгән,
Йолкынган, тамыры өзелгән –
Хәл җыеп, яңадан терелгән.
Тернәкле орлыктан үрчегән,
Очкыннан кабынып дөрләгән...
Дым-шифа эзләгән тирәннән,
Түбәннән югары үрләгән.
Яраткан, җылыткан, бүлешкән...
Үз-үзен аямый көрәшкән.
Гыйлемле туташлар, ханымнар
Халкыма мәгърифәт өләшкән.

## МУЛЛА-АБЫСТАЙ

1908 елда Иж-Бубый авылындагы (хәзерге Әгерҗе районы) мәдрәсә каршында хатын-кызлар мәктәбе эшли башлый. Аны оештыручылар абыйлы-энеле Бубилар һәм сеңелләре Мөхлисә (1869–1937) була. Мәктәп татар халкының беренче хатын-кызлар гимназиясенә әверелә. Шәригать кануннары өлкәсендәге тирән белемен хөрмәт итеп, Мөхлисәне халыкта мулла-абыстай дип йөртәләр...

### 1

Беназиры, Индирасы* ул татарның,
Милләтемнең киләчәген саклаучысы;

* *Беназир Бхутто* – мөселман илләрендәге (Пакыстан) хатын-кызлардан иң беренче дәүләт башлыгы. *Индира Ганди* – Һиндстанның танылган сәяси эшлеклесе.

Мәгърифәтче, дин әһеле, сәясәтче...
Рәнҗетелгән хатын-кызның яклаучысы.

Иң әүвәле ул үз-үзен яклый алган,
Коллыктагы ирегенә юлны ачкан:
Үз кызын һәм ятимәне сыендырып,
Кансыз ире — мулласыннан чыгып качкан.

«Гыйлемсезлек-наданлыктан кыз баланы
Йолып калсаң, коткарырсың ил-дәүләтне», —
Шул уй белән мәдрәсәләр ача-ача,
Алга сөргән динебезне һәм милләтне.

Казан, Уфа, Мәскәвеннән, Сәмәркандтан... —
«Җир читеннән» мөселманнар монда килеп,
Иж-Бубыйның мәктәбендә белем алган,
Мәгърифәтне, аң-белемне өстен күреп.

**2**

Әй татарым!
Ярыймы соң баш калкыту?!
Син бит җиргә хәтәр татар булып туган.
Дәүләтчелек нигезләрен какшата дип,
Тиз утырта акылыңа «олы туган».

Столыпин реформасы читләп узмый
Иж-Бубыйның гөрләп торган ул чакларын:
Берәм-берәм сүндерелә, көл ителә
Милләтемнең аң-мәгърифәт учаклары.

Татар аңын зинданнарга япсалар да,
Ассалар да, тотып утка яксалар да,

Мөгаллимне алыштырган мөгаллимә,
«Акылы кыска» дигән ярлык таксалар да.

Бер газаптан мең газапка ул куылган,
Ир-егетләр җөрьәт итмәс эшләр кылган;
Һәр адымда мәгърифәт дип сулыш алган,
Ни күрсә дә, кыйбласына тугры калган.

* * *

Мөхлисә дә милләтенә һәм диненә
Иҗтиһадта махы бирми ирләргә дә:
Мөселманнар корылтае казый итеп
Сайлап куя аны Үзәк идарәгә.

Алты казый арасында — бер казыя,
Шәригатьчә хөкем итә, бирә җәза...
Күнче мулла-мунтагайлар санламыйлар,
Казый түгел, хатын-кыз, дип, башка каза.

Шәригатькә каршы килә ул, янәсе,
Мөбах* булган гамәлләрне ник тыярга?
(Ә казыя идарәдә тәкъдим кертә:
«Күпхатынлык ирегенә чик куярга!»)

...Чик куярга кимсетелү-хурлауларга!
Туймадыңмы син кол булып ир-атларга?!
Әй хатын-кыз! Ки әүвәле гыйлем таҗын
Һәм әзер тор үз-үзеңне син якларга.

---

* *Мөбах* — тыелмаган.

## 3

Залим-золым тәгәрмәче таптап уза
Сайлап кына асылларны, зыялыны.
Абыстай да төрмәләрдә михнәт чигә,
Ирешалмый хаҗга бару хыялына.

Көл ителә күпме хезмәт, җилгә оча,
Мәдрәсәләр, бар мөлкәте кулдан китә.
Кыл өстендә тора гүя ил язмышы,
Яше байтак, юк өмете, хөкем көтә...

Мең тугыз йөз утыз җиде... Карар катгый...
Вәхшиләрне ничек итеп күтәрә җир?
Халкы өчен корбан булган изгеләргә
Әй Раббыбыз, ахирәттә әҗерен бир!

Төбәләм дә Күкнең тирән күзләренә,
Мин ачынып сорау бирәм: «Кайда хаклык?!»
Гасырларны кичеп гүя бер өн килә:
«Без гомерне милләт өчен утка яктык!
Гаебем юк! Намусым пакь! — Шунысы хак!»

## 4

Иж-Бубыйның мәктәбендә сәер тынлык...
Җан башыннан түләү көтә бала-чага.
Яңа гасыр реформасы мәгарифкә —
Киләчәкнең тамырына балта чаба.

Һәм бүген дә яңартулар-кыскартулар
Мәктәпләрнең баш очына кылыч элгән.
«Олы туган» куласасы тагын баса —
Аңлый булыр милләт хәлен анык белгән.

Ярыймы соң кем икәнең онытырга?!
Татар бит син, әй татарым! Татар гынам!
Мөхлисәле чакларыңа уем төбәп,
Татарлыгың уянганны мин сагынам!
Хәтәрлегең уянганны мин сагынам!

## ФАТИХА

Фатиха Аитова (Яушева, 1866 — 1942) — танылган җәмәгать эшлеклесе, иганәче, татар халкына дөньяви белем бирү тарафдары. 1897 — 1900 елларда үз акчасына Казанда фәкыйрь кыз балалар өчен башлангыч мәктәп тота. 1909 елда тулаем аның акчасына ачылган башлангыч кызлар мәктәбе 1913 елда алты сыйныфлы мәктәп итеп, 1916 елда кызлар хосусый гимназиясе итеп үзгәртелә.

Ике мең дә унбер. Казан кайный.
Зур түрәләр бергә җыйналды.
Уналты ел көткән бәхет килде:
Гимназия булды биналы.

Гимназистка кызлар хәзер монда
Саф заманча гыйлем алачак,
Киләчәктә алар милләт даны —
«Элиталы кызлар» булачак.

Бирсен Ходай. Мин дә шул догада,
Юрыйк моны бары яхшыга...
Кайтып киләм. Уйларымны бүлеп,
Тарих чыга минем каршыга.

* * *

Мең тугыз йөз уналтының көзе.
Гөрли Иске татар бистәсе.
Халык кайный – килми берәүнең дә
Тантананы читләп үтәсе.

Апалар да, әбиләр дә монда,
Калфак кигән кызлар төркеме...
Тарихларга язылачак бу көн –
Милләтемнең данлы бер көне.

Зур түрәләр, аксакаллар килгән,
Хәбәрчеләр тыз-быз кайнаша.
Бар халыкны бердәм күтәралган
Бу нинди шау? Нинди тамаша?

Кызлар өчен гимназия ачып,
Киләчәккә бирә фатиха,
Гыйлем алу бәхетен татымаган
Милләт кызы – кыю Фатиха.

* * *

Әтисеннән мирас бар мөлкәтен
Халкы файдасына багышлый.
(Уллары һәм ире хуплап чыга –
Хәерхаһлы, димәк, ялгышмый.)

Әүвәл — мәктәп. Аннан — гимназия...
Тәвәккәлләп, эшкә алына.
Йә хөкүмәт «тота якасыннан»,
Йә муллалар төшә юлына.

Киртәләре очрап торса тора,
Уй-чаптарын бормый кирегә.
(Максатына кыю җилгән өчен,
«Батый» диеп йөртә ире дә.)

Җирле идарәләр тыю салгач,
Питергача барып җитә ул.
Милли мәктәпләргә закон каршы —
Чигенмәскә карар итә ул.

Шәхси уку йорты ачып кына
Ирешала изге хыялга.
Татар кызларына юлны ача
Гыйлем дигән якты дөньяга.

* * *

Көчле затларның да буе җитмәс
Биеклекне кыю алалган,
Тар карашлы «милләт агайлары»н
Урап үтәр юллар табалган.

Безнең кызлар, монда гыйлем алып,
Тугры хезмәт иткән халкына.
...Гасыр кичкән гыйлем учаклары
Сүнәм-сүнәм диеп талпына.

Иске татар бистәсеннән узам,
Адымнарым кая ашыга?
Коткар, диеп, хәрабәләр аша,
Өнсез тарих чыга каршыга.

## САРА

XX гасыр башында татар кызлары Европа университетларын яулый башлый. Сара Шәкулова (1887 – 1964) – югары математик белемле татар хатын-кызларының иң беренчеләреннән. 1913 елда аңа Сорбонна университетының төгәл фәннәр факультетын тәмамлау хакында диплом бирелә. 1915 елда ул Мәскәү университеты дипломына ия була.

Һәр тугрыда ким түгелбез ирләрдән без,
Гыйлем алсак, иң галимнәренә тиңбез.
Бу милләтнең там яртысы* без булгачдин,
Карап карыйк: иранлардин** ничек ким без?

*М. Мозаффария. «Мәшһүр хатыннар»*

Булды микән берәр тыныч көнең,
Ят күргәнме сине тынлык җаны?
Көрәш өчен туган милләт кызы –
Буыныңда типкән татар каны.

Чорлар аша кабат кайта-кайта,
Мин яд белән карыйм үткәннәргә:
Гомеренең хәләл һәр тамчысын
Гыйлем эстәп фида иткәннәргә.

---

* *Там яртысы* – нәкъ яртысы.
** *Иранлардин* – ирләрдән.

Касыйм шәһәреннән Сорбоннага
Юлың булган урау — Питер аша:
Кыз балага монда вузлар ябык,
Белем ал, дип, Париж үзе дәшә.

Озатканда әнкәң әйткән сүзләр
Чит кыйтгада булды микән терәк:
«Хатын-кызга, гыйлем таҗы киеп,
Үз ирегең даулап алу кирәк!»

Уку авыр, бигрәк авыр, диеп,
Туган якка хатлар язган үзе…
Фән кырында син — Парижны алган
Иң беренче татар хатын-кызы.

Алда — Мәскәү. Салкын канлы кала.
Каршы чыгар кочак җәеп димә!
Син — мөселман һәм… хатын-кыз бары,
Ир-атлардан узма, әй галимә!

Империя кануннары кырыс:
Кем хәлеңә керер, кем соң яклар?
Петербург көтми… Мәскәү — күптән…
Сыендыра, ярый, туган яклар.

Татар рухы, милләт гаме үги
Губернаңның йөрәгенә, Рязань.
Кунак булып бер әйләнсен әле,
Сыендырмас микән шәһри Казан?

Казан, Уфа, аннан — Мәскәү үзе,
Наркоматта эшли янып-көеп,
Мәктәп ача, дәреслекләр яза,
Төнне таңга ялгап, милләт диеп.

Механика фәне башын ия
Профессор ханым — галимәгә.
Татар кызы, техник вузлар яулап,
Остаз була галим-голәмәгә.

* * *

Мәңгелектә йокың тыныч микән?
Юктыр... атмый әле милләт таңы.
Мин дә юкса «укымышлы ханым»,
Миндә дә бит шул ук татар каны?!

Шул ук гамем, шул ук гаҗиз уем:
Милли мәктәп, газиз туган телем.
Хыялымда корам Фән сарае,
Үз телемдә бирер өчен белем.

Ерак төбәкләрдә карендәшләр
Милләт рухын яши гаярь яклап.
Ватанында телгә кадер бетсә,
Читтәгеләр калыр кебек саклап.

Юк, ышанмыйм! Канатлана рухым,
Үткәннәргә әгәр борылып баксам.
Тарих учагының көлен каксаң,
Утлы кузы тетрәп куя үрләп.
Милләт Әнкәләре сулыш өрсә,
Гыйлем учаклары кабыныр дөрләп.

# ҖӘМИЛӘ БӘЕТЕ

«...Зур авырлык белән белем алуга ирешкән кызларның күбесе үзен халыкка хезмәткә багышлый һәм милли-азатлык хәрәкәтенең алгы сафына баса. Татар мөгаллимәләре Урта Азия республикаларында наданлык белән көрәштә күп газап-михнәт чигә, иске фикерле фанатиклар тарафыннан эзәрлекләүләргә дучар ителә, хәтта һәлак була. Җәмилә Юмаева — шул корбаннарның берсе».

*Узган гасырның утызынчы елларында хатын-кызлар хәрәкәтендә актив катнашкан укытучы Вәлиева Әминә Фазыл кызы истәлекләреннән*

Унбиш яшьтә Чистайларда
Укып белем алдым мин.
Үз башыма, күрәчәккә,
Мөгаллимә булдым мин.

Үзбәкстан якларына
Ник җибәрдең, әнкәем?
Балакаем, барма диеп,
Ник әйтмәдең, әнкәем!

Тарих мең дә тугыз йөз дә
Утыз икенче елда,
Тәкъдиремә язган булгач,
Ният иттем мин юлга.

Юл газабы — гүр газабы,
Булмый берни эшләп тә.
Гүр газабы көткән икән
Лагман дигән кышлакта.

Мин аң-белем таратам дип
Килгән идем бирегә.
Милләтчеләр кырын карый,
Карагандай бүрегә.

«Кызыл почмак»ка барганда,
Юлларымны будылар,
Кайткан чакта, артларымнан
Эт өстереп кудылар.

Әнкәй җаным, син күрмәдең
Миңа аткан ташларын.
Әнкәй җаным, сездең микән,
Бик авыртты башларым?!

Үзбәкстан кышлагында
Акты минем каннарым.
Аң-мәгърифәт юлларында
Чыкты газиз җаннарым.

Гыйлем алып, унбиш яшьтә
Мөгаллимә булдым мин.
Уналтыда чит җирләрдә
Корбан булып калдым мин.

Әнкәй җаным, Җәмиләм, дип,
Елыйсыңдыр, бичара.
Күрәчәктән узачак юк,
Гомерең беткәч, ни чара?

* * *

Елама син, үз халкына
Батыр кыз биргән Ана!
Ватан йөрәге түрендә
Һәйкәл куйыйк без аңа.

Ул һәйкәл булсын Хәтернең
Иң якты төсләреннән,
Бәгырь кылында сызланган
Үкенеч хисләреннән.

Китерик аңа чәчәкләр
Яшьлеге язларыннан.
Мәңге бөредә калачак
Сөюе назларыннан.

Ул, җан сулышыбыз булып,
Безнең йөрәккә дәшәр.
Милләт йөрәге типкәндә,
Хәтер дә имин яшәр!

## КЫЗЛАР-ЙОЛДЫЗЛАР

Йолдызлар чиксез галәмдә:
Тыйнагы бар, яктысы.
Калыкты яңа планета –
Туфан* дигән атлысы.

Исемсез йолдызлар күпме,
Кадер-хөрмәт күрмәгән.
(Ә кайберсе үз-үзеннән
Югарырак үрләгән...)

Дөнья күгендә нур сибеп
Балкыйлар безнең кызлар.
Халкы өчен гомерен биреп
Кабынган ул йолдызлар.

## ТӨНГЕ ФӘРЕШТӘЛӘР

Кызыл йолдызлы 46 нчы Тамань гвардия төнге бомбардировщиклар хатын-кызлар авиация полкының 23 кызына Советлар Союзы Герое исеме бирелгән. Алар арасында милләттәшләребез – авиаэскадрилья командиры, керәшен кызы Ольга Санфирова (1917 – 1944) һәм авиаэскадрилья командиры ярдәмчесе Мәгубә Сыртланова да (1912 – 1971) бар. Ольганың дус кызлары кушкан икенче исеме – Ләйлә.

«Алтын кызлар! Көндез дә очалар, төнлә дә. Ә бит хәтта ир-ат очучыларның да һәркайсы аларга тиңләшә алмый, һәрберсе дә төнге очыш маһирлыгына ия түгел...» – дигән полкның батыр кызлары хакында Советлар Союзы Маршалы К. Е. Ворошилов.

---

* Җирдән 250 млн километр ераклыктагы кече планеталарның берсенә Хәсән Туфан исеме бирелде.

Җир-ананың әрни яралары,
Бәгырендә яна ут-ярчык;
Афәт узган тирән эзләр булып,
Йөзләренә сарган җыерчык.

Ватан хакын хаклап,  халкын яклап,
Икеләнмичә хәтта ялгыш та,
Ир-егетләр белән тигез сафта
Кызлар киткән канлы сугышка.

Алтын кызлар, халкым, үстергәнсең,
Егетләргә алар биргесез!
Герой исеме алганнары күпме,
Батырлары күпме билгесез.

Искә алам бүген тик икесен
Мин, яд итеп йөзләр, меңнәрне.
...«Төн пәрие» диеп йөрткән фашист
Төнге фәрештәгә тиңнәрне.

Мәгубә һәм Ольга-Ләйлә алар,
Ике кызы данлы татарның.
Мин аларны, халкым зурлаганча,
Лачын кызлар диеп атармын.

— Исемең — Ольга, үзең — татар. Чынмы?
— Әйе, дөрес, иптәш командир!
...Татар икәнеңне каның белән
Күккә язу сиңа язгандыр...

* * *

Төн пәрдәсен турап, прожекторлар
Төпсез күкне айкый капшанып.
Ут күзенә керә лачын кызлар,
Күкләр ярдәменә ышанып.

Таулар, тарлавыклар... аста – диңгез,
Җил камчылый төрле яклатып.
Киссә кисә юлны ут яңгыры –
Кала алмый үчне туктатып.

Теткәләнгән очкыч канатында
Төшкән чаклар булды сирәкме?
Җиргә кайта кызлар исән-имин,
Мотор итеп ярсу йөрәкне.

* * *

Лачыннарның «Очыш көндәлеге»
Кургаш белән чигеп язылган,
Кулга алсаң, җанны пешерер күк:
Җиңү көнен якынайтыр өчен
Ут йотмаган көннәр аз булган.

Җиңү көне! Рейхстагка җитеп,
Мәгубә дә итә тантана.
Стенага язган исемнәрдән
Хәтерләгез безне дигән кебек,
Бәгыренә гүя кан тама.

Ольга-Ләйлә генә ятып кала
Гродноның мина кырында.
Бу ят туфрак — аның соңгы йорты...
Җилләр йөри риваятьләр сөйләп
Батыр татар кызы турында.

* * *

Уйный күктә төнге аҗаганнар,
Яшен булып тама яшьләре.
Әллә Күктән төнге фәрештәләр
Онытмаска кушып дәшәме?

Соңгы йолдыз сүнгәч моңсулана
Туган якның тыныч таңнары.
Гүя безнең кызлар-лачыннарның
Йолдызларга күчкән җаннары.

Кешеләр дә сүнә, йолдызлар да...
Хәтер генә җирдә мәңгелек.
Йолдызларның хәлен аңлар өчен,
Йолдыз булып кара иң элек.

## ТАТАР ЙӨРӘКЛЕ БИЮ

Мәшһүр балет биючесе, балетмейстр, СССРның һәм Үзбәкстанның халык артисткасы, СССРның Дәүләт премиясе, Үзбәкстанның Хәмзә исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты; ике тапкыр Ленин ордены, СССРның «Почёт билгесе» ордены иясе; көнчыгыш илләре халык биюләрен башкару остасы Галия Измайлованың (1923 – 2010) якты истәлегенә.

Ишетәм мин киереп канат ачканың,
Төн пәрдәсен тибрәндереп очканың;

Билгә урап көяз ефәк җилләрне,
Бөтерелеп, чиксез күкне кочканың.

Биюеңдә күрәм диңгез дулкынын,
Бер ярсуын, бер бик тыныч, алкынын;
Карашыннан йолдыз сирпеп күз кыскан
Кайнар тынлы кышкы учак ялкынын.

Бу биюдә көмеш чулпы чыңнары,
Кубызларның җанга чирткән моңнары,
Сәмаркандның тулган айлы төннәре,
Бохараның җәйге иркә таңнары.

Фирганәгә илтә аның юллары,
Памирларга алып менә югары;
Арыкларның тулып аккан суыдай,
Сулган җанны шифа белән сугара.

Алып китә мине бию еракка:
Һиндстанга, Бирма, Кытай, Гыйракка...
Бию җаны сөйләп биргән кыйссалар
Дәрт уята, ләззәт өсти йөрәккә.

Синең бию көнләү хисен уята,
Кочагында назлап-назлап юата,
Гүзәллекнең гарешенә ашудан
Бәхетемне сулык-сулык елата.

Синең бию — биюләрнең сирәге,
Михнәт аша шөһрәт яулау үрнәге.
Горур да ул, мәһабәт тә, шанлы да —
Биюеңдә тибә татар йөрәге!

## ГИМНАСТИКА ШАҺИНӘСЕ

Тугыз тапкыр дөнья чемпионы исемен яулаган, дүрт тапкыр ил буенча абсолют чемпион булган мәшһүр гимнастка, СССРның атказанган спорт мастеры, Россиянең атказанган тренеры Галимә Шөгеровага (1953) багышлыйм.

> Татарлыктан татар һич гарь итәрме,
> ...Кеше үз исмене инкяр итәрме?
>
> *Дәрдемәнд*

«Мин – татар!
Мин – татар кызы!
Исемемне бозмагыз.
Мин – Галимә, дөресләгез,
Галина дип язмагыз!» –

Дөнья пьедесталыннан
Ул шулай дип чаң кага.
Татар кызы тамырында
Үз милләте, халкы өчен
Горурлык ярсып ага.

Бөеклеккә елдам чумып,
Алтын балыктай йөзә;
Җиңү таҗыннан нур сибеп,
Спорт галәмен гизә.

Таҗик кызлары җыр суза,
Галимәгә багышлап,
Чәчәкләр бүләк итәләр,
Озаталар алкышлап.

Азәрбайҗан шагыйрьләре
Шигъри котлау китерә,
Казахлар, исемен кушып,
Думбрада көй чирттерә...
Ил башлыклары, кул кысып,
Соклануын җиткерә.

Кайда бәйге — анда җиңү,
Кайда җиңү — ул анда.
Көрәштән көрәшкә яшәү —
Татарымның канында.

Гап-гади бер эшче кызы,
Спортта ул — ханбикә.
Галимә-алтынбикә дип
Йөртмиләр аны тиккә:
Нәзакәтлек шаһинәсе
Җиңелмәстәйне җиңә:
Дан тәхетенә — Гигова*
Янәшәсенә менә.

Европада да Галимә
Үз мөнбәрендә кала!
Мадридта ул тиңдәше юк
Чемпион исемен ала.
Ун меңле зал бердәм баса,
Ун минут алкыш ява...

* Мәшһүр болгар гимнасткасы Мария Гигова.

* * *

Укучысыз остазларның
Даны да кыска була,
Кемнең алмаш-дәвамы бар,
Шулар чын оста була!
Безнең спортчы кызыбыз —
Дипломлы мөгаллимә.
Оста да ул һәм остаз да —
Укытучы Галимә.

Сания* белән янәшә
Аның исеме атлый.
Дөньяда һәм Европада
Чемпионка укучысы
Остазы данын аклый.

«Мин — татар!
Мин — татар кызы!» —
Галимә шулай дигән.
Дөнья, алкышларга күмеп,
Милләтемә баш игән.

* * *

Күкләр биргән данлы хөкем —
Татар булу бәхете.
Миңа язган тәкъдирем ул,
Горурлыгым тәхете.

Бу исем мең еллар буе
Көч җыеп куәт алган;
Җиңелмәс рухлы булсын дип,
Язмышка мөһер салган.

---

* Дөнья чемпионы Сания Бабий.

Ул яшәү нуры иңдерә,
Җан тетрәп кабынганда,
Тез чүккәндә, егәр бирә,
Күтәрә абынганда.

Исемем — минем холкымда,
Кыяфәт-килешемдә,
Йөрәгем сулкылдавында,
Җанымның тибешендә.

Ә мин йөртергә хаклымы
Бу кодрәтле исемне?
Дәвамымның тамырында
Татарлыгым исәнме?

Үз-үзеңне җуйма, диеп,
Дәште миңа Хәтерем.
Тарихымны, мирас итеп,
Иңнәремә күтәрәм.

## ЮЛДАН ЮЛГА

Бу сәфәрем тәмамланып килә,
Гыйбрәтле төш минем күргәннәр.
Рәнҗемәгез, искә алмады дип,
Тарих хәтеренә кергәннәр.

Рәнҗемәгез, яшьнәп балкымыйча,
Тыйнак йолдыз булып янганнар;
Ачылмаган әрнүле сер булып
Күкләр күңелендә калганнар.

Һәр дәвернең була үз батыры
Халык исеме белән атарлык.
Кыйблаң җуймый билгесезлек кичү –
Бүген үзе гадел батырлык.

...Салмакланды күңел аргамагым,
Дымсу томан төште күземә.
Гыйбрәт алып шанлы үткәннәрдән,
Кайтып киләм кире үземә.

Ач күзеңне, Акыл, иртәгәмә,
Уйлар газабыннан арын да,
Ишкәге юк көймә көтеп тора
Замананың бирге ярында.

Йолдызларга карап юлга чыгам,
Җилкән итеп ярсу йөрәгем.
Үз кайгымны бүген куеп торам, –
Милләтемә тоям кирәгем.

Минем вакыт... минем сәгатем бу!
Ил язмышы – минем язмышым.
Хыянәтчел җилләр ярга какса,
Ялларына ныграк ябышам.

Мин үги дә, дүңгәләк тә түгел,
Чит итәргә җирем, илемне.
Ни күрсәк тә, бергә күрербез дип,
Чор иңенә куям иңемне.

# Сүнмәс балкыш

*Поэма*

Танылган табиб, төбәгебез тарихын, Казан татарларының мәдәниятен,
гореф-гадәтләрен беренче булып өйрәнгән галим,
тәкъва һәм абруйлы шәхес Карл Фуксның
(1776 — 1846) якты истәлегенә багышлыйм.



*Аның гомер юлы, бөтен күңеле, акыл эшчәнлеге тәүге адымыннан алып соңгы минутына кадәр фәкать бер иманга — шәфкатьлелеккә юнәлтелгән кеше тормышының гаҗәеп үрнәге иде.*

Е. Ф. Аристов (1806 — 1876),
Казан университетының анатомия профессоры

## ТАРИХ БУСАГАСЫНДА

Фукс йорты, бу мин әле, картлач!
Аңлыйм хәлең, берни сорамыйм...
Хуҗаң кайтыр диеп ышандырмыйм,
Тылсым-могҗизалар юрамыйм.

Фикерле аң әверелеш көтә, –
Инкыйлаблар тулы Казан бу!
Күз иярмәс Вакыт иярендә
Киләчәккә җилгән заман бу!

Кайтаралсам әгәр кичәгеңә,
Гафу итәр идең барсын да...
Кешелексез бу кешелек өчен
Җавап тотам гүя каршыңда.

Тетрәнгәндәй була Күк бәгыре,
Төпсез күзләреңдә моң күреп.
Үтәли җил елый моржаларда,
Хәтер учагына тын өреп.

Минем аһны искәрүдән узган
Үгилекнең өнсез мохите;
Әрнеп иңри бары таш диварлар –
Инкыйразның телсез шаһиты.

Рөхсәт бир син, узыйм әле түргә,
Вакыт капуларын кичим дә...
Сүнмәс шәмнең* җан тибешен тоям
Шанлы хатирәләр эчендә.

## ТАБИБЛЫК

Табиб ул – Ходай тиңендәге акыл иясе.

*Гиппократ*

Казанымда янгын шәүләсеме,
Сызылып алсу таңнар атамы?
Кемгә монда – сөрген, ә кемнеңдер
Бу – икенче йорты-ватаны.

Алман иле! Укымышлы улың
Әллә кайтмыйм диеп киттеме?
Татар җаны аны үз күргәнме,
Ул Казанны якын иттеме?

Табиб Фукс керми калган бер йорт
Булды микән якын-тирәдә?
Ярлы алачык та көткән аны,
Затлы гүрничәдә түрә дә.

*Карл Фуксны замандашлары «Идел төбәгенең шәме» дип атаган.

Кечелекле табиб кешеләрне
Кан кардәштәй күреп яраткан:
Күңел яктысын да, җылысын да
Ул һәркемгә тигез тараткан.

Тормыш муллыгында йөзгәннәргә
Тән сихәте, гомер биргән ул,
Ярлы-ябагайга йөрәк тулы
Рәхим-шәфкать алып килгән ул.

Табиб Фукс аяк баскан өйнең
Савыктырган хәтта һавасы;
Ул орынса, хаста-сырхауга да
Тигән, диләр, шифа-дәвасы.

Тәнне генә түгел, әүвәл җанны
Ягымлы сүз белән имләгән.
Алла хакы, диеп ярдәм иткән,
Аяк хакы өчен килмәгән.

Бар мөлкәте аның — китаплары.
(Фәһемлелек өчен көрәшкән!)
Тыйнак керемнәрен, кызганмыйча,
Юксыл бәндәләргә өләшкән.

Аңа яуган рәхмәтлелек хисе,
Белмим, кемгә насыйп булгандыр?
Ходай сөеп биргән бу изге җан
Казан бәхете өчен тугандыр.

Котылгысыз афәт-чирләрнең дә
Хәйләсенә табиб төшенә.
Акылын да, бөтен йөрәген дә,
Гомерен дә баглый эшенә.

Эчкерсезлек аша кешеләрнең
Ышанычын яулый алганмы?
Шуңа да ул гомер соңынача
«Безнең Фукс» булып калганмы?

Бу сүз — аңа иман китерү ул,
Кодрәт иясенә җан ату.
Моннан гайре өстен була ала —
Бер Аллаһны гына ярату!

## ГАЛИМЛЕК

Профессор Фукс — могҗиза! Аның укымышлылыгы. Татар медальләре белән мавыгуы. Татар һәм гарәп телләрен белүе. Тәкъва һәм әхлаклы шәхес...

*Себер генерал-губернаторы*
*М. М. Сперанский. 1819*

Геттингенның фәнни мәктәбендә
Билгеләнгән аның юл башы,
Яшьлектәге шөгыль-мавыгулар
Гомерлеккә булган юлдашы.

Европаның «асыл сөягенә»
Рәсәй кыргыйлыгы кунмаган:

Тынгы белми, рухи мая җыйган,
Аң-белемгә сусап туймаган.

«Идел төбәгенең шәме» булып
Алман диндарлыгы талпына;
Горур тәкәбберлек аша түгел,
Олы хөрмәт белән халкыма.

Караңгыны камап кабынган да
Сүнмәс балкыш булып яшьнәгән;
Газиз милләтемнең кан тибешен
Табибларча тоеп яшәгән.

* * *

Фукс йорты! Кичермә син безне,
Мәнсезлекне кертмә ишектән!
...Зал, кабинет, бельведерда* гүя
Рәнҗү катыш елау ишетәм.

Өске катта булган китапханә.
(Гүя Хәлфин** сыны чагыла.)
Алып керә мине хатирәләр
Йортның гөрләп торган чагына.

---

**Бельведер* – бинаның тирә-якны манзара кылу өчен түгәрәкләп эшләнгән ябулы өскормасы.

***Ибраһим Хәлфин (1778 – 1829)* – татар грамматикасына нигез салучы галим.

Казна хезмәтеннән кайткан табиб
Нәрсә яза көн дә җентекләп?
Казан татарлары мәгыйшәтен
Теркәп бара шулай бөртекләп.

Төпле-төгәл итеп тасвирлый ул
Татарымның кәсеп-шөгылен,
Гореф-гадәт, дини йолаларын,
Төс-кыяфәт, холык-фигылен...

Табиблыгы уңай килеп тора —
Күп ишетә галим, күп күрә:
Сенатор да, авыл агае да
Ышанычын аңа белдерә.

Иң кадерле кунак безнең Фукс
Җыенында, никах, туенда...
Interesse* юкка гына түгел, —
Китап язу аның уенда.

Ул тергезгән «Казан тарихы» да
Мәңге җуймас асыл-кыйммәтен:
Үткен алман күзлегеннән карап,
Үз ханнарын таный милләтем.

---

* Interesse *(нем.)* — кызыксыну.

* * *

Дүрт-биш телдә иркен сөхбәтләшкән
Һәм өйрәнгән шәрык телләрен;
Әнкә теле түгел, тәңкә теле
Ачкан аңа тарих серләрен.

Тәңкәләрдән «күреп белә» галим
Чыңгыз ханның һәрбер варисын,
Бату ханнан Мөхәммәдкә кадәр
Җүчи олысының тарихын.

Үз баласы кебек кадерледер
Бу тәңкәләр алман улына:
«Өлкәнәйгән көндә мин бәхетле,
Күчсә мирас яшьләр кулына».

«Мөлкәте»ннән халык файдасына
Аерылганга Фукс көенми:
Бу тәңкәләр чыңы Азияне
Рәсәй тарихына төенли.

* * *

«Рәтсез кулга» калып, төрле якка
Таркатылган мирас, вакланган;
Сирәк кулъязмалар, китапларның
Бер мыскалы гына сакланган...

Тукта, Хәтер, ерак китмә алай,
Бер мизгелгә әйдә тукталыйк!
Кунак бүлмәсенең ярым ачык
Ишегеннән эчкә күз салыйк.

## ЗЫЯЛЫЛЫК

«Карл Фёдоровичка олуг хөрмәтемне җиткерсәгез иде, аның мөлаемлыгы, илтифаты мәңге онытылмас...»

*А. С. Пушкинның А. Фукска язган хатыннан;*
*9 октябрь, 1834*

Җанланалар кинәт таныш сыннар,
Бүгенгедәй күрәм барсын да:
Александра Фукс! Нинди бәхет:
Александр Пушкин — каршында!

Син тартынма, укы шигырьләрең,
Мизгел күзләренә кара да.
Бары сирәк кенә язган хатлар
Йөрер тиздән ике арада.

Ә хәзергә сездә шагыйрь үзе,
Галиҗәнап Пушкин — янәшә!
(Муза булу түгел омтылышым,
«Шагыйрәлек» синнән көнләшә.)

Ул эчкерсез һәм рәхмәтле бүген,
Игътибарлы, ачык күңелле,
Кунак булып безгә килегез, ди.
(«Шагыйранә ялган» түгелме?)

Доктор Фукс никтер тоткарлана,
Чәй суына әнә табында.
Пушкин хәтле Пушкин анда кунак,
Ә ул сырхаулары янында!

(Телдәрләргә әгәр колак салсаң,
Шундый хәл дә, имеш, булган, ди:
Күбәләкләр куып йөреп, Фукс
Никахына соңга калган, ди.)

Үз эшенә тугры бирелгәнлек
Сеңгән тырыш алман канына.
...Ул бер төркем җандашлары белән
Кайтып керә Пушкин янына.

Бөек шагыйрь – яхшы әңгәмәдәш –
Тарих сөйли моны сагынып.
Бу әдәби кичә очкынынnan
Дәртле илһам кала кабынып.

Пушкин исә шушы сәфәреннән
Хатынына язган хатында:
«Акыллы һәм галим немец», – диеп
Искә алыр Фукс хакында.

Акыллы һәм галим немец, әйе, –
Моңа өстәп нәрсә диясең?
Бик сирәкләр генә яулый алган
Бу бибәһа акыл иясен.

Кыргыз-кайсак ханы Җиһангир дә,
Сенатор да килә кунакка...
Кенәз, нашир, рәссам, зур шагыйрьләр
Фукс данын илтә еракка.

Игътибарны Александра ханым
Бүлешмәгән диеп кем әйтер?
(Профессор ирнең мөнбәреннән
Тормыш аны күпкә өйрәтер.)

Бу нигезгә чорның шаһбазларын
Кем абруе дәшеп алгандыр?
Инсаннарның сөеклесе Фукс
Ир дә, идеал да булгандыр.

«Ире көен көйли...» — гаеп түгел —
Бар вөҗүде аңа көйләнә:
Казан төбәгенең тарихын да
Ире шаукымында өйрәнә.

Ул — әдәби салон алиһәсе,
Шагыйрә... һәм иңдәш табибка. —
Дворянка Апехтина-Фукс
Шулай кереп кала тарихка.

## БӘХИЛЛӘШҮ

К. Ф. Фуксны татар һәм рус халкын, аларның рухи бәйсезлегенә дәгъва кылмыйча гына, Болак аша бердәмлек төеннәре белән тоташтырырга тиешле күпернең тәүге ташы иде диярга мөмкин...

*Н. И. Воробьёв (1884 – 1967),*
*тарих фәннәре докторы,*
*Казан университеты профессоры*

Иске коляскада кырлар буйлап
Фукс картлач кая юл чыга?
«Көзнең кыр киеме — тоташ сары —
Ялыктыра, күңел талчыга...

Якыная менә минем көзем,
Иске дуслар сирәк күренә.
Күпме эшләр кала башкарасы –
Менеп җиттем гомер үренә...»

Куеп торчы бу күңелсез уйны,
Кая сәфәр чыктың? – шуны әйт.
Спас өязендә ни йомышың?
Чистайларга илтә ни ният?

Бүген аның бөтен илтифаты,
Игътибары мордва халкына:
«Ничек тәэсир итә тормыш шарты
Бу халыкның акыл-холкына?

Руслашканнар! – галим шундый уйда, –
Кием-салым русча, йөз-килеш...
«Вак» милләтләр үз кыйбласын җуяр,
Барса дөнья һаман бу килеш».

...Бер-ике көз шулай узып китә,
Өченчесе ишек какканда,
Җан тетрәткеч каза күрә Казан,
Иҗтиһадлы яшәп ятканда.

* * *

Казан 1815 һәм 1842 елларда коточкыч янгыннардан гаять зур зыян күрә. Карл Фукс 1815 елда, афәт буласын алдан сизгәндәй, губерна канцеляриясенә монда сакланган бибәһа тарихи документларның күчермәсен алу кирәклеге турында берничә мәртәбә мөрәҗәгать иткән була, әмма берсендә дә аның сүзенә илтифат итүче булмый.

Соңрак Фукс: «3 сентябрьдә котырган янгын губерна идарәсен чолгап алды. Мин анда кереп грамоталарны коткарып калырга омтылып карадым, ләкин янгын шулкадәр көчле иде ки, мин бу уемнан кире кайтырга мәҗбүр булдым», — дип искә ала.

Элгәрерәк чорларга күз салсак, 1611 — 1612 елларда Мәскәү Кремле поляклар кулына күчкәч, көчле янгын вакытында Нугай һәм Кырым ханлыкларына кагылышлы тарихи документлар исән калып, нәкъ менә Казан ханлыгына мөнәсәбәтлеләре юк ителә. 1815, 1842 елгы янгыннар вакытында Казан архивлары да ут гарасатыннан көл була.

Казанымда янгын шәүләсеме,
Утлы балкыш — Кояш калкамы?
Бер мизгелдә Проломныйны камый
Ут-дәһшәтнең көчле ялкыны.

Шашып-ярсып котырына давыл,
Бар шәһәрне көчле ут ала.
Чиркәү чаңы, шартлау, елау-сыктау —
Барсы бергә күктә бутала.

Ут ташкыны, Болак аша чыгып,
Ялмый башлый Татар бистәсен.
Гомер буе җыйган бу тарихны
Ничек шулай ташлап китәсең?

Сандыкларда – сирәк минераллар,
Кемнән ярдәм көтеп торасың?
Коллекция, китап, картиналар... –
Коткарырга кирәк барысын!

Күтәрә дә авыр бер сандыкны,
Фукс картлач тышка омтыла:
Картлыгы да, бөердәге таш та,
Дөнья гаме – бар да онытыла.

...Төтен сулап ята хәрабәләр,
Булганы юк мондый казаның.
«Феникстай, үз көленнән калкып»,
Кабат туар чоры Казанның.

* * *

Ут афәте йортны читләп үтә –
Күкләр мәрхәмәте түгелме?
Сәламәтлек кенә кинәт какшый...
Рух чүксә дә, сынмый күңеле!

Саулык китә... Тормыш дәвам итә,
Эшли Фукс таңнан төнгәчә:
Ходай биргән бүләк – табиблыгын
Алып бара соңгы көнгәчә.

Безнең Фукс, дан үренә менеп,
Карый гомер язы багына...
Шәфәгынның соңгы чаткысыннан
Сүнмәс балкыш булып кабына.

…Болыт кебек агылып, бөтен Казан
Килә аның «соңгы туе»на.
Икенче һәм мәңгелек йорт хәзер –
Сөйгән каласының куены.

Ят туфракка берегеп, бу гали зат
Милләтемә хезмәт иткәнме?
Алман булып җиргә килгән дә ул,
Казан улы булып киткәнме?

* * *

Фукс һәйкәленә Хәтер килгән,
Фукс бакчасыннан Уй үтә,
Лютераннар кирхасында Вөҗдан
Изге Фукс рухын яд итә.

Йорты гына үги ятимлектә,
Тиздән соңгы таңы атармы?
Җиргә иңә сыкрап таш диварлар,
Айнытырга теләп татарны.

Кирха залларында шәм кабына,
Чорны дәшеп иман юлына…
Фукс йорты! Синдә дога кылам
Татар җанлы алман улына.

# Төрки дөнья таҗы — Төркия

Шигъри юлъязма



*Күктән бирелми Азатлык,*
*Даулана яу кырында.*
*Атасы булган милләтнең*
*Ияре үз кулында.*

## ҺАВА ЮЛЫ

Дөнья күрим, сәфәр чыгыйм дигән кеше
Кәсеп итә, эзли җаен, таба юлын.
Соң булса да, уң булсын дип, тәвәккәлләп,
Мин дә менә ниятләдем Һава юлын.

Җирнең тарту көчен җиңеп, күккә ашам,
Тик нигәдер күңел генә сагаюлы.
Белгән догам, булган бурыч-әҗәтләрне
Исләремә тиз төшердең, Һава юлы.

Күтәрелеш, очыш алыш, һушсыз калыш...
Гүя җанның Гарше көрси таба юлы.
Минем бары инсан гына икәнлекне
Тагын бер кат искәрттең син, Һава юлы.

# ТӨРКИ ДӨНЬЯ ТАҖЫ — ТӨРКИЯ

Европага акыл төбәп яши
Олы гамьле Кече Азия.
Анатолия, Пергам, Византия...
Ун мең еллык сер-хәтергә ия
Төрки дөнья таҗы — Төркия.

Бронза гасырлардан бүгенгәчә
Азат рухлы булды Төркия.
Троя явы, Тәре походлары,
Көчле империя вакытлары...
Ататөрек иле Төркия.

Борынгылык белән заманчалык —
Игез балаларың, Төркия.
Зәңгәр мәчет, музей, әхрамнарың,
Чәйханәләр, базар, бульварларың
Күңелеңә сыйган, Төркия.

Дүрт диңгезнең дәрт-дәрманы кага
Йөрәк тибешеңдә, Төркия.
Кояш егәрлеген кыю җиккән,
Тау-ташлыкны җир оҗмахы иткән —
Яши белеп яши Төркия.

## ТАТАР АКЫЛЫ...

### (төштән соң түгел)

Барлык төрки дөньяда, Европа илләрендә мәгълүм милләттәшләребез Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Йосыф Акчура, Әхмәтзәки Вәлиди Туган кебек шәхесләрнең исемнәре узган гасырның 20 нче елларында яңа төзелгән Төркия Республикасының сәяси-мәдәни күгендә якты йолдыз булып кабына.

Басып торам хәтер ярларында,
Чит күкләргә багып, аптырап.
Төркиядә төннәр кыска икән,
Ярымае балкый яктырак.

Йолдызларны барлыйм күңелемнән:
Гаяз, Садри, Йосыф, Вәлиди...
Үткәннәрне хаклар сәбәп эзлим,
Уйда бәргәләнеп, аң йөди.

Акыл ага Европага таба,
Нинди хәтәр җилләр куганнар?..
Үз йортында дошман саналганнар
Ят нигездә туган булганнар.

Тарихларны була аклап... таплап,
Үз-үзеңә булмый алдашып.
Күк тә шул ук, Ярымай да уртак,
Җаннар гына йөри адашып.

Йолдызларның нуры арта бара
Узып вакыт күге аркылы...
Төркиянең таңы атсын өчен,
Кирәк булган татар акылы.
Татар акылы!

# МӘДХИЯ

Мидас* патша мирасыдыр – Анкара,
Иске шәһәр эргәсендә – яшь кала.
Кунак булып кер, дия,
Үз өеңдәй күр, дия,
Мең мәрхәбә башкалаңа, Төркия!

Тау сафларың сәждә кыла Раббыма,
Диңгезләреңгосел арган рухыма.
Изгеләргә – мәдхия,
Әрвахларга – мәрсия,
Азан әйтеп җан сугара Төркия.

Табыныңны ямьләп тора пәхләвә,
Тел очында эреп тора кәләвә,
Чикләвекле хәлвәсе –
Татлы өлеш һәммәсе.
Рәхәтлукум... тәмлетамак Төркия.

Керфекләре – сәлҗүк угы – Айзирәк,
Чәче – Тарсус шарлавыгы – Айбүләк.
Яшь пальмия** – Талия,
Зәйтүн гөле – Зөлфия...
Чук гүзәлләр ватаны син, Төркия.

---

**Мидас* – риваятьләр буенча, б. э. га кадәр VII гасырда Анкарага нигез салган, байлыкка табынып яшәгән патша.

** *Пальмия (төрек.)* – пальма.

# БӘХЕТЛЕ МИЛЛӘТ

Төркиянең беренче президенты Мостафа Кемаль Ататөрекнең: «Мин – төрек!» дип әйткәндә, үземне бәхетле саныйм», – дигән сүзләре, милли шигарьгә әверелеп, Төркиянең һәр почмагында диварларга, һәйкәлләргә, хәтта тау маңгайларына уеп язылган... Кайсы шәһәргә барма, мәйданнар түрендә Ататөреккә һәйкәл куелган.

Чын бәхет кичерер идең
Син бүген, Ататөрек,
«Мин – төрек!» дип горурланган
Балаларыңны күреп.
Яши халкың син сайлаган
Кыйблага тугры калып,
Һәр сулышта исемеңне
Яд белән искә алып.

Хәрбиләрчә елгыр аңлы,
Салкын канлы булгансың.
Ил-йортыңның мәгыйшәтен
Гел яңача коргансың.
Көрәшкәнсең курыкмыйча
«Милләтче» ярлыгыннан,
Азат итәм дип халкыңны
Аң һәм рух тарлыгыннан.

*

Грек, әрмән, яһүдиләр
Санлаган төрек илен,
Төркияле булыр өчен,
Өйрәнгән төрек телен.

«Төрек булу — бәхет», — диеп
Әйткәнсең, Ататөрек...
Ятимлек ачысын тойдым,
Бәхетлеләрне күреп.

*

Ярымайлы һәм йолдызлы
Төркиянең әләме.
Ул — солтанлы, хәлифәтле
Үткәннәрнең сәламе.
Төркия канаты — байрак,
Гел биеккә талпына.
Югары тот уеңны, дип
Дәшә гүя халкыңа.

Һәйкәлләре дә мәһабәт —
Атлары аягүрә...
Каян килә бу горурлык? —
Тез чүкмәгәнгә күрә!
Әрнүле яшәү асылын
Аңладым шул чагында:
Күктән бирелми Азатлык,
Даулана яу кырында!
Атасы булган милләтнең
Ияре үз кулында!

# ИЛАҺИ ЛӘЗЗӘТ

Диңгез буенда тумасак та,
Бездә диңгез каны бар.
*Марсель Галиев*

Дулкын күкрәгенә башым куеп,
Тыңлыйм алкын йөрәк кагышын.
Син күптәнге хыял идең, Диңгез,
Син – бүгенге кыргый табышым.

Зәңгәр күзләренә сөеп карап,
Иярләдем Диңгез күңелен.
Бар хәятым белән тапшырылып,
Ялларына кереп күмелдем.

Ул да миңа буйсынгандай булды,
Ятсынмады, кире какмады.
Сырт кабартып, бераз уйнаклады,
Әмма ярга чөеп атмады.

Бер тән, бер җан булып кушылдык та
Тирбәләбез икәү бер тында.
Бу – илаһи ләззәт – эротика...
Үлеп туу төпсез упкында.

Дулкын мине куенына алды,
Юашланды йөрәк кагышы...
Син кичәге хыял идең, Диңгез,
Син – бүгенге нәүмиз табышым.

Бер татыгач иләс бу тойгыны,
Кире кайтмаганнар сирәктер...
Диңгез рухын тояр өчен,
жанда
диңгез каны тибү кирәктер.

## МАНЗАРА

Тахталыда* болыт черем итә,
Көн сүрелеп, кичкә авышкач,
Тау салкыны сихри Ак диңгезнең
Кайнар тыны белән кавышкач.

Тахталыда болыт черем итә,
Күк гөмбәзле биек тирмәдә;
Наратларның бөдрә бишегендә
Күләгәсе изрәп тирбәлә.

Тахталыда болыт черем итә,
Тау башында кырын яткандай,
Кояш нурларыннан чакма чагып,
Ләззәтләнеп  челем тарткандай.

Тахталыда болыт черем итә,
Ак яллары төшкән салынып...
Тау әкиятен бер күрү дә җитә,
Яшәр өчен мәңге сагынып.

---

* *Тахталы (Олимпос)* – Төркиядәге тау исеме.

## ТӨНГЕ БИЮ

Талгын көй тарала бар тәнгә,
Чымырдап тамырдан аккандай...
Дулкыннар алкышлый бу җырны,
Төн кошы канатын каккандай.

Балавыз шәменең хуш исе
Тарала җилпенә-җилпенә.
Төнге бар, пальмалар, фонтаннар
Чумганнар сихри моң иркенә.

Кичәнең тылсымлы балкышы —
Ап-актан киенгән кыз бала,
Җилкенчәк дәртенә ияреп,
Ялгызы биергә кузгала.

Текила, сабыр ит, текила...
Чәркәдә тирбәлеп ай йөзә.
Яшь сынны күзәткән ханымнар,
Уфтанып, үкенечле уй гизә.

Диңгездә ул бүген соңгы көн,
Ул бии аерылу кайгысын...
Текила, сабыр ит, текила,
Ир-атлар хисләрдән айнысын.

Гитара кылында көй елый,
Йөрәккә, сулкылдап, моң каба...
Кыз бии... Тимәгез, биесен,
Ишетәмсез, Ак диңгез кул чаба.

## ТӨРЕК МУНЧАСЫ

### *(Шаяру)*

Евро-апаны парланырга өйрәткән төрек мунчасы шушымы?

Килгән-килгән — бер керим,
Төрек мунчасын күрим;
Чабынырмын туйганчы,
Арып хәлдән тайганчы.
Ах, төрек мунчасы,
Әллә чыгып качасы?!
Эзләдем җиллекләрен,
Тапмадым миллекләрен.

Кергән-кергән — юыныйм,
Сихәттә бер коеныйм...
Уптым бар да тулдылар,
Парланырга булдылар.
Ах, төрек мунчасы,
Юк икән мунчаласы,
Уртак икән ләүкәсе,
Әттәгенәм, әнкәсе!

Җәймә урап парландым,
Эчтән генә зарландым.
Кем соң инде чит илгә
Мунча керергә килә?!
Ах, төрек мунчасы,
Үзләренә булсачы!
Чын мунча — бездә генә,
Йөзим диңгездә генә!

## ТӨРЕК ЕГЕТЕНӘ

Бөдрә чәчең куесына төн сыйган,
Кош канаты – кыйгач кашың кем уйган?
Син Фәрхәт дип, күпме Ширин баш җуйган, –
Ләкин мине әсир иткән син түгел…

Гүзәлсең дип, хәрәм сүзләр сөйләмә,
Ымсындыргыч «Түркү» җырын көйләмә.
Ялгышып та төшмәм ятьмә-хәйләңә, –
Күңел кылым тибрәткән моң син түгел…

Татлы сыең ширбәтме соң, балмы соң?
Авыз иттем инҗирен һәм алмасын.
Тәшәкүр*, дим, тик хәтерең калмасын, –
Бу оҗмахка дәшкән ярым син түгел…

Сезнең һава – җанга дәва, ни хикмәт,
Диңгезегез тәнгә бирә мең сихәт.
Кунак булдык, инде китү мәслихәт, –
Янәшәмнән кайтыр бәхетем син түгел…
Бигайбә!

---

* *Тәшәкүр (төрек.)* – рәхмәт.

## ХУШЛАШУ

Нигә купты күңелең ярларыннан? –
Иләсләнеп канат кагасың.
Минем сагыш синекеннән тирән,
Каласың бит, Диңгез, каласың...

Чал дулкыннар аяк чалып уйный,
Тартып ала кире үзенә.
Тозлы үкенечне йота-йота,
Кереп чумам диңгез күзенә.

Муенсаңнан сибелгәнме ташлар?
Истәлеккә берсен алыймчы;
Очрашуга юрап, учкаеңа
Мин дә көмеш тәңкә салыймчы?

Ярсу хисләремә җандаш иткәч,
Ташлап китү сине ямансу...
Үз ярыңа кайт дип, салмак кына
Хәтеремә кага Казансу.

# Сер турында хикәят



*«Хан казнасы бик тирән яшерелгән, ди. Ул урынны тапсаң да, хикмәтле бер серне белми торып, хәзинәне өскә күтәрү мөмкин түгел икән...»*

«Югалган хан казнасы турында риваять»тән

## 1

Гарасат куптымы түбәндә —
Казансу тынгылык югалтты.
Гөрелте, хәрәкәт ташкыны
Әрнүле хәтерен чуалтты.

Әйтерсең замана ахыры,
Җир гүя баштүбән әйләнде:
Елганың аръягын кирмәнгә
Су асты юллары бәйләде.

Казансу Сер йөртә куйнында,
Тайпылмый ант-вәгъдә сүзеннән,
Яшереп ничәнче гасырлар
Нәфесле дөньяның күзеннән.

Шушы Сер ачылса җиһанга,
Бу гасыр итәчәк тантана:
...Түбәнге Кабанның төбендә
Ханлыкның казнасы саклана.

Имеш, ди, беркөнне тәхеткә
Чын хуҗа — Ирдәүләт киләчәк.
Байлыкның күмелгән урынын
Сер аңа күрсәтеп бирәчәк.

Бирелеп хафалы уйларга,
Ярларга бәреләә Казансу,
Угрылар кулына керер дип,
Ханлыкның мирасы — казнасы.

Ул көтте менгәнен ияргә
Ханнарга иш булыр алмашның.
Ватаны, милләте хакына
Җан фида кылырлык Илбашның.

Нигәдер шом сала җанына
Ияле-иясез бу заман.
Казнага баш булып алмасмы
Очраклы узгынчы-узаман?

2

Һәм юллый ул Серне Кабанга,
Яшер, дип, хәзергә еракка.
Нәзерен тапшыра ышанып
Гасырлар илчесе Болакка:

«Уятмыйк үч-нәфрәт давылын,
Вакытсыз кузгатып үткәнне;
Көтсен Сер-әманәт тирәндә
Үз көне, сәгате җиткәнне.

Калкыр ул берзаман югары,
Дөньясы килгәчтен аңына.
Хәзергә Сер-ачкыч күмелсен
Ханлыкның казнасы янына».

Күндерә сәйярга фәрманын:
«Кузгал, — дип, — син юлга, төн узгач.
Җитәрсең туганым Кабанга,
Нәкъ җиде күперне син узгач...»

Таң белән җир асты юлыннан
Әманәт кузгала сәфәргә.
«...Ак кирмән янында зур күпер
Озатып җибәрер шәһәргә.

Көн туса, меңләгән кешене
Ул күпер иңеннән үткәрә.
Төн җитсә, күкләргә ашкандай,
Канатын югары күтәрә...

Баржалар, көймәләр агыла
Йөк төяп мул сулы Болактан.
Көтәрмен хәерле хәбәрләр,
Күзләрем алмыйча шул яктан... » —

Хәтерен җуйганмы Казансу,
Исенә алдымы үткәнен?
...Сизми дә калды Сер җир аслап
Ак кирмән янына җиткәнен.

## 3

Тапмагач «канатлы» күперне,
Юлчыбыз тукталды сагаеп.
Таныды Болакны... Тик нидән
Калган ул саегып, тараеп?

Күкләрдән иңгәндәй, калыккан
Нәкъ сигез фирүзә манара.
(Кол Шәриф язмышы хакында
Хакыйкать хәтердә яңара.)

Әйтерсең чорлардан кисәтү —
Шомлы уй кабына күңелдә.
Ак кирмән дивары тын калган,
Таныш та тирә-як, түгел дә...

Неоннар яшьниләр җемелдәп,
Яшәргән таш кала, үзгәргән.
...Яшерә Болак үз куйнына
Юлчыны мәкерле күзләрдән.

4

Озак та бармый Сер, юлында —
Зур күпер, заманча, килешле.
Кабаннан килгәндә монысы
Алтынчы булырга тиешле.

«Сәүдәгәр Ложкиннан» — эңгердә
Бер язу чалына күзенә.
Сискәнеп, дикъкатен юнәлтә
Юлдашы Болакның сүзенә:

«Карама як-якка, ашык син,
Ышанма хөсетле заманга.
Якты көн эзеңә төшкәнче,
Җит тизрәк Түбәнге Кабанга».

Каршында — тагын бер ташкорма,
«Өркәч»е шәйләнә өс якта.
Атаклы «Күз яше күпере» —
Болактан ишетте ул хакта.

Монысын Лебедев төзеткән,
Йөрегез, рәхәтен күрегез!
Тукталып бераз тын ала да
Кузгала мосафир Серебез.

«Романов», «Дегтярёв», «Батурин» –
Гүяки һәйкәл бу күперләр...
(Тарихны белгәннәр аларны
Башкача исемләп йөртерләр.)

Юк «Печән базары», күпере...
Ә Болак хәтерли барысын:
Төенләп торганнар шул алар
Уң Болак – Сул Болак арасын.

Иң өске күпергә җитә дә
Туктый Сер бераз ял итәргә.
Аннан соң, юлдашын калдырып,
Уйлый ул Кабанга үтәргә.

Бу – «Татар күпере». Кайчандыр
Шулай дип йөртелгән халыкта.
Ул чакта зур сәүдә кайнаган,
Мул булган Болакта балык та.

Һәм Пётр Беренче узган, ди,
Җилдереп бу юлдан атларда.
Ярларны бәйләгән көймәләр,
Болактан су ташкан чакларда.

Илткән юл борынгы бистәгә
(Исеме нәкъ шуннан алынган).
Юк Татар бистәсе. Күпер дә
Заманга турылап салынган.

### 5

Хәл алгач, кыюлык яңарткач,
Тотына йөзәргә колачлап,
Аннан соң саркый Сер Болактан
Кабанның ярына җир аслап.

Җырлаучы фонтаннар астына
Туктый да мосафир җай гына,
Су өсләп, ай юлы буйлатып
Юнәлә аргы яр ягына.

Ук сыман тамгага җитүгә,
Яңгырый азан да Казанда.
Бер-ике дилбегә буй йөзеп,
Серебез юк була Кабанда.

### 6

Кабанның төбендә ниләр бар? —
Сер күрә аларның барсын да.
Болары — бары тик таш тәти
Ханлыкның казнасы каршында.

Төннән дә куерак караңгы,
Үтә ул кырык ләм катламын.
Балыклар күрми дә, белми дә
Кай төштә Сернең ни тапканын.

Ә анда? Андамы?! Ниләр юк!
Манзара аяктан егарлык:
Ул байлык, зиннәтле мөлкәтнең
Түгел, ди, санына чыгарлык.

Зөбәрҗәт, якутлар, энҗеләр,
Баш хәтле алмазлар дисеңме?
Бик затлы ташларның бар хәтта
Үзенә кушылган исеме.

Саф алтын һәм көмеш тәңкәләр,
Исәбен-хисабын кем белгән!
Ханлыкның табышы, бүләкләр
Өс-өсләп, тау кебек өелгән.

Илбасар ерткычлар күзеннән
Байлыкны кем болай яшергән,
Кирмәннән кем монда ташыган —
Серебез исенә төшергән.

Барлагач ханлыкның казнасын,
Үзенә бишек тә тапкан ул:
Энҗеле кабырчык эченә
Шым гына кергән дә яткан ул.

**7**

Хакмы бу, түгелме — анысын
Бары тик киләчәк ачыклар.
Эзлиләр гауваслар байлыкны,
Качып та, ачыктан-ачык та.

Табыла борынгы тәңкәләр,
Муенса, беләзек, алкалар,
Ханлыкның шәүкәтле чорында
Коелган сөңгеләр, балталар.

Өметне җылытып, кайчакта
Эләгә кисмәк тә, казан да...
Тик корыч ыргаклар язылып,
Ычкына бар табыш Кабанга...

## 8

Ни хакта серләшә өч туган —
Мин дә шул белмим ул кадәрен.
Казансу тынычлык тапмаган,
Алса да Болакның хәбәрен.

Ә Кабан аз сүзле, гел моңсу...
Уйдамы йә сабыр итәме?
Ханлыкның бибәһа казнасын
Тапшырыр Илханны көтәме?

Борынгы хәзинә — Сер таҗы
Ачылыр кайсы чор-буында?
Йа Раббым, насыйбын әйләсен
Ир данын ил малы итәрлек
Дәүләтле халкымның улына!

# Сине җырымда сөям



*Җан авазым туа җырлар булып,*
*Моңсыз калсам, белмим, нишләрмен.*
*Сүзләр белән әйтә алмаганга,*
*Җырга салам яшерен хисләрем.*

## ДӘШМӘ МИҢА, СОҢ ИНДЕ...

Кочагыңнан тартып алды
Каты куллы язмышым.
Ә мин юләр, ычкынмыйм дип,
Кулларыңа ябыштым.

Кулың салкын, карашың ят,
Күзләреңдә боз иде.
Назың күчкән башкаларга...
Тотма кулдан, соң, диден.

Башым иеп, ялгыз атлыйм,
Киселде өметләрем.
Төзәтик ялгышларны, дип
Дәшәреңне көтмәдем.

Бәгырем — таш, күземдә — яшь,
Миңа юлдаш моң инде.
Теләсәм дә, кичералмыйм,
Дәшмә миңа, соң инде.

# ЯЛГЫЗ ӘНКӘЙ

Рәнҗетмикче әнкәйләрне,
Хат язганчы, кайтып килик.
Күчтәнәчләр юллаганчы,
Бер күрешеп, хәлен белик.

Кушымта:

Көннәр үткән, төннәр үткән,
Ни арада картлык җиткән?
Җилдәй искән гомеркәйне
Газиз әнкәй ялгыз кичкән.

Сагынулардан сыза-сыза,
Күңеле һаман безне көтә,
Тик капканы каерып ачып,
Җилләр генә узып китә.

Кушымта.

Кайтып киләм башым иеп,
Бәхиллегең алыйм диеп,
Йа Ходаем, каршы алсын
Якты утың, җылы өең.

Кушымта.

## КУРА ҖИЛӘК

Кура җиләк пешкәндер, дип
Чакырдың урманнарга.
Күмелдек икәү кереп без
Ут янар куралаларга.

К у ш ы м т а:

Коела инде куралар,
Җил үтте аралардан.
Ялгызым йөрим адашып
Куралы аланнарда.

Җем-җем яна кура җиләк,
Җыймыйча булмый түзеп,
Уч тутырып кура җиләк
Ашаттың миңа өзеп.

К у ш ы м т а.

Иң бәхетле чакларымны
Хыялда йөрим гизеп.
Кура җиләк кабат пешкән,
Тик кем ашатыр өзеп?

К у ш ы м т а.

## ПАР АЛМА

Алларыма килеп тезләндең син,
Кулларыңда иде пар алма.
Төшләремә кереп һәр көн шулай,
Таң атуга китеп югалма.

К у ш ы м т а:

Өзелепләр төште пар алмакай,
Ятимләнеп калды алмагач.
Өзелә бит инде үзәккәем,
Ялгызлыктан дәва булмагач.

Пар алмадай идек, пар алмадай,
Үз күзләрем тиде, күрәсең.
Багалмадай, бигрәк матур булып,
Төшләремә генә керәсең.

К у ш ы м т а.

Җанга ява бары салкын көзләр,
Бар төсләрне җирдә тигезләп.
Төшләремдә күргән пар алманы
Бакчаларда йөрим мин эзләп.

К у ш ы м т а.

## БАЛАЧАГЫМА КАЙТАМ

Хыялымдай атка менеп,
Эх, бер чабасы иде.
Колындай балачагымны
Эзләп табасы иде.

К у ш ы м т а:

Төшләремә керә бары
Җилләрдәй җитез атым.
Муеннарына сарылып,
Сабый чагыма кайттым.

Атлар утлап йөри микән
Ялансу буйларында?
Төннәрен атлар саклыйм мин
Бары тик хыялымда.

К у ш ы м т а.

Колыннар чабып узадыр
Туздырып тузаннарны.
Үтәдер бу гомеркәйләр,
Юксынып узганнарны.

К у ш ы м т а.

## МОҢАЙМАГЫЗ, ШОМЫРТЛАРЫМ

Үткәннәрдән, синең төсең булып,
Истәлеккә калды моң гына.
Без утырткан шомырт агачлары
Чайкалалар җилдә тын гына.

Кушымта:

Моңаймагыз әле, шомыртларым,
Сыгылмагыз сыкрап җилләрдә.
Күтәралмас ачы хәсрәтләрем
Сездән башка сөйлим кемнәргә?

Язлар җиткәч, бер-берсенә сыенып,
Ак чәчәккә күмелә шомыртлар.
Син янымда чакны хәтерләтә
Үзәк өзгеч шушы вакытлар.

Кушымта.

Күзләремдә инде яшь кипкән,
Тик җан гына сыкрап гел елый.
Минем яшем булып, шыбырдап,
Җиргә кипкән шомырт коела.

Кушымта.

# ӘЙТЕР СҮЗЕҢ ӘЙТЕП КАЛ

Агыйделдә ике сал:
Берсе — каен, берсе — тал.

*Татар халык җырыннан*

Агыйделкәй буйларында
Үсә кара карлыган.
Күптән инде күңелем сизә
Әйтер сүзең барлыгын.

Кушымта:

Агыйделдә ике сал:
Берсе — каен, берсе — тал...
Сагынганда үкенерсең —
Әйтер сүзең әйтеп кал.

Кара карлыганнар җыйдым,
Калдырмыйча вакларын.
Бер җылы сүз әйтер идең,
Күңелем китек чакларым.

Кушымта.

Җыйган карлыганнарымны
Ашарга өлгермәдең.
Син дәшмәгәч, мин дә түздем —
Серемне белдермәдем.

Кушымта.

## ЧИШМӘЛӘРДӘ КЕРЛӘР ЧАЙКЫЙМ

Чишмәләрдә керләр чайкыйм,
Ай-һай салкын сулары.
Серем чишсәм, челтер чишмәм
Сагышымны юармы?

К у ш ы м т а:

Көянтәле пар чиләгем
Авыр шул иңнәремә.
Мөлдерәмә күңелемне
Бушатыйм кемгә генә?

Чишмәләрдә керләр чайкыйм,
Кулларым тала инде.
Салкын чишмә суларына
Яшьләрем тама инде.

К у ш ы м т а.

Чишмәләрдә керләр чайкыйм,
Кире кайтырсың кебек.
Кулың туңган, бир җылытыйм,
Диеп әйтерсең кебек.

К у ш ы м т а.

## АРЧАЛАРДА КАЛЫП БУЛМАДЫ

Арчаларга тимер юллар илтә,
Урамнары аның бормалы.
Кайларда сез, урамнарга сыймас,
Гөрләп үткән яшьлек елларым.

Кушымта:

Истә әле Арча урамнары,
Су буена төшкән сукмагы.
Үкенепләр үтә гомерләрем —
Арчаларда калып булмады.

Казансуда кызлар кер чайкамый,
Сулары сай хәзер Арчаның.
Тар басмада тәүге ярым калды,
Аның белән бергә яшь чагым.

Кушымта.

Сабантуйлар җитсә, Арчаларга
Әйләнә дә кайта юлларым.
Урамында мин тик кунак хәзер,
Читтә булгач эчәр суларым.

Кушымта.

## СИН — БАШКАНЫҢ БӘХЕТЕ

Йөрәгемне учларыма
Йомарлап түзәм инде.
Уйларымны күзләремнән
Укыйсың, сизәм инде.

К у ш ы м т а:

Гафу үтенмә, кирәкми,
Син — башканың бәхете,
Кайларда йөрдең адашып,
Соңлаган мәхәббәтем?

Никадәрле күзләреңә
Карамаска тырышам.
Мине түгел, ташны эретер
Бер ялкынлы карашың.

К у ш ы м т а.

Теләсәң, шашкын хисләрне
Туктатып була, имеш.
Булдыралсаң, янмый кара,
Йөрәгеңдә ут килеш.

К у ш ы м т а.

## ТОЛЫМНАРЫМ

Таң нурларын кушып тараганга,
Толымнарым булды микән озын...
Таңда чишмәләрдән су китергән
Авыл кызы бит мин, авыл кызы...

К у ш ы м т а:

Тибрәндереп толымнарым,
Суларга бара идем.
Мин бит туган авылымда
Бәхетле бала идем.

Толымнарым алгач кулларына,
Ап-ак булды кинәт әнкәм йөзе.
«Бәхетләрең киселә күрмәсен», — дип,
Кабат-кабат дога кылды үзе.

К у ш ы м т а.

Толымнарым — әнкәй сандыгында,
Толымнардай сүтелеп, гомер уза.
Бәхеткәйләр эзләп читтә йөргән
Авыл кызы бит мин, авыл кызы...

К у ш ы м т а.

## ЯЛГЫЗ УЧАК

Ямьле язда әллә тугангамы,
Язлар килсә, яшьним, тереләм,
Өметемнең соңгы чаткысыннан
Дөрләп янган учак тергезәм.

Кушымта:

Учагымны читтән күзләп үтә
Күшеккәннәр, ялгыз-ярымнар.
Тик янымда күптән саклап торткан
Сиңа гына дигән урын бар.

Кушымта.

Әллә инде очрашырбыз дигән
Уйларыңнан кире кайттыңмы?
Йә булмаса, ялан кырга чыгып,
Берьялгызың учак яктыңмы?

Кушымта.

Көтә-көтә зар-интизар булсам,
Көтмәм бүтән, үзем барырмын.
Сүнеп барган ялгыз учагыңа
Утлы күмер илтеп салырмын.

Кушымта.

## САРЫ КАШКАРЫЙЛАР

Өзгәләнеп көттем кабат күрешүне,
Килдең менә бүген яңадан.
Бүләк итеп биргән сары чәчәкләрең
Аерылуга диеп юрадым.

К у ш ы м т а:

Кулларыңда сары, сары кашкарыйлар,
Ә мин көткән идем акларын.
Минем дә бит бүген, сары гөлләр кебек,
Сагышлардан сулган чакларым.

Нишләтергә белмим биргән чәчәкләрең,
Йөзләремә яуды сарысы.
Нинди генә дәва табыйм йөрәгемә,
Сулык-сулык кilә ярасы.

К у ш ы м т а.

Өй түремә үзем кашкарыйлар чәчтем,
Кайнарлыгын кушып хисемнең.
Хак сөюем булып, ап-ак чәчәк атсын
Гөлләр белән язган исемең.

К у ш ы м т а.

## АНА ҖЫРЫ

Бәхеткәйләр сагындырып кына
Шакый, диләр, өйнең ишеген.
Белгән догам укып эчтән генә,
Өй түремә элдем бишегең.

Әй балам, багалмам,
Бәхетеңне бирсен бер Аллам.

Кайгы-хәсрәт рөхсәт сорап тормый,
Үтә икән өйнең түренә.
Алларыма алып сине сөйсәм,
Ачы хәсрәтем дә сүрелә.

Тигез канат җылысына сыенып,
Насыйп булса иде яшәргә.
Соң сулышта, башкаеңнан сыйпап,
Риза-бәхил, диеп дәшәргә.

Әй балам, багалмам,
Тәүфыйгыңны бирсен бер Аллам.

## РӘХМӘТ, КАЗАНЫМ

Дәште мине шәһәр шау-шуы,
Төшләремә кергән матурлык,
Гүя тәлгәш-тәлгәш бәхетем
Ераклардан алды чакырып.

Кушымта:

Үз иттең син, рәхмәт, Казаным,
Мин кыюсыз авыл баласын.
Кем уйлаган, шулай яратып,
Гомерлеккә синдә каласым.

Туган нигез биргән канатлар
Синдә ныгып үсте тагын да.
Баштан сөеп гүя юаттың,
Сагынып күңел тулган чагында.

Кушымта.

Синдә таптым сөйгән ярымны,
Дуслар таптым гомер итәрлек.
Заманабыз язган язмышны
Алмаш-тилмәш бергә күтәрдек.

Кушымта.

## МӘХӘББӘТЛЕ БУЛ

Язмыш йөген салып иңнәремә,
Тормыш сикәлтәсен узганда,
Ерак юлдан кайтып керсәм арып,
Җан җылыңны берүк кызганма.

Кушымта:

Синең кулда минем язмышым,
Кичерә күр, булса ялгышым.
Кире какма, мәрхәмәтле бул,
Җан эрерлек мәхәббәтле бул.

Кайчакларда күңел — ирекле кош,
Дөньям онытып йөргән чагымда.
Алда оҗмах дәшеп торса торсын,
Тик бер сукмак илтсен яныңа.

Кушымта.

Күңелдәге бозны эретер өчен,
Бер ягымлы, җылы сүз җитә.
Мәхәббәткә, сүнми янар өчен,
Аз да, күп тә түгел — Без җитә.

Кушымта.

## МИН УЛ, ӘНИ, СИНЕҢ ЯШЬ ЧАГЫҢ

Әниемнең ал күлмәген киеп,
Бөтереләм көзге каршында.
Нинди хатирәләр саклыйсың син?
Сер булмаса, сөйлә барсын да.

Кушымта:

Сабыем, дип, һаман эндәшсәң дә,
Үсте инде нәни кошчыгың.
Гомер уза, диеп уфтанмале,
Мин ул, әни, синең яшь чагың.

Бала итәкле алсу күлмәгеңне
Бәйрәмнәрдә алып киденме?
Талчыбыктай нәзек билләреңә
Ак алъяпкыч бәйләп йөрдеңме?

Кушымта.

Күлмәкләрнең киям затлыларын:
Йә кыскасын, яки озынын.
Тик әнкәмнең алсу күлмәгеннән
Урам әйләнергә кызыгам.

Кушымта.

## КИЛӘ БҮГЕН ЯЛГЫЗ КАЛАСЫМ

Күлмәгемнең кидем яңасын,
Чәчләремне салдым таратып.
Яшь аралаш никтер елмаеп,
Әнкәй калды мине озатып.

К у ш ы м т а:

Әйләндек без кызу бию көенә,
Җем-җем утлар күзен кысып әйләнә.
Кичә тәмам. Дус кызымны
Син озата киттең өенә.

Төсле утлар сүнеп баралар,
Берәм-берәм парлар тарала.
Күз яшьләрем ничек яшерим?
Син борылып берүк карама.

К у ш ы м т а.

Күлмәгемнең кидем карасын.
Килә бүген ялгыз каласым.
Сорауларың калдыр иртәгә,
Минем хәлне, әнкәй, аңласаң.

К у ш ы м т а.

# СИН СӨЮДӘН ЧИБӘР

Сөюемнән мин бер чибәр идем...
*Эльмира+ Шәрифуллина*

Бәхет ачкычлары таптыңмы,
Әллә оҗмах кошы тоттыңмы?
Йә булмаса, әкият егете
Юлларыңа үзе чыктымы?

Кушымта:

Йолдызлар күп, бик күп, санасаң,
Матурлар күп, бик күп, сайласаң...
Син сөюдән чибәр, күз тияр,
Йөзләреңә тутырып карасам.

Тәгәрәсен гомер йомгагың,
Сүтелсеннәр айлар-елларың.
Сөю патша булган илләргә
Алып барсын сине юлларың.

Кушымта.

Юлдаш булып сиңа иң элек,
Янәшәңнән барсын Изгелек.
Йөзләреңә чыккан бәхетең
Була күрсен берүк гомерлек.

Кушымта.

## ТЕЛЕФОН ДӘШМИ

Яшәвем газапка әйләнде,
Ник кенә янымнан җибәрдем.
Үпкәләп киттең дә син миңа,
Юк хәзер бернинди хәбәрең.

Телефон яныннан китмичә,
Сәгатьләр буена утырам.
Бу үле тынлыкка җан керсен,
Йә инде, телефон, шалтыра.

Ничәнче тапкырлар кар күмде
Эземне тәрәзәң төбендә.
Урамда караңгы төн инде,
Утыңны сүндердең бүлмәңдә.

Бәгырең таш булса, син йокла,
Мин төнне уздырам йокысыз.
Иртәгә бүлмәңдә көнозын
Телефон шалтырар туктаусыз.

Телефон дәшми, ул синең яклы.
Кем соң гаепле, кайсыбыз хаклы?

## ЙӨРӘГЕМӘ КАРЫЙ КҮЗЛӘРЕҢ

Болытлы көнемә нур иңде,
Бар дөньям яктырды, күр инде.
Син мине сүзсез дә аңладың –
«Дус булыйк» дидең дә кул бирдең.

К у ш ы м т а:

Йөрәгемә карый күзләрең,
Бигрәк матурлар шул үзләре.
Күз карашыңнан да ягымлырак
«Без бит икәү» дигән сүзләрең.

Иркә син кайчакта аз гына,
Елмайсаң, сирпелә наз гына.
Ягымлы тавышың күңелгә
Әйтерсең җыр булып языла.

К у ш ы м т а.

Мин синең барлыгың белмәдем,
Юлымда очрар дип йөрмәдем.
Бар назын тик сиңа саклаган,
Кайлардан белгәндер йөрәгем?

К у ш ы м т а.

## АДАШТЫК МӘХӘББӘТ ИЛЕНДӘ

Кояшка үреләбар гөлләр,
Җылыга тартыла күңелләр.
Нигәдер юл тапмыйм мин генә
Үтәргә йөрәгең түренә.

Кушымта:

Калдырдың да киттең
Җиде юл чатында.
Эзләп тап син мине,
Яратсаң, дидең дә.
Уңнарда — кыямәт,
Сулларда — хыянәт...
Адаштык Мәхәббәт илендә.

Сынауның авырын калдырдың:
Ялгызым көйдердең, яндырдың.
Кыя таш түгел бит бәгырьләр,
Аңла син: бер генә гомерләр.

Кушымта.

Җиде ай, җиде ел барсам да,
Зилзилә эчендә калсам да,
Кирегә борылып китмәмен —
Табармын күңелең бикләрен.

Кушымта.

## КҮРШЕ ЕГЕТЕ ҖЫРЫ

Кем уйлаган йөрәгемнең
Түренә утәрсең дип,
Җәйге озын төннәремне
Йокысыз итәрсең дип.

К у ш ы м т а:

Күрше кызы, чибәрем,
Син дип тибә йөрәгем.
Күптән күзем төшкән сиңа,
Белми генә йөргәнмен.

Ялантәпи чабып йөргән
Балачак үткән икән.
Дөрли-дөрли, сөюләрдә
Янар чак җиткән икән.

К у ш ы м т а.

Бүген кичен, сине дәшеп,
Тәрәзәң чиртәм әле.
Белми йөрмә сөюемне —
Яшермим, әйтәм әле.

К у ш ы м т а.

## ТЫЛСЫМЛЫ МӘХӘББӘТ

Талпына, әйтерсең күбәләк,
Бу күңел, һай, бигрәк җилбәзәк.
Дөньясы җәннәт күк, болытсыз зәңгәр күк –
Нишләттең син мине, Мәхәббәт.

Кушымта:

Уйладым, уйладым... Сине генә уйладым...
Очратсам да, сине күреп
Туяр кебек булмадым...
Тынычлыгым урладың.

Сүз бирдем үземә кабаттан:
Уйламам, сагынмам, яратмам!
Ни генә итсәм дә, син генә исемдә,
Йокысыз үтә төн, ата таң.

Кушымта.

Җуйдым мин көчне дә, башны да
Тылсымчы Мәхәббәт каршында.
Бар сүзем шул гына: минеке бул гына,
Калганы безнеке барысы да.

Кушымта.

# АЛСУ ГӨЛЕМ

Күңелләрем – ярсу диңгез,
Йөрәк-утрау ятим синсез.
Чәчәк атмый, бөредә гел
Шул утраудa серле бер гөл.

Назлар алсын күзләреңнән,
Җылы алсын сүзләреңнән.
Гомерлек яр булсаң, иркәм,
Шул чәчәкне бүләк итәм.

Бар дөньяны нурга күмеп,
Рәшә сыман, җем-җем көлеп,
Көтмәгәндә, таңда бүген
Чәчкә атты алсу гөлем.

Чит-ят куллар сузылмасын,
Яман күздән ул сулмасын.
Җандай газиз күреп кенә,
Сакла назга төреп кенә –
Сөю гөлем бүләк итәм.

## КОЯШЛЫ ГОМЕР

Алмашынучан болытлы һава:
Йә кояш чыга, йә яңгыр ява.
Чалт аяз көнне яшен суккандай,
Утлы сүзеңнән йөрәгем яна.

К у ш ы м т а:

Кояшлы булыр, диден,
Һәрвакыт тормыш күгең.
Нигә соң, күзге болыттай,
Мөлдерәп тулды күңелем?

Төньяктан исә әче салкын җил,
Бер ярсып куя, бер тына күңел.
Бер-берсен саклап җилдән-яңгырдан,
Парлашып үткән, юк, ул без түгел.

К у ш ы м т а.

Кояшлы яңгыр, яусаң яу чынлап,
Йә күк күкрәтеп, йә бер давыллап.
Үтәлми калган вәгъдәләр кебек,
Торма гел көлеп, җанны яралап.

К у ш ы м т а.

## УНҖИДЕ ЯШЬ

Мәктәп юлларында танышып,
Сөю тулы хатлар алышып,
Балачактан бик тиз киттек без,
Сиздерми дә үсеп җиттек без.

Кушымта:

Унҗиде! Тик унҗиде яшь.
Яшь әле, без әле бик яшь.
Мең төрле тормыш юллары —
Сөю илләренә мине дәш.

Канатлана күңел, ашкына,
Җанга сыймый хисләр ташкыны.
Безгә яшьлек үзе гашыйк бит,
Зур булырга әйдә ашыкмыйк.

Кушымта.

Дөрләп янсын сөю-учаклар,
Кире кайтмас безнең бу чаклар.
Бик көнләүләр бездән көнлидер,
Тик яшәрү серен белмидер.

Кушымта.

## ӘЙДӘ, КИТИК ЕРАК-ЕРАККА...

Борчу-хәсрәт өскә өелә,
Мәшәкатьләр тула өемә.
Дөнья гизүләре рәхәттер,
Кайда без юк, шунда — бәхеттер.

К у ш ы м т а:

Кайгыларны онытырга телим,
Җитәкләшеп икәү — син дә мин —
Китик әйдә ерак-еракка —
Беркем аяк басмаган якка.

Җитәр, диеп, болай яшәргә,
Чыгып китик ерак сәфәргә.
Бер сәгатькә, айга, бер елга,
Буйсыныйк та юләр хыялга.

К у ш ы м т а.

Күрәчәкне урап узарбыз,
Гүзәл утрау эзләп табарбыз.
Бәлки, вакыт арттан җиталмас,
Бәлки, язмыш куып тоталмас.

К у ш ы м т а.

## ӘНИЕМНЕҢ ТУГАН КӨНЕ

Шатлыкларың торган онытылып,
Борчуларың булган җитәрлек,
Шуңа бәйрәмнәрең җибәргәнсең
Тыйнак кына итеп үткәреп.

К у ш ы м т а:

Әниемнең туган көне бүген.
Ярар инде, әни, елама.
Онытмадым, ничек итеп онытыйм,
Йә, бер елмай, авыр сулама.

Каушап калган нурлы йөзләреңә
Ак яулыгың бигрәк килешә.
Борчылмале, син һәрвакыт матур –
Гади күлмәк кигән килеш тә.

К у ш ы м т а.

Күңелләргә сыймый шатлыгыбыз,
Синең бәхет зуррак аннан да.
Җаныбызга җылы кояш булып,
Яшә, әни, шулай һаман да.

К у ш ы м т а.

## СИН — МАТУР ҖЫРЫМ

Сиңа багышлап шигырьләр яздым,
Сиңа атап җырлар җырладым,
Сиңа тәүге кат «яратам» дидем —
Син бит бәхетем идең.

К у ш ы м т а:

Төшемдә, өнемдә —
Күңелемнең түрендә,
Иң матур җыр булып
Яшисең син бүген дә.

Безгә тидеме ятларның күзе,
Безгә язмыш шулай язганмы,
Безгә насыйп яр хәзер бүтәннәр —
Тик онытылмый үткәннәр.

К у ш ы м т а.

Сиңа багышлап шигырьләр язам,
Сиңа атап җырлар җырлыйм мин,
Сиңа җырымда «яратам» диям —
Сине җырымда сөям.

К у ш ы м т а.

## БЕЗНЕҢ СӨЮ

Кемне назлый бүген татлы сүзең,
Кемгә сөеп карый шаян күзең,
Кайнар иреннәрең төннәреңдә
Гөлләр тезә кемнең йөзләренә?

Кушымта:

Бик бәхетле кебек яшәсәң дә,
Хәбәр биргәч, каршы дәшмәсәң дә,
«Оныттым» дип әйтү генә җиңел –
Безнең сөю онытырлык түгел.

Берни әйтми сиңа минем исем,
Минем барлыгымны син белмисең.
Син идеңме, әллә түгел микән? –
Миңа алтын таулар вәгъдә иткән.

Кушымта.

Мин яратам сине, урлап кына,
Яшерен янып, яшерен уйлап кына.
Көнләшмәсен әйдә сөймәгәннәр,
Җирдә Сөю барын белмәгәннәр.

Кушымта.

## НИ БУЛДЫ СИҢА?

Куйныңда йөрткән агулы хәнҗәрне
Бәгырьгә кадап киттең...
Синең күңелең бушап калгандыр,
Мине хәсрәтле иттең.

Кушымта:

Ни булды сиңа, ни булды –
Аңлатып бирсәң иде.
Сулкылдап елый йөрәгем –
Үтәли күрсәң иде.

Син мине, алай сабыр дигәч тә,
Сынама утка салып.
Сабырның соңгы кыллары сынар,
Сагыш утында калып.

Кушымта.

Туры сүз, анысы, яра ташны да,
Тик дәшми калу – алтын.
Көенер чакта сөелер мәлләрне
Тоттың да утка яктың.

Кушымта.

## ҖАВАПСЫЗ СӨЮ

Мин яраттым сине. Сөюемне
Дулкын итеп тездем суларга.
Диңгез миңа тозлы яшьләр бирде,
Сине сагынганда еларга.

Мин яраттым сине. Сөюемне,
Канат куеп, күккә күтәрдем.
Җаннарыма койды бозлы яңгыр,
Төннәремне ялгыз үткәрдем.

Мин яраттым сине. Сөюемне
Кабул итеп кенә алмадың.
Дәрьялардай ташкан хисләремне
Бер шаяру диеп аңладың.

Күк күкрәсен, яшен яшьнәсен!
Тик «яратмыйм» диеп дәшмә син.
Ятим сөю минем йөрәгемдә
Бер җылы сүз көтеп яшәсен.

## ӘТКӘЙ-ӘНКӘЙ — ПАР КАНАТЫМ

Язмыш йөген салып иңнәремә,
Үткән чакта тормыш юлларын,
Җан сөенә, җиңеләя адым,
Белеп янәшәдә сез барын.

Кушымта:

Әткәй-әнкәй — минем пар канатым,
Сез булганга, дөньям түгәрәк.
Иңне — иңгә, җанны җанга куеп
Яшик әле, яшик бергәләп.

Акыллы сүз, алтын киңәш белән
Авыр чакта ярдәм итәсез.
Адашканда, ак юл күрсәтүче
Күңел күзе ул — сез икәнсез.

Кушымта.

Сезгә саулык телим һәр догамда,
Тигез бәхет телим һәрвакыт.
Мең рәхмәтләр әйтеп чын йөрәктән,
Карыйм сезгә сөеп, яратып.

Кушымта.

## ҖАН ДУСЛАРЫМА

Якын дуслар булу аз димә,
Җан дуслар ул — үзе хәзинә.
Дөньяларның малы — бер көнлек,
Саклап тотсаң, дуслык — гомерлек.

Кушымта:

Яшерен серләремне чишәргә,
Кайгы килсә, уртак итәргә,
Үпкәләшер өчен, яратып,
Җан дусларым кирәк һәрвакыт.

Чит илләрдән алып кайтылмый,
Бизмәннәрдә үлчәп сатылмый.
Чын дуслыкның хакы югары —
Озын-озак гомер юллары.

Кушымта.

Якын дуслар — ярты бәхет ул,
Дуслар өе — алтын тәхет ул.
Якын булсын ерак юлыбыз,
Уртак булсын һәрчак җырыбыз.

Кушымта.

## ЯШЬЛЕГЕМӘ КИРЕ КАЙТАЛМЫЙМ

Дугаларга чиккән сөлге бәйләп,
Моңлы кыңгыраулар чыңлатып,
«Авыл көе»н җырлап чыгып киттем,
Унсигезем калды озатып.

К у ш ы м т а:

«Туп-туп» иткән тояк тавышымы,
Йөрәк тибешеме — әйталмыйм...
Талпынса да күңел, ашкынса да,
Яшьлегемә кире кайталмыйм.

Йөгән кидерелгән ярсу җанны
Җибәрәсе иде тугарып.
Ат саклаган төнге болыннарга
Килдем, ахры, шактый соңарып.

К у ш ы м т а.

Гармунымны алып җырлап карыйм,
Моң да башка, көй дә ят бүген.
Алмачуарымның күзләредәй,
Күңел мөлдерәмә чак бүген.

К у ш ы м т а.

## АШЫТБАШ КЫЗЛАРЫ

Авылыма алып кайта
Мине урман юллары.
Җырлый-җырлый җиләк җыя
Ашытбашның кызлары.
Әй сез, кызлар, очкын күзләр,
Ашытбаш бизәге лә.
Печән чапкан егетләрнең
Күзләре сездә генә.

Шифа булып җанга ята
Чәчәк исе, бал исе.
Челтер-челтер кызлар көлә,
Ямьләп авылым кичен.
Әй сез, кызлар, очкын күзләр,
Ашытбаш бизәге лә.
Гармун тарткан егетләрнең
Күңеле сездә генә.

Ямь өстенә ямьнәр өстәп,
Туйлар узар көзләрен.
Чит-ятларга бирмәбез без
Ашытбашның кызларын.
Әй сез, кызлар, очкын күзләр,
Ашытбаш бизәге лә.
Тирә-як егетләренең
Өмете сездә генә.

## МИНЕ ЮГАЛТЫРГА АШЫКМА

Чишен әйдә, сал өстеңне
Ун минутка булса да,
Кырык эшең кырык якка
Кырылырга торса да.

Кушымта:

Дусмы соң без, юкмы?
Үпкәләшер чакмы?
Мине югалтырга
Ашыкма шулчаклы.

Кермә тик узып барышлый,
Кил минем янга атап;
Өзелеп сагынган чагыңда,
Бар мәшәкатең ташлап.

Кушымта.

Күрсәтмә күз яшьләреңне,
Елап килсәң, дәшмим дә.
Син минеке булсаң әгәр,
Таммас бөртек яшең дә.

Кушымта.

## МИНЕМ АРТТАН ЙӨРМӘ, ХЫЯНӘТ

Әсир итә очкын күзләрең,
Таң калдыра ялкын сүзләрең.
Җуяр идем, бәлки, акылым —
Йөрәгең таш синең, матурым.

К у ш ы м т а:

Куеныма кереп елышма,
Ышандырам диеп тырышма.
Йөрәгемдә яши Мәхәббәт,
Минем арттан йөрмә, хыянәт.

Мәхәббәтнең туган көнендә
Чакырылмаган кунак син генә,
Түбән булма инде шулчаклы —
Оныт минем янга сукмакны.

К у ш ы м т а.

Серле йозак белән бикләрмен,
Чит берәүне җанга кертмәмен.
Юлларыңа синең ак җәймә —
Үз тиңеңне эзләп тап әйдә.

К у ш ы м т а.

## ЯЛГЫШМА

Парын эзләп очкан ак күгәрчен
Ялгышкандыр юлын, күрәсең.
Ул үзе дә белгәндерме-юкмы
Учларыңа очып керәсен.

К у ш ы м т а:

Тик адашып килгән бәхетеңне
Күрмәмешкә юри салышма!
Бер табылгач, инде югалмас дип
Ялгышма син берүк, ялгышма.

Очрашуны көтеп көннәр озын,
Сөю-назлау көтеп төнозын.
Җаны белән күккә омтылса да,
Ул калдырып китми ялгызың.

К у ш ы м т а.

Дөньяларың онытып ни уйлыйсың,
Төннәреңдә нигә елыйсың?
Тиңен эзләп очкан кошчыгыңның
Учларыңа кысып җылысын.

К у ш ы м т а.

## САҖИДӘКӘЙ

Саҗидәкәй! Моңлы карашыңда –
Үпкәләү дә, тирән сагыш та.
Чәчәк кебек чакта тол калгансың,
Елый-елый рәнҗеп язмышка.

К у ш ы м т а:

Газизеңнең якты эзе яши
Кыз-улларың йөргән һәр җирдә.
Йөз аклыгың алар, йөз шатлыгың,
Син бит ялгыз түгел, Саҗидә.

Кага-суга тормыш елатканда,
Кайдан алдың көч һәм сабырлык?!
Синең кебек сабыр әнкәйләргә
Алтыннардан һәйкәл салырлык.

К у ш ы м т а.

Синең сөю – бер һәм гомерлеккә,
Еллар уза – сүнәм дими ул.
Дөньялыктан мәңгелеккә күчәр,
Чын мәхәббәт ике килми шул.

К у ш ы м т а.

## ЯШЕРЕН ЧИШМӘМ

Челтер-челтер көлеп, терекөмеш кебек,
Учларымнан качма йөгереп,
Сине, яшерен чишмәм, мин озак эзләдем,
Бер йотым назыңа тилмереп.

К у ш ы м т а:

Ярсый йөрәк, дөрли йөрәк.
Янган йөрәгемә ни кирәк?
Янып, көлгә калмас өчен,
Яшерен чишмәм, миңа син кирәк.

Әйтмәсәң дә беләм: синдә дә бар сагыш,
Үзәкләрне өзә тавышың.
Җырыбыз бер икән, моңыбыз бер икән,
Булмаса да гәрчә кавышып.

К у ш ы м т а.

Сусаудан чатнаган иренемә бер тамгач,
Килмә бүтән, диеп озатма.
Татыйм бәхетемне тамчы-тамчы гына,
Җитсен диеп озак-озакка.

К у ш ы м т а.

## ЯЗМЫШЫМ МИНЕМ — АРЧАМ

Алтын куллы балалары
Йөрәк җылысын биргәч,
Безнең Арча гөлбакчадай
Яшәрә язлар килгәч.

Данлы Арча, яңа Арча —
Халкымның йөз аклыгы.
Сабантуйлар булып гөрли
Тыныч хезмәт шатлыгы.

Аз булмады гомеркәйнең
Ут уйнаткан чаклары;
Сынауларның, баш идереп,
Бер елаткан чаклары.

Яшәвемә көч өстәүче
Сулышым минем — Арчам.
Туган ягым, горурлыгым,
Язмышым минем — Арчам.

## ӨЧ ПОШАЛЫМ — ӨЧ ИГЕЗӘК

«Поши аулыйм» дигән сүздән
Исем алган Пошалым.
Түбән, Урта, Югарысы —
Өчесе бик дус аның.
Яши шулай гомер буе
Өч Пошалым бер булып.
Дуслык буыннан буынга
Күчсен гүзәл җыр булып.

Кушымта:

Эх, Пошалым чанасы ла,
Җәйләр җитсә — арбасы.
Җырлап үтсәң, сизелми дә
Өч Пошалым арасы.

Пошалымның осталары
Кулында ут уйната.
Бездәге таң әтәчләрен
Пычкы җыры уята.
Сүзгә тапкыр, эшкә маһир —
Заманча яшьләр бездә.
Безнең якка кияүгә чык,
Безнең яктан кыз күзлә.

Кушымта:

Эх, Пошалым чанасы ла,
Җәйләр җитсә — арбасы.
Җырлап үтсәң, сизелми дә
Өч Пошалым арасы.

Тимерша аланына кил,
Балланып җиләк пешкәч.
Тәннәреңә сихәт керер,
Сул(ы) аланда су эчкәч.
Көз чагыла, Карлыярда
Ак кар яткан чагында.
Өч Пошалым — өч игезәк
Туган җир кочагында.

К у ш ы м т а:

Эх, Пошалым чанасы ла,
Җәйләр җитсә — арбасы.
Җырлап үтсәң, сизелми дә
Өч Пошалым арасы.

## СОЛДАТ ЕГЕТКӘ

Туган яктан, туган җирләрдән
Солдат егет көтә гел хәбәр.
Сөйгән кызы язган соңгы хат
Ник кадерле икән шулкадәр?!

К у ш ы м т а:

Көннәр-төннәр имин үтсен,
Әйбәт кенә хезмәт ит син,
Дусларыңа бездән сәлам әйт.
Сагынам сине, солдат егет,
Бер көн миңа бер ел кебек,
Исән йөреп, тизрәк өйгә кайт.

Газиз әткәң, сагынып бөркетен,
Күз яшьләрен сөртә яшереп.
Газиз әнкәң, улым кайтыр, дип
Көтә тәмле ашлар пешереп.

К у ш ы м т а.

Берәүгә дә әйтмә серемне,
Сөйгәнеңнән сиңа бар бүләк:
Уртак вәгъдәбезнең билгесе –
Туебызга тегәм ак күлмәк.

К у ш ы м т а.

## ИҢ МАТУР БӘЙРӘМЕҢӘ

Бүләк булып барсын җырым
Иң матур бәйрәмеңә.
Ак теләкләр кушып бирәм
Ак гөлләр бәйләменә.

К у ш ы м т а:

Син миңа һәрвакыт кирәк,
Син янда чакта рәхәт.
Бу дөньяга туган өчен,
Булганың өчен рәхмәт.

Тормыш гүзәл, яшәү — бәхет,
Белсәң генә кадерен.
Югалтма бәхет-шатлыкның
Сиңа килгән кадәрен.

К у ш ы м т а.

Башлаган һәр яңа эшең
Син теләгәнчә барсын.
Гомереңнең һәрбер көне
Туган көн кебек булсын.

К у ш ы м т а.

## ХУШ КИЛДЕҢ, ЯҢА ЕЛ!

Йөрәкне җилкетеп, хисләрне уйнатып,
Өр-яңа ел килә илемә-җиремә.
Утларын яктыртып, йолдызлар балкытып
Чакыра ул безне балачак иленә.
Яңа ел – могҗиза,
Яңа ел ул – тылсым.
Яшәсен елмаю,
Күз яше онытылсын!

Әкият дөньясы сихерли күңелне.
Без – аның кунагы, без – аның патшасы.
Теләкләр ак булса, ниятләр саф булса,
Беләбез хыялның тормышка ашасын.
Яңа ел – могҗиза,
Яңа ел ул – тылсым.
Яшәсен изгелек,
Өметләр аклансын!

Тугрылык һәм бәхет атлыйлар янәшә,
Дөньяны яшәтә мәңгелек мәхәббәт.
Хуш килдең, Яңа ел, рәхим ит, түрдән уз!
Хуш инде, Иске ел, барысына мең рәхмәт!
Яңа ел – могҗиза,
Яңа ел ул – тылсым.
Яшәсен мәхәббәт,
Бәхетләр мул булсын!

## МИН МОНДА ЮК

Әллә күкләрдә кояш, әллә күкрәктә кояш?
Йөрәкнең дөрләп янган мәле...
Таныш йөзләр ят кебек, күңел тулпар ат кебек –
Шулдыр, күрәсең, сөю хәле.

Сорау бирмәгез. «Ниләр булды?» димәгез,
Хыялый дип көлмәгез, кадап җанга ук.
Мин бик ерак:
Җиде таулар артында,
Җиде диңгез артында.
Мин бит монда юк. Юк!

Анда ал гөлләр үсә, балдай хөрмәләр пешә,
Былбыллар иңгә кунып сайрый.
Иркә боландай ярым, үземә насыйп парым
Бишек үрергә гөлләр сайлый.

Сорау бирмәгез. «Кайда соң син?» димәгез.
Хыялый дип көлмәгез, кадап җанга ук.
Мин бик ерак:
Серле сөю илендә,
Йөзәм бәхет күлендә.
Мин бит монда юк. Юк!

## ҮКЕНМИМ

Назлы итеп карама син, карама,
Берни дә юк хәзер безнең арада.
«Онытыйк» дип, бәгърем, үткәннәрне,
Кагылма син түзәлмәгән ярага.

К у ш ы м т а:

Юк, үкенмим, мин барыбер үкенмим,
«Оныттыр» дип, синнән үтенмим.
Син — мәңгелек ярым,
Син — мәңгелек ярам…
Онытырга сине мөмкинме соң?

Үз кулларым белән бирдем ятларга,
Күз алалмыйм син яшәгән яклардан.
Сер бирмәскә, бәгърем, теләсәм дә,
Мин ваз кичмим  син янымда чаклардан.

К у ш ы м т а.

Назлы итеп карама син, карама,
Кагылма син түзәлмәгән ярага.
Кайтып булса, бәгърем, үткәннәргә,
Җил дә кермәс иде безнең арага.

К у ш ы м т а.

## СИН — МӘХӘББӘТНЕҢ ҮЗЕ

Син — мәхәббәтнең үзе,
Син — кичермәгән хисем.
Дөньяда иң матур сүз —
Син йөрткән нурлы исем.

К у ш ы м т а:

Энҗе ташлар белән бизәп,
Таҗ кидермим истәлеккә.
Исемеңне йөрәгемә
Язып куйдым гомерлеккә.

Син — ачылмаган гөлем,
Син — татымаган назым,
Көттереп, сагындырып,
Яшьлектән килгән язым.

К у ш ы м т а.

Син — тыңланмаган көем,
Мин — ятланмаган шигырь...
Без — гүзәл бер җыр булып
Кушылган ике гомер.

К у ш ы м т а.

## СӘБӘПЛӘРЕН СОРА ЙӨРӘКТӘН

Ни сәбәпле мине яратасың, дип
Сорама син, кабат сорама.
Сине гашыйк иткән сәбәпләр эзләп,
Йөзләремә сынап карама.

К у ш ы м т а:

Яратам мин сине, бары яратам,
Җаннарыма якын күргәнгә.
Яшерен серләремне ачам ышанып,
Синең яратканны белгәнгә.

Серләреңне сорап торасы да юк,
Укып була, дисең, күзеңнән.
Энҗеләре тирән, ә күзләремдә
Чайпалганы гына күңелдән.

К у ш ы м т а.

Буйсынмыйча миңа, ихлас хисләрем
Җырлар булып чыга күкрәктән.
Йөрәгем бит сине, сине сайлады,
Сәбәпләрен сора йөрәктән.

К у ш ы м т а.

## ТИК СИН КИРӘК

Әйлән-бәйлән уйный гүя дөнья,
Тормыш бит ул тоташ бәйрәм түгел.
Шатлыкта да, авыр вакытта да
Тигез сөю өмет итә күңел.

К у ш ы м т а:

Очар канат куя шатлык хисем,
Сөюемнән алам яшәү көчен.
Рәхмәт сиңа, рәхмәт, газиз кешем,
Минем бәхетемә туган өчен.

Ерак араларны якын итеп,
Кара төнне көнгә авыштырып,
Йөрәгемне бәйләп йөрәгеңә,
Сөю яши безне кавыштырып.

К у ш ы м т а.

Җан сулышын әйдә уртак итик,
Бер-беребез өчен булыйк терәк.
Яшьлектә дә, гомер көземдә дә
Тик син кирәк миңа, тик син кирәк.

К у ш ы м т а.

## «ЯРАТАМ» ДИП ӘЙТСӘҢ, НИ БУЛА?

Кыяга сыенып, моңсуланып үскән
Ялгыз гөлдәй тоям үземне.
Җил-яңгырдан саклап, яшәсәң дә яклап,
Кызганасың назлы сүзеңне.

Кушымта:

Уттай челләләрдә, сусаудан тилмереп,
Чәчәк аткан гөлләр тиз сула...
Янган йөрәгемнең ярсуларын басып,
«Яратам» дип әйтсәң, ни була?

Күңелемдә — рәшә, җанымда — аҗаган,
Күрмисең шул, берни күрмисең.
Назың көтеп яшим, кочагыңда өшим —
Нигә бер уч җылы бирмисең?

Кушымта.

Бер елыйм, бер көләм; бер янам, бер сүнәм,
Кабынам да янә сүреләм...
Сөю тулы назлы карашыңны күреп,
Өметләнеп кабат тереләм.

Кушымта.

## ӘЛЕ СИН ДӘ СӨЯРСЕҢ

Уйнап кына билләремә
Кулың салмаска иде.
Күзләремә карап алдап,
Серем алмаска иде.
Яратам дип мине алдап,
Серем алмаска иде.

Китәсең икән, әйдә, кит,
Ак теләк юлларыңа.
Сагышымны илтеп салам
Каракүл суларына.
Сөюемне илтеп салам
Каракүл суларына.

Минем кебек башың җуеп,
Әле син дә сөярсең.
Аерылу газапларына
Ничек түзгән диярсең.
Гыйшык хәле бигрәк яман,
Нихәл түзгән диярсең.

## ҖАНЫМА НИДЕР ҖИТМИ

Очрашу өчен чакыру көтәсең,
«Кит» дию белән, борылып китәсең.
Йөрәгем давыл теләгән чакта,
Тынычланырга киңәш итәсең.

Кушымта:

Юк!
Биргән суларың сусауны басмый!
Шаян сүзләрең күңелемне ачмый!
«Бәгырем» диюең бәгырьгә үтми,
Җаныма нидер җитми.

Язмышым миңа матур фал ача,
Күңел канатым күкләрне коча.
«Сабыр була бел, тукта», — дисең дә,
Бар хыялларым җилләргә оча.

Кушымта.

«Мин сөям икән — гомергә», — дисең,
Һаман сөйлисең, тыңлыйм димисең.
Бәлки, ярата беләсеңдер дә,
Тик яраттыра гына белмисең.

Кушымта.

## БЕРДӘНБЕРЕМӘ

Нигә юкка шикләнәсең,
Нигә юкка сыныйсың?
Ятларга яр булырсың, дип,
Ник аерылу юрыйсың?

К у ш ы м т а:

Синеке мин, тик синеке!
Күрмисеңмени үзең?
Газаплама, газапланма –
Оныт «хыянәт» сүзен.

Ышанырлык та түгел шул,
Артык кайнар хисләрем.
Сөюемнән йөрәгемә
Утлар капса нишләрмен?

К у ш ы м т а.

Үзең дә, бердәнберем, дип
Әйтче, күземә карап.
Ятка күз салмаслык итеп,
Миннән дә ныграк ярат!

К у ш ы м т а.

# ШАЛТЫ ҖЫРЫ

Шалты суы ерак китә,
Челтери тавышлары.
Аккан сулар кебек серле
Кешенең язмышлары.

К у ш ы м т а:

Яшь гомерләр дә узган ич, —
Шунысы бигрәк кызганыч.
Шалты буен бер әйләнсәм,
Йөрәгемә юаныч.

Мүкле чишмә буйларының
Картайган шул таллары.
Сөзәкләнгән Күчемтауның
Чана шуган таулары.

К у ш ы м т а.

Әйләнәм дә килеп чыгам
Түгәрәк урманнарга.
Өч чакрым арамыни
Күңеле тулганнарга.

К у ш ы м т а.

## БЕР ОЧРАШУ

Уй җитмәслек бөек хыял идең,
Буй җитмәслек биек кыя идең, —
Сөю тулы кайнар сүзләр белән,
Тезләндең дә кочтың тезләремнән.

К у ш ы м т а:

Бу очрашу тәүге мәртәбә,
Бу очрашу соңгы мәртәбә.
Син минеке бүген, тик минеке...
Үкенүләр калсын иртәгә.

Минем сөюемне белмәс идең,
Чакырмасам, мәңге килмәс идең.
Инде кабат дәшүемне көтмә,
Хәбәр көтмә, вакыт әрәм итмә.

К у ш ы м т а.

Ни булса да, һичбер үкенмимен,
Кабат кил дип, синнән үтенмимен.
Кичер, миңа синнән сөю кирәк,
Тибә миндә сөю тулы йөрәк.

К у ш ы м т а:

Бу очрашу тәүге мәртәбә.
Бу очрашу соңгы мәртәбә.
Бу кавышу түгел, бу — хушлашу,
Үкенүләр калсын иртәгә.

## БЕРДӘНБЕРЕМ БУЛМАДЫҢ

Карап калдым киткән юлларыңа,
Син, борылып, кулың болгадың.
Булдың минем парым,назлы ярым,
Бердәнберем генә булмадың.

Кушымта:

Гел адашып йөрим шул язларда,
Әллә дәштең җәйгә, әллә юк.
Кояш сүнде җанда, күңелем боек,
Әллә яшим җирдә, әллә юк.

Китүеңнең эзлим сәбәпләрен,
Тик шул гына: артык яраттым.
Синең сөймәгәнне белсәм беркөн,
Мин үләрмен диеп шаярттым.

Кушымта.

Җәйләре дә үтәр. Килер көз дә,
Кышларның да була төрлесе...
Язын чәчәк атмый өзелеп төште
Сөю дигән гөлнең бөресе.

Кушымта.

## ЯҢА ГАСЫР ДӘШӘ

Йөрәкләргә, дөрләп, утлар кабыныр күк,
Бигрәк кайнар заман сулышы.
Уңай ниятләргә, изге гамәлләргә
Хәер-фатихада илбашы.

К у ш ы м т а:

Хәерле иртә, газиз халкым, сиңа!
Зур эшләргә чакырып, Ил дәшә.
Исән-имин көннәр, якты уйлар теләп,
Яңа гасыр безгә эндәшә.

Ил-көннәрдә нинди яңа хәбәрләр бар,
Милләттәшем, күңелең ни даулый?
Җиргә туа сабый, җанда иҗат кайный, —
Яшәү эфирларга сыялмый.

К у ш ы м т а.

Изге табигатьнең балалары бит без,
Кем булсак та, кайда торсак та.
Үзебез булып калыйк,
Гүзәл эшләр кылыйк —
Тормыш гөрләп барыр шул чакта.

К у ш ы м т а.

## ӘТНӘ

Алтын куллы тырыш егетләрең,
Әтнәм, сине гөлләр иткәннәр.
Үкенсеннәр әйдә, үкенсеннәр
Туган ягын ташлап киткәннәр.

Кушымта:

Яңа туган айдай балкып,
Тора Әтнә үзенә тартып.
Исемеңне, Әтнәм, күңелемдә йөртәм,
Әткәм-әнкәм белән беррәттән.

Уттай өлгер апа-җиңгиләрең
Шәл бәйлиләр бала чагыннан.
Читтән килеп, кияү егетләре
Кәләш эзли Әтнә ягыннан.

Кушымта.

Гөрләп торган данлы калаларда
Күп күрсәм дә дөнья рәхәтен,
Әтнә ягы – ямьле Ашыт буе,
Синдә таптым яшәү бәхетен.

Кушымта.

## ЫШАНДЫР

Аның эзе калган сукмаклардан
Дәшмә мине сөю иленә;
Алып кермә аны коендырган,
Шашындырган бәхет күленә.

К у ш ы м т а:

Дәш син мине бүтән бер дөньяга —
Дәш ихластан, чакыр алдаусыз,
Һәм ышандыр яшәп булганлыкка
Хыянәтсез, һичбер ялгансыз...

Чатнап ярылса да иреннәрем,
Ул татыган назны теләмим...
Мин бит башка, сөям үземчәрәк —
Тик барыбер аннан көнләмим!

К у ш ы м т а.

Телисеңме? Оныттырам аны?
Җырга төрәм моңлы җаныңны?
Бәхеткәйнең ал нурына манам
Күтеп алган һәрбер таңыңны?

К у ш ы м т а.

## КӨТӘМ

Сагынсам да, яннарыңа
Юри соңарып барам.
Һәр сүз саен, сине үртәп,
Һаман кабатлап торам:
«Мин китәм инде, китәм,
Кайтырга вакыт җиткән».
Ә үзем «Бераз тор инде,
Китмә» дигәнне көтәм.

Янәсе, мин бик еш килеп
Йөрүеңне яратмыйм.
Үз-үземә каршы чыгып,
Гел бер сүзне кабатлыйм:
«Син килмә көн дә, килмә,
Вакыт уздырып йөрмә».
Ә йөрәк сүзсез ялвара:
«Берүк ышана күрмә».

Бүген минә килми калдың,
Мине утларга салдың.
«Килмә» дигән шул сүземне
Башка әйтмәслек булдым.
Мин көтәм сине, көтәм.
Нигә килмәдең икән?
Синең белән очрашмаган
Бер көн — бер гомер, иркәм.

## КЫРГЫЙ ГӨЛ

Дус кызларым кичләр буе биләмдә йөри,
Чибәр-чибәр егетләргә тынгылык бирми.
Ә мин менә дәшсәләр дә чыкмыйм урамга,
Күңелемне бәйдә тотар сәбәп булганга.

К у ш ы м т а:

Җырчы кошым-сандугачым,
Мин синнән качам.
Чәнечкеле кыргый гөлең
Күрерсең кайчан?

Гитараңны кочагыңа алып уйныйсың,
Сөям, диеп җырлаганда, кемне уйлыйсың?
Үзең кызлар озатмыйсың, ялгыз йөрисең,
Берәү син дип өзгәләнә, шуны күрмисең!

К у ш ы м т а.

Үзем теккән аллы-гөлле күлмәгем кидем,
Түзалмадым, бүген кичке уенга килдем.
Күз дә салма, бер сүз дәшмә, хыялый егет,
Мин, белеп тор, чәнечкеле кыргый гөл кебек.

К у ш ы м т а.

## ТҮНТӘР

Борма-борма Түнтәр юлы
Еракка алып китә.
Читләргә чыгып киткәннәр
Моңланып гомер итә.

Кушымта:

Хәтерем сукмакларыннан
Үткәннәремә кайттым.
Сагышларыма дәваны,
Сагынуларыма дәваны,
Түнтәрем, синдә таптым.

Тау асты чишмәләренең
Суын эчеп туймадым.
Сандугач моңнарын тыңлап,
Корт бакчасын буйладым.

Кушымта.

Яшь урманның аланнары —
Җиләкле хәтфә келәм.
Бер җырлап утырыйк әле
Яшьлек дусларым белән.

Кушымта.

## СИҢА ЧИТТӘН ТАБЫНАМ

Күзләремә карап торды,
Бәхетне танымадым.
Елый-елый китеп бардың,
«Кал» диеп ялынмадым.

К у ш ы м т а:

Учларымда учың булган
Вакытларны сагынам.
Ялгышларыма җәза шул:
Сиңа читтән табынам.

Очраганда елмаясың,
Берни булмаган кебек.
Хәлләремне сорашасың,
Әллә чын, әллә көлеп.

К у ш ы м т а.

«Бәхетлеме» дип сорамыйм,
Әйтеп тора күзләрең.
Кайгы синнән ерак йөрсен,
Мин ничек тә түзәрмен.

К у ш ы м т а.

## ТУГАН АВЫЛЫМ — ӘХМӘТЕМ

Әлки якларына килсәң,
Әхмәт авылына кер.
Безнең чишмә суларыннан
Сихәт ал җаныңа бер,
Киң күңелле, якты йөзле
Кунакчыл халкымны күр.

Сүзгә тапкыр, эшкә батыр
Әхмәтнең егетләре.
Кызларның бездә сылуы —
Зифа тал кебекләре.

Чирмешән буенда йөрим,
Тургай көйләрен урыйм.
Озын күперне үтәм дә
Әлҗән аланын буйлыйм.
Җилгә иркен сахраларны
Сөеп-яратып туймыйм.

Су буе урамын җырлап
Бер әйләник, әйдәле,
Яшьлек хисләрен яңарта
Әхмәт авылы бәйрәме.

Аккош күле түм-түгәрәк,
Тирбәлә талгын гына,
Сандугач сайрый өздереп,
Алмачак таллыгында.

Уйларга чумып тын калган
Комсыз кырлары гына.

Бары газиз туфрагымда
Тулы минем бәхетем.
Яшәвемә ямь өстисең
Туган авылым — Әхмәтем.

# СОҢГЫ ХАТ

Син хат итеп язам дидең, әни,
Безгә әйтер соңгы сүзеңне.
Күңелләрең алдан сизгән кебек,
Гомер дисбең кинәт өзелде.

К у ш ы м т а:

Әманәтең, әни, табылмады,
Мәңгелек сер булып югалды.
Әйтелмәгән васыятьләрең гүя
Күкләр хәтеренә юл алды.

Бергә чакта аңлап бетермәдек
Әни назларының кадерен.
Синең янда кичергәнбез икән
Садә мизгелләрен гомернең.

К у ш ы м т а.

Мәрхәмәтсез язмыш укларына
Калкан иттең сабыр йөрәгең.
Бүген безне саклап-яклап яши
Соң сулышта әйткән теләгең.

К у ш ы м т а.

# ГОМЕР ФАСЫЛЛАРЫ

Шагыйрә Сания Юныс кызы Әхмәтҗанова 1962 елның 20 апрелендә Татарстанның Арча районы Курса Почмак авылында туа. Әнисе Рәхимә апа балачакта укытучы булырга хыяллана, ләкин биш яшеннән аннан өлкәнрәк сигез бертуганы белән әтисез калуы, яшьлегенең михнәтле сугыш елларына туры килүе бик күп яшьтәше кебек үк аны да тормыш арбасына җигелергә мәҗбүр итә. Унҗиде яшьлек Рәхимә, шул елларда артельдә эшләп, хәрбиләрнең кием-салымнарын төзәтү-ямау, яңаларын тегүдә катнаша һәм тегүче һөнәрен үзләштерә. Сания, әнисенә охшап, кечкенәдән тапкыр телле, җор сүзле, шат күңелле булып үсә. Әнисе даими язылып алдырган газета-журналлардагы әдәбият-сәнгать дөньясы Санияне дә кечкенәдән үк кызыктырып җәлеп итә. Әтисе Юныс абый да агач эшенә осталыгы белән тирә-якта дан тота. Йорт-җирне баштанаяк үзе төзеп, табак-кисмәктән алып, йорт җиһазларына кадәр үз кулы белән ясый. Арба тәгәрмәче, чана-чаңгы, тырма ише көнкүреш кирәк-яракларын ясауга, көянтә, ат дугасы, камыт бөгү кебек эшләргә дә кулы ятып тора. Әти-әнисе, алты баласына да төпле һөнәри белем алуда ярдәм итеп кенә калмыйча, үзләре белгән кул эшләренә маһирлыкны да мирас итеп калдыра.

Сания сигезьеллык мәктәпне, аннары Арча педагогия училищесын «бик яхшы» билгеләренә генә тәмамлый, Казан дәүләт педагогия институтының рус-татар бүлегендә югары белем ала. Рәхимә апа үзенең яшьлек хыялын кызының тормышка ашыруына куанып бетә алмый.

Сания Юныс кызы хезмәт юлын Казанда башлангыч сыйныфлар укытучысы буларак башлый. Балалар бакчасында тәрбияче, соңрак татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. Күңелендә гомер буе шигырь уты йөртеп, ике дистә елга якын балаларга белем һәм тәрбия бирә. Сайлаган һөнәренә тугры калып, мәктәп эшеннән журналистика-язу хезмәтенә күчә: укытучылар журналы булган «Мәгариф»кә бүлек мөхәррире итеп эшкә алына. Бүген дә милли мәгариф өлкәсендәге хезмәтен иҗади эшчәнлек белән бергә бәйләп алып бара.

Беренче әдәби иҗат тәҗрибәләре — шигырьләре һәм яшь хәбәрче язмалары — мәктәптә укыганда, «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында басыла. Педучилищеда белем алган елларында язучы Радик Фәизов җитәкләгән «Тукай якташы» әдәби түгәрәгенә йөреп, күпмедер иҗади чыныгу ала, шигырьләре һәм булачак укытучылар тормышыннан кызыклы язмалары белән район газетасында даими катнашып килә.

Сания Әхмәтҗанова туксанынчы елларда популяр җыр текстлары авторы буларак халыкка таныла. Аның шигырьләренә иҗат ителгән җырларны Рөстәм Закиров, Айдар Галимов, Алсу Хисамиева, Эльвира Хәйруллина, Алсу Хәбибуллина кебек танылган җырчылар бик теләп башкара. Җырчы һәм композитор Зөфәр Хәйретдинов турында аерым әйтеп үтәргә кирәктер, чөнки Сания Әхмәтҗанова шигырьләренә язылган күп җырның көй авторы да, башкаручысы да Зөфәр Хәйретдинов. Байтакка сузылган бәрәкәтле иҗади хезмәттәшлек нәтиҗәсе буларак, инде ике дистә ел дәвамында халык яратып тыңлый һәм җырлый торган «Пар алма», «Кура җиләк», «Дәшмә миңа, соң инде», «Әйтер сүзең әйтеп кал», «Сары кашкарыйлар», «Ялгыз әнкәй» кебек җырлар дөнья күрә.

«Идел-Пресс» нәшрияты 2002 елда Сания Әхмәтҗано-

ваның «Оч иреккә, җырым» исемле беренче китабын бастырып чыгара. Тәүге мәхәббәт лирикасы, хатын-кыз язмышы, халык-милләт турындагы фәлсәфи уйланулы шигырьләре тупланган китап укучылар күңеленә хуш килгәндер.

Сания Әхмәтҗанованың милләт язмышы, рухи иминлек, яшәү мәгънәсе белән сугарылган яңадан-яңа шигъри тупланмалары көндәлек матбугатта, аерым алганда «Казан утлары», «Мәйдан» журналларында, «Мәдәни җомга», «Ватаным Татарстан» газеталарында даими басылып тора; лирик таланты һәм иҗат үзенчәлекләре яңа җыр текстларында тагын да ныграк ачыла бара. 2008 елда Татарстан китап нәшриятында шагыйрәнең «Пар алма» дип исемләнгән яңа шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.

2009 елдан ул – Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Сания Әхмәтҗанованың әдәби теле халыкның җанлы сөйләменә, образлы фикерләвенә нигезләнгән; аның иҗатына ихласлык, хисси кайнарлык хас; шигъри әсәрләре күңел кылларын тибрәтерлек төгәл музыкаль-ритмик яңгырашка ия. Халык мәхәббәтен казанган әдип Мөхәммәт Мәһдиевнең якташы булу да рухи йогынты ясамый калмагандыр.

Кияүгә чыккач, Сания ире Сәүбәннең туган авылына – гүзәл табигатьле Ашытбашка туган йортына караганда да ешрак кайтып йөри башлый. Бергә гомер иткән чирек гасыр дәвамында ул һәвәскәр умартачы иренең алыштыргысыз ярдәмчесе дә, аркадашы да була. Бал кортларының искиткеч тырышлыгын күрү Саниянең иҗатына һәм яшәү рәвешенә дә йогынты ясагандыр, мөгаен. Җәен-көзен Ашытбаш белән ике арада яшәп, каенаналар каенанасы Маһиәнвәр апага карусыз килен хезмәте күрсәтеп, ире белән бергә ике егет үстерәләр. Улларына авыл тормышының, умартачылык шөгыленең нечкәлекләрен төшендереп кенә калмыйча, үзләре сайлаган юнәлештә югары һөнәри белем алуга мөмкинлек тә бирәләр.

Бүген шагыйрәнең иҗат галәмендә үз юлын табып, ирекле очышка кыюрак омтылуын, үзе ачкан йолдызлардан нур алып, шигъри таҗын яңа бизәкләр белән баетуын, аңлашыла ки, балалары үсеп, имин гаилә тормышында үз күңеленңне дә күрү мөмкинлеге, ягъни илһамлы икенче сулыш ачылу белән дә аңлату фарыздыр. Хәер, Сания Әхмәтҗанованың иҗатын күз уңында тоткан шигърият сөючеләр соңгы елларда моны үзләре дә тоеп, бәяләми калмагандыр, мөгаен.

# БИБЛИОГРАФИЯ

*Фәйзуллин Р.* **Җыр канатлары сынмасын!** – Китапта : Оч иреккә, җырым : шигырьләр. – Казан : ГУП ПИК «Идел-Пресс», 2002. – 5 б.

*Гарипова Х.* **Җыр канаты – сөюдән** // Шәһри Казан. – 2003. – 14 март. – 14 б. С. Әхмәтҗанованың «Оч иреккә, җырым» китабы чыгу уңаеннан.

*Мостафин Р.* **Шигъриятькә кызлар килә** // Татарстан яшьләре. – 2004. – 15 гыйнвар. Мәкаләдә С. Әхмәтҗанова иҗаты турында әйтелә.

*Садә Г.* **Офыгында – кояш нуры** // Ватаным Татарстан. – 2004. – 23 гыйнвар. С. Әхмәтҗанова шигырьләренә кереш сүз.

*Мөхәммәдиева Л.* **Туган якта очрашу** // Арча хәбәрләре. – 2004. – Февраль. Мәктәптә укучылар белән очрашудан соң язылган мәкалә.

*Гәрәев М.* **Син йөрәктә...** // Мәдәни җомга. – 2004. – 19 март. – 8 б. Арчада булып узган хезмәт һәм сәнгать бәйрәме турындагы язмада С. Әхмәтҗанова иҗаты искә алына.

*Сәлахова Э.* **Укытучы булып туганмын...** // Ирек мәйданы. – 2004. – №19. – 5 ноябрь. – 4 – 6 б. С. Әхмәтҗанованың иҗаты һәм тормышы турында.

**Хитлар ничек туа?** // Кәеф ничек? – 2006. – №5. – Март. – 10 б. А. Юнысова, М. Әгъләм, С. Әхмәтҗанова сүзләренә язылган җырлар турында.

*Гаташ Р.* // Ватаным Татарстан. – 2007. – 6 апрель. – 6 б. С. Әхмәтҗанова шигырьләренә кереш сүз.

**Туган нигез җылысына төреп...** // Мәдәни җомга. – 2007. – 20 апрель. – 7 б. Шигырьләреннән соң кыскача белешмә.

*Моратов Г.* **Пар алмадай идек, багалмадай.** – Китапта : Пар алма : шигырьләр. – Казан : Татар.кит.нәшр., 2008. – 5 – 6 б.

*Вәлиева Д.* **Мин бәхетле булыр өчен тудым** //Ватаным Татарстан. – 2009. – № 13. – 24 гыйнвар. – 8 б. «Пар алма» китабын укучыга тәкъдим итү кичәсе турында мәкалә.

*Гыйззәтуллин Р.* **Җырың очсын биектә** //Мәдәни җомга. – 2010. – 20 август. –16 б. «Пар алма» китабына рецензия.

## ЭЧТӘЛЕК

Гәрәбә — диңгез бүләге. *Марсель Галиев* . . . . . . . . . . . . . . 3

**Җан сулышым** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Ант . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Өлгерәсе иде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Тере сүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Ташлама... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Татар җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Сәхтиян лә читек, көмеш дага... . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Икетелле телсезлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Миллениум . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Мәңгелек ут . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Уян, дидем... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Канатсызлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Оч ирекkә, җырым! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Чакыру . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Җавап . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Инану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Ният . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Халәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Гадел хаким . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Бирәүгә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Сабырлык бирде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
Ни булса, шул! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Күңел төшкәндә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
Белмәү кирәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Үч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
Тәүбә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42
Дөнья бу! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Кыйблаң үзгәрт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Ният һәм гамәл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Үзем белән күзгә-күз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
Җимеш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Яшь әби . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48

Кешелегем . . . . . . . . . . 49
Төен . . . . . . . . . . 50
Гаеп кемдә? . . . . . . . . . . 51
Бүре өнендә . . . . . . . . . . 52
Кеше булыйк . . . . . . . . . . 53
Хыялым . . . . . . . . . . 54
Өр-яңа мин . . . . . . . . . . 55
Исәнме, яңа көн! . . . . . . . . . . 56
Сәфәр . . . . . . . . . . 57
Алдаша кәккүк, ялгыша . . . . . . . . . . 58
Гомер учагы . . . . . . . . . . 59
Юлаучы . . . . . . . . . . 60
Мин үзем! . . . . . . . . . . 61
Хуш хәзергә... . . . . . . . . . . 62

**Гомерлек бурыч . . . . . . . . . . 63**
Бәбкә . . . . . . . . . . 65
Дәвамчы . . . . . . . . . . 66
Улыма . . . . . . . . . . 67
Фатиха . . . . . . . . . . 68
Балам, бел... . . . . . . . . . . 69
Моңлану . . . . . . . . . . 70
Мәңгелек бәхәс . . . . . . . . . . 71
Ана һәм бала . . . . . . . . . . 72
Әни сүзе . . . . . . . . . . 73
Дускаем-сердәшем . . . . . . . . . . 74
Уйлармы? . . . . . . . . . . 75
Тормыш киносы . . . . . . . . . . 76
Тиеш! . . . . . . . . . . 78
«Үпкәләдең, ахры, әни, миңа...» . . . . . . . . . . 78
Кичер, әбкәй . . . . . . . . . . 79
Утлы күмер . . . . . . . . . . 80
Кайту . . . . . . . . . . 81
Әни бәлеше . . . . . . . . . . 82
Әнкәем-сердәшемә . . . . . . . . . . 84
Уклау . . . . . . . . . . 86
Әйттеме әни, уйлады гынамы? . . . . . . . . . . 87
Тансыклау . . . . . . . . . . 88
Шәлбизәк . . . . . . . . . . 89
Әнием хатлары . . . . . . . . . . 90
Туган яклар — җанга дәва . . . . . . . . . . 91
Озакламыйм . . . . . . . . . . 92

Мирас . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
Авыл кызы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 94
Мин – туган як баласы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 95
Бөекләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
Очрашу җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Белем алиһәсе – Әлифба . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
Галәми сәлам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100
Яшәү гимны . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
Кардәшлекне саклыйк йөрәктә . . . . . . . . . . . . . 102
Кошлар кайта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
Нәүруз килә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Яфрак гомере . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106
Ачуланма, шәһәр... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
Сафлану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
Зәңгәр күлдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Туган-үскән җирләрдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Соклану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Көз һәм без . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Тәүге кар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
Истирахәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115

**Алмагач бураны** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
Мин бәхетле булыр өчен тудым! . . . . . . . . . . . 119
Мәңгелек җырым бул! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
Парлы гомер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
Сиңа таба . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Гөлбишек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 123
Гомер юлын узыйк бергәләп . . . . . . . . . . . . . . 124
Кушылыйк куш каеннардай . . . . . . . . . . . . . . . 125
Син – йөрәге минем сөюемнең . . . . . . . . . . . . 126
Сагыну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Читтән торып . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128
Ялгызларга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
Аерылу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130
Аңлашыйк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
Чынлап шаяру . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Үкенеч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Китек бәхет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
Тамаша . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
Китү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Хәтәр төш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
Бергә булуларга ни җитә? . . . . . . . . . . . . . . . . 138

Безнең сөю . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
Йоклый алмыйлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
Бергә чакның кадерен белик . . . . . . . . . . . . . . 141
Ышанам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
Күңелемнән — күңелеңә . . . . . . . . . . . . . . . . 143
Мәхәббәт җимеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
Кыргый алма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Чалма чәчәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
Янартау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Йөрәксенү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Хыялый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
Сөю тәме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
Мин синең өчен яратылганмын . . . . . . . . . . . . 150
Син ул — артист! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Соңгы бүләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152
Кыйсса . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
Һава торышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Алтынчы көн... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Тик син диеп кенә яшим . . . . . . . . . . . . . . . . 156
Гәрәбә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157
Алмагач бураны . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
Кызыл Төлке . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
Сөюдән ваз кичмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160
Миңа сусап баккан карашыңда... . . . . . . . . . . . 161
Бер вакытлык... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Җиңелү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163
Үзем булып калыймчы?! . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Кил генә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
Агыла гомер, агыла . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166
Газаплама . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
Йөрәк белән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
Дога . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169
Кичә һәм бүген . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
Тормыш — сәхнә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171
Очрар әле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172
Ярый син бар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173
Онытыйк ярату турында . . . . . . . . . . . . . . . . 174
Ут һәм су . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175
Розалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
Гөлбадран . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
Мин, чыннан да, сөя идем . . . . . . . . . . . . . . . 178
«Мин»ле шигырь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 179

Хушлашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180
Килә үзем булып каласым . . . . . . . . . . . . . . . . 181
Аклык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182
Күк күбәләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 183
Ник дәшәсең? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 184
Тәүге ярым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 185
Йөрәгемә яздым исемеңне . . . . . . . . . . . . . . . . 186
Лилияләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 187
Йөрәгеңнән — йөрәгемә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 188
Хакыйкать . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 189
Мине сөю бара озатып . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 190

**Татар кызлары** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 191

Ниятләү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 193
*Ханнар китә — халык кала* . . . . . . . . . . . . . . . 195
Нурсолтан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 195
Сөембикә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 199
Фатима Солтан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 201
Чордан чорга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 203
*Гыйлем таҗы* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 204
Мулла-абыстай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 204
Фатиха . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 208
Сара . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 211
Җәмилә бәете . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 214
*Кызлар-йолдызлар* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 217
Төнге фәрештәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 217
Татар йөрәкле бию . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 220
Гимнастика шаһинәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 222
Юлдан юлга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 225

**Сүнмәс балкыш** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 227

Тарих бусагасында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 229
Табиблык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 230
Галимлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 232
Зыялылык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 236
Бәхилләшү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 238

**Төрки дөнья таҗы — Төркия** . . . . . . . . . . . . . 243

Һава юлы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 245
Төрки дөнья таҗы — Төркия . . . . . . . . . . . . . . . 246
Татар акылы... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 247
Мәдхия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 248

Бәхетле милләт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 249
Илаһи ләззәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 251
Манзара . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 252
Төнге бию . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 253
Төрек мунчасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 254
Төрек егетенә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 255
Хушлашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 256

**Сер турында хикәят . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 257**

**Сине җырымда сөям . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 267**

Дәшмә миңа, соң инде... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 269
Ялгыз әнкәй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 270
Кура җиләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 271
Пар алма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 272
Балачагыма кайтам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 273
Моңаймагыз, шомыртларым . . . . . . . . . . . . . . . . . . 274
Әйтер сүзең әйтеп кал . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 275
Чишмәләрдә керләр чайкыйм . . . . . . . . . . . . . . . . . 276
Арчаларда калып булмады . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 277
Син – башканың бәхете . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 278
Толымнарым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 279
Ялгыз учак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 280
Сары кашкарыйлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 281
Ана җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 282
Рәхмәт, Казаным . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 283
Мәхәббәтле бул . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 284
Мин ул, әни, синең яшь чагың . . . . . . . . . . . . . . . . 285
Килә бүген ялгыз каласым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 286
Син сөюдән чибәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 287
Телефон дәшми . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 288
Йөрәгемә карый күзләрең . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 289
Адаштык мәхәббәт илендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 290
Күрше егете җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 291
Тылсымлы мәхәббәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 292
Алсу гөлем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 293
Кояшлы гомер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 294
Унҗиде яшь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 295
Әйдә, китик ерак-еракка... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 296
Әниемнең туган көне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 297
Син – матур җырым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 298
Безнең сөю . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 299
Ни булды сиңа? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 300

Җавапсыз сөю . . . 301
Әткәй-әнкәй — пар канатым . . . 302
Җан дусларыма . . . 303
Яшьлегемә кире кайталмыйм . . . 304
Ашытбаш кызлары . . . 305
Мине югалтырга ашыкма . . . 306
Минем арттан йөрмә, хыянәт . . . 307
Ялгышма . . . 308
Саҗидәкәй . . . 309
Яшерен чишмәм . . . 310
Язмышым минем — Арчам . . . 311
Өч Пошалым — өч игезәк . . . 312
Солдат егеткә . . . 314
Иң матур бәйрәмеңә . . . 315
Хуш килдең, Яңа ел! . . . 316
Мин монда юк . . . 317
Үкенмим . . . 318
Син — мәхәббәтнең үзе . . . 319
Сәбәпләрен сора йөрәктән . . . 320
Тик син кирәк . . . 321
«Яратам» дип әйтсәң, ни була? . . . 322
Әле син дә сөярсең . . . 323
Җаныма нидер җитми . . . 324
Бердәнберемә . . . 325
Шалты җыры . . . 326
Бер очрашу . . . 327
Бердәнберем булмадың . . . 328
Яңа гасыр дәшә . . . 329
Әтнә . . . 330
Ышандыр . . . 331
Көтәм . . . 332
Кыргый гөл . . . 333
Түнтәр . . . 334
Сиңа читтән табынам . . . 335
Туган авылым — Әхмәтем . . . 336
Соңгы хат . . . 338

*Гомер фасыллары* . . . 339

*Библиография* . . . 343

Литературно-художественное издание

**Ахметзянова** Сания Юносовна

ЯНТАРЬ

Казань. Татарское книжное издательство. 2012

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Әхмәтҗанова** Сания Юныс кызы

ГӘРӘБӘ

Мөхәррире *Л. Ә. Гыйззәтуллина*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *М. Д. Вәҗиева*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф. Р. Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Г. Г. Габдуллаҗанова, Р. Н. Нуриева*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 26.03.12. Форматы $70 \times 108^1/_{32}$.
Шартлы басма табагы 15,4. Тиражы 2300 д. Заказ М-383.

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

**Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:**

Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге. Тел.: (843) 519-45-35.
Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете. Тел.: (843) 292-03-18.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.